**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 8 апрель № 231

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 22 апрель, 267 нче; 2014 ел, 1 октябрь, 708 нче; 2014 ел, 14 ноябрь, 876 нчы; 2014 ел, 12 декабрь, 977 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына, карарга теркәлгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\231.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 8 апрель, 231 нче
карары редакциясендә)

2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы

Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы (алга таба – Программа) |
| Программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысы | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| Программаның дәүләт заказчылары | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы,Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе, Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды |
| Программаның максаты | Социаль ярдәм һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәле адреслы системасын булдыру, шулай ук гражданнарның аерым категорияләре тормыш сыйфатын күтәрү |
| Программаның бурычлары | 1. Татарстан Республикасы гражданнарының аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларын күрсәтү һәм тормыш сыйфатын күтәрү.<br>2. Өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү.<br>3. Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү.<br>4. Үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне тәэмин итеп тору буенча ведомствоара үзара хезмәттәшлек механизмын булдыру.<br>5. Гаиләгә һәм гаилә тормышы кыйммәтләренә булышлык күрсәтү, аларны ныгыту һәм яклау, гаиләләрнең тормыш сыйфатын күтәрү. |

| | |
|---|---|
| | 6. Татарстан Республикасында инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектларга керә алу һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу дәрәҗәсен күтәрү.<br>7. Татарстан Республикасында инвалидларны тернәкләндерү һәм социаль интеграцияләү системасын мәгълүмати-методик яктан һәм кадрлар белән тәэмин итү.<br>8. Җәмгыятьтә социаль таркаулыкны бетерү һәм инвалидлар проблемаларына һәм Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен тереклек эшчәнлегенең унай мохитен тәэмин итү проблемасына карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру.<br>9. 3 яшькә кадәрге балаларның тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту.<br>10. Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру өчен унай шартлар тудыру. |
| Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2020 еллар |
| Ярдәмче программалар исемлеге | 1. 2014 – 2020 елларга «Социаль түләүләр».<br>2. 2014 – 2020 елларга «Өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү».<br>3. 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү».<br>4. «2014 елга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору системасын формалаштыру комплексы программасы».<br>5. 2014 – 2020 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту».<br>6. 2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит».<br>7. 2014 елга «Бәләкәч – Малыш».<br>8. 2014 елга «Опекуннарга һәм тәрбиягә бала алган ата-аналарга дәүләт ярдәме күрсәтү» |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 171 804 670,42 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 126 952 950,266 мең сум; федераль бюджет акчасы исәбеннән – 44 836 193,717 мең сум, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия исәбеннән – 13 871,900 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән – 1 654,537 мең сум (2013 елда Тормыш хәле авыр булган балаларга ярдәм фондыннан алынган тотылмый калган акча). |

<table>
<tr>
<td></td>
<td>
мең сум
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Акча күләме, барлыгы</th><th colspan="4">Шул исәптән</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>федераль бюджет акчасы</th><th>Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия</th><th>бюджеттан тыш чыганаклар</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>22 093 722,52</td><td>16 070 8 9, 83</td><td>6 007 386,200</td><td>13 871,900</td><td>1 654,537</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>23 089 730,7</td><td>16 622 302,983</td><td>6 467 427,717</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>23 141 154,1</td><td>17 139 160,2</td><td>6 001 993,9</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>24 327 863,9</td><td>18 132 505,8</td><td>6 195 358,1</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>25 369 288,7</td><td>18 907 530,2</td><td>6 461 758,5</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>26 404 974,0</td><td>19 678 283,1</td><td>6 726 690,9</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>27 377 936,5</td><td>20 402 358,1</td><td>6 975 578,4</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>171 804 670,42</td><td>126 952 950,266</td><td>44 836 193,717</td><td>13 871,900</td><td>1 654,537</td></tr>
</table>
Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш
</td>
</tr>
<tr>
<td>Еллар буенча бүлеп, Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)</td>
<td>
Ярдәмче программаны тормышка ашыру 2020 елда түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:
хокуклары булган һәм аларны билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән аерым категорияле гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтүне 100 процент дәрәҗәсендә тәэмин итәргә;
социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдалануга хокуклары булган һәм алардан файдалану өчен дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына мөрәҗәгать иткән гражданнарның гомуми санында дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланган гражданнар өлешен 100 процентка кадәр арттырырга;
Татарстан Республикасында балаларның гомуми санында күзәтүчесез һәм караучысыз балигъ булмаган балаларның чагыштырма авырлыгын 0,38 процентка кадәр киметергә;
эшчәнлекләре билгеләнгән критерийларга (стандартларга) туры килми торган дәүләт халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмалары булмауны тәэмин итәргә, 0 процент;
барлык милек рәвешендәге социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында хезмәт күрсәтүләрдән файдаланган өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның (өлкәннәр һәм балалар) гомуми санында дәүләткә карамаган социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында хезмәт күрсәтүләрдән файдаланган өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның (өлкәннәр һәм балалар) чагыштырма авырлыгын 5 процентка кадәр арттырырга;
барлык милек рәвешендәге оешмаларның гомуми санынннан социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләткә карамаган оешмаларның чагыштырма авырлыгын 1,4 процентка арттырырга;
дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының гомуми санында СанПиН нормаларына кадәр житкерелгән дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының чагыштырма
</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | авырлыгын 95 процентка кадәр җиткерергә;<br>социаль ярдәм чараларыннан файдаланучы өлкән яшьтәге гражданнарның керемнәре артуны кимендә 7,9 процент (2030 елга кадәр Россия Федерациясен озак вакытлы фаразы социаль-икътисадый үстерү буенча инфляция индексыннан түбән булмаган) күләмендә тәэмин итәргә;<br>гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өлешен 98,8 процентка кадәр арттырырга;<br>ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруның барлык төр формаларында социаль түләүләр бирүне 100 процент дәрәҗәсендә тәэмин итәргә;<br>җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән халыкның җан башына яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрдәге өч яшькә кадәрге балаларның, шулай ук түләүсез нигездә табиблар рецептлары буенча махсус балалар туклануы продуктлары белән тәэмин ителгән хроник авырулары булган балаларның чагыштырма авырлыгын 100 процент дәрәҗәсендә сакларга;<br>балалар туклануы җитештерү өчен файдаланыла торган сөткә базар һәм теркәлгән бәяләр арасындагы аерманы тулы күләмдә каплауны 100 процент дәрәҗәсендә тәэмин итәргә;<br>Татарстан Республикасында гаиләләрнең гомуми санында торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә торак субсидияләре алган гаиләләр өлешен 8,1 процентка кадәр киметергә;<br>тернәкләндерү вакытларын арттырмыйча уңай нәтиҗәләргә ирешкәннән соң аларга карата ведомствоара патронажлык итеп тору туктатылган балалы гаиләләр өлешен 81,1 процентка кадәр арттырырга;<br>сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 4 яшькә кадәрге балаларның гомуми санында яшьтән үк чара күрү кабинетларында тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүдән файдаланган сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 4 яшькә кадәрге балаларның чагыштырма авырлыгын 2014 елда 11,0 процентка кадәр җиткерергә;<br>Ведомствоара патронажлык итеп тору хезмәте тарафыннан ачыкланганнар һәм исәпкә куелганнар арасыннан 2014 ел эчендә үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларга ведомствоара патронажлык итеп торуга 100 процент күләмендә тартуны тәэмин итәргә;<br>Ведомствоара патронажлык итеп тору хезмәте күзәтүендәге гаиләләрнең гомуми саныннан социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең көндез була торган бүлекләрендә социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланган үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар |

| | |
|---|---|
| | тәрбияләүче гаиләләрнең чагыштырма авырлыгын 2014 елда 90 процентка кадәр җиткерергә;<br>Татарстан Республикасында инвалидларның гомуми санында тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге өстенлекле объектларга керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу дәрәҗәсен уңай бәяләүче инвалидлар өлешен 55,0 процент дәрәҗәсенә кадәр җиткерергә;<br>Татарстан Республикасында өстенлекле объектларның гомуми санында <1> социаль, транспорт, инженерлык инфраструктурасының өстенлекле объектларыннан инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре файдалана ала торган өлешен 45,0 процент дәрәҗәсенә кадәр җиткерергә;<br>Татарстан Республикасында хәрәкәт итүче состав паркында халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәрен йөртү өчен җиһазландырылган гомуми файдаланудагы автомобиль һәм җир өсте шәһәр электр транспортының хәрәкәт итүче составы паркы өлешен 11,7 процент дәрәҗәсенә кадәр җиткерергә;<br>һөнәр белеме бирүче оешмаларның гомуми санында үсешләрендә бозыклыклар булмаган затларның һәм инвалидларның бергә укуын тәэмин итәргә булыша торган универсаль киртәсез мохит булдырылган һөнәр белеме бирү оешмалары өлешен 15,4 процент дәрәҗәсенә кадәр җиткерергә;<br>системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге инвалидларның һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның халыкның бу категориясе гомуми санындагы өлешен 15,0 процент дәрәҗәсенә кадәр җиткерергә;<br>Татарстан Республикасында сораштырылган инвалидларның гомуми санында инвалидлар проблемаларына халыкның мөнәсәбәтен уңай бәяләүче инвалидлар өлешен 49,6 процент дәрәҗәсенә кадәр җиткерергә;<br>инвалидларны тернәкләндерү, социаль интеграцияләү мәсьәләләре буенча өйрәтү үткән һәм квалификациясен күтәргән белгечләр өлешен бу өлкәдә эшләүче барлык белгечләр арасында 26,0 процент дәрәҗәсенә кадәр җиткерергә;<br>картларга кичектергесез социаль һәм медицина-социаль хезмәтләр күрсәтү буенча мобиль бригадалар эшчәнлеген тәэмин итү өчен яна автотранспорт белән җиһазландырылган социаль хезмәт күрсәтүче территориаль комплекслы үзәкләрнең чагыштырма авырлыгын 46,6 процентка кадәр җиткерергә. |

<1> Тереклек эшчәнлегенең һәр өстенлекле өлкәсе буенча шундый ук күрсәткечләр (индикаторлар) хисаплап чыгарылырга мөмкин.

## I. Программаны тормышка ашыру өлкәсе тасвирламасы. Программа хәл итәргә йөз тоткан проблемалар

Бу Программа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 ел, 17 ноябрь, б-1662 нче боерыгы белән расланган Россия икътисадый үсешенең инновацион социаль юнәлешле тибына күчү шартларында 2020 елга кадәр Россиянең озак вакытлы социаль-икътисадый үсеше концепциясе, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 ел, 7 февраль, б-165 нче боерыгы белән расланган 2020 елга кадәрге чорга Идел буе федераль округының социаль-икътисадый үсеш стратегиясенең төп нигезләмәләре, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 ел, 10 март, б-367 нче боерыгы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга 2011 – 2015 елларда Россия Федерациясенең демографик сәясәте концепциясен тормышка ашыру буенча чаралар планы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 12 гыйнвар, 6 нчы карары белән расланган 2010 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге перспективага Татарстан Республикасын демографик үстерү комплекслы программасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 ел, 25 август, б-1618 нче боерыгы белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә дәүләт гаилә сәясәте концепциясе нигезендә эшләнде.

Бу Программаны тормышка ашыруның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

өлкән яшь төркеменә керүче гражданнар тереклек эшчәнлегенең тискәре демографик тенденцияләрен җиңеп чыгу, халыкның тормыш сыйфатын күтәрү;

сыйфатлы белем һәм медицина ярдәме алу мөмкинлеген тәэмин итү, халыкны һәркем сатып алырлык һәм сыйфатлы торак белән тәэмин итү;

өлкән яштәге кешеләр, инвалидлар һәм балалар өчен булышлык һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәле адреслы системасын булдыру;

гаиләгә һәм гаилә тормышы кыйммәтләренә булышлык күрсәтү, аларны ныгыту һәм яклау, гаиләләрнең тормыш сыйфатын күтәрү.

Программа гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чараларының эшләп торучы системаларын модернизацияләүне һәм кабул ителгән ачык норматив йөкләмәләрне тормышка ашыруны тәэмин итә торган эшчәнлек юнәлешләрен аларның нәтиҗәлелеген күтәрү һәм файдасын арттыру максатында билгели.

Татарстан Республикасында 3,8 миллионнан артык кеше, шул исәптән 645 096 бала (17 процент); 2 326 780 (61,2 процент) эшкә яраклы яштәге гражданнар; 831 313 (21,8 процент) эшкә яраклы яштән өлкәнрәк кеше яши.

Татарстан Республикасында формалашкан халыкны социаль яклау системасы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

гражданнарның төрле категорияләренә федераль һәм республика законнарында каралган социаль түләүләрне, компенсацияләрне, субсидияләрне, пособиеләрне бирүне; аз керемле гаиләләрнең һәм ялгыз яшәүче аз керемле гражданнарның тормыш дәрәҗәсен саклау өчен төрле төрдәге дәүләт социаль ярдәмен күрсәтүне;

балигъ булмаганнарны һәм эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраксыз гражданнарга карата опеканы һәм попечительлекне;

балаларга, шулай ук балалы гаиләләргә кайбер өстәмә чараларны;

халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре тарафыннан социаль хезмәтләрнең төрле төрләрен күрсәтүне;

инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен тереклек эшчәнлегенең һәркем керә алырлык һәм уңай мохитен булдыруны.

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләр бүлешү шартларында гамәлгә ашырыла торган халыкны социаль яклау өлкәсендәге дәүләт социаль йөкләмәләрен һәм бюджет системасы дәрәҗәләре буенча гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча тиешле чыгым йөкләмәләрен үз вакытында һәм тулы күләмдә үтәү оештырылган.

Россия Федерациясенең федераль бюджеттан финанслана торган чыгым йөкләмәләренә Бөек Ватан сугышы ветераннарына; инвалидларга; инвалид балалары булган гаиләләргә; техноген һәлакәтләрдән зыян күргән гражданнарга һәм социаль ярдәмгә мохтаҗ гражданнарның федераль законнар белән билгеләнгән башка категорияләренә күрсәтелә торган социаль ярдәм чаралары кертелгән

| Күрсәткечләр | 2009 ел | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел |
|---|---|---|---|---|
| Федераль бюджеттан финанслана торган социаль ярдәм чараларыннан файдаланучылар – федераль ташламалары булган затлар саны, кеше | 441 031 | 368 713 | 370 933 | 371 779 |
| Федераль бюджет акчасы, млн.сум | 2 405,47 | 2 666,05 | 3 103,93 | 3 279,66 |

Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләренә хезмәт ветераннарына, тыл хезмәткәрләренә, тернәкләндерелгән затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга, балалы гаиләләргә, аз керемле гражданнарга һәм тормыш хәле авыр булган гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чаралары кертелгән.

| Күрсәткечләр | 2009 ел | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел |
|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган социаль ярдәм чараларыннан файдаланучылар – республика ташламалары булган затлар саны, кеше | 922 980 | 987 999 | 984 294 | 1 209 084 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, млн.сум | 5 047,52 | 5 785,22 | 6 292,90 | 7 019,62 |

Узган дүрт елда халыкны социаль яклау системасында социаль ярдәм чараларыннан файдаланучылар булган гражданнар саны 16 процентка артты һәм бүгенге көнгә 1,5 млн. артык кеше тәшкил итә. Бу чараларны тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләре 38 процентка артты (2009 елда - 7 472,9 млн.сум, 2012 елда – 10 299,28 млн.сум).

Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан халыкның керемнәрен арттыру буенча кабул ителә торган чаралар

гаиләләрнең матди хәлен яхшырта һәм аз керемле гражданнар саны кимүгә китерә. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү технологиясен кертү аз керемле гаиләләрнең тормыш сыйфатын аларның адаптив мөмкинлекләрен активлаштыру, ярдәм алучыларның социаль җаваплылыгын арттыру, аларның үз-үзләрен тотышларындагы кеше хисабына яшәү мотивын киметү юлы белән күтәрүгә булыша.

Торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү тарифлары артуга бәйле рәвештә гражданнарның керемнәре дәрәҗәсе кимүне кисәтү, шулай ук файдаланылган хезмәт күрсәтүләр өчен аларның түләү мөмкинлеген тәэмин итү (Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә федераль дәрәҗәдә билгеләнгән торак-коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларыннан тыш) максатларында, Татарстан Республикасында берничә өстәмә субсидия бүлеп бирелә. Социаль ярдәмнең әлеге чараларын күрсәтү исәбенә субсидия алучы гаиләнең торак-коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен үз түләве күләме керемнең 12 процентыннан артмый.

Соңгы өч ел эчендә республикада гражданнарның аерым категорияләренә, балалы гаиләләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган яңа өстәмә социаль ярдәм чаралары билгеләнде, шул исәптән керемнәрне исәпкә алып күрсәтелә торган:

даими кеше тәрбиясенә (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү;

хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәвалану алучы затларга дәвалану урынына баруга компенсация.

Республика пенсионерларының шифаханә-курорт дәвалавыннан файдалана алу мөмкинлеген киңәйтү максатыннан чыгып, пенсионер гаиләсенең җан башына уртача кеременә карап, юллама кыйммәтенә өлешчә түләү кертелде, бу шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин ителгән пенсионерлар санын 30 процентка арттырырга мөмкинлек бирде.

«Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән аналарга бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү күләме арттырылды, биш бала тәрбияләгәннәргә - 25 мең сумга кадәр; алты һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләгән аналарга һәр балага исәпләгәндә акчалата бүләкләү күләме тиешенчә 5 мең сумга арта.

Берьюлы өч һәм аннан да күбрәк баласы туган гаиләләргә һәр балага 10 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие һәм яшь ярымга кадәрге һәр балага 1 мең сум күләмендә айлык пособие билгеләнде.

Хәзерге этапта Татарстан Республикасында дәүләт гаилә сәясәтенең өстенлекләре булып түбәндәгеләр тора:

хезмәт күрсәтүләрнең комплекслылыгы, алардан һәркем файдалана алу;

хезмәтләр барлык мөрәҗәгать иткән гражданнарга, аларның яшенә, диненә, социаль статусына, яшәү урынына карамастан һәм бары тик ирекле тәртиптә генә күрсәтелә;

консультацияләр клиентлардан алына торган аларның шәхси тормышы турындагы мәгълүматның тулысынча конфиденциальлеге саклануга нигезләнә;

белгечләрнең һөнәри дәрәҗәсе югары булу;

клиентлар теләге буенча мөрәҗәгать аноним булырга мөмкин;

кешелеклелек, игелеклелек, игътибар, индивидуаль мөнәсәбәт.

2013 елда Татарстан Республикасында 33 580 пар үз никахларын теркәде, бу 2012 ел белән чагыштырганда 408 парга күбрәк (1,2 процент). 2014 елның 9 аенда республикада никахлар теркәлү саны 2013 елның шундый ук чоры белән чагыштырганда 3,2 процентка кимү билгеләп үтелә.

Соңгы җиде ел эчендә Татарстан Республикасында теркәлә торган никахлашулар һәм аерылулар чагыштырмасы акрынлап яхшыра (2006 елда 1000 никахлашуга - 545 аерылышу, 2013 елда 467 аерылышу туры килде).

2013 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында 57 214 бала туу турында акт теркәлде.Туучыларны теркәү дәрәҗәсенә ирешү 2012 ел дәрәҗәсеннән 2,2 процентка күбрәк, ә 1999 ел белән чагыштырганда туучыларны теркәү 62 процент тәшкил итте. Яңа туган балаларның гомуми санынннан 29 408 малай (51,4 процент) һәм 27 806 кыз (48,6 процент) теркәлде.

Татарстан Республикасында балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары федераль һәм республика законнары нигезендә күрсәтелә. «Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» 1995 ел, 19 май, ФЗ-81 нче Федераль закон нигезендә вакытлыча эшкә яраксыз булу очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерелергә тиеш булмаган затларга түбәндәгеләр түләнә:

бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособие;

хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие;

хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәр баласына айлык пособие;

бала карау буенча айлык пособие.

2014 елның 1 сентябре хәленә карата эшләмәүче ата-аналар бала тууга бер тапкыр бирелә торган 5 297 пособие алды, хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең 32 йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие түләнде, 19 848 эшләмәүче зат бала карау буенча пособие ала, айлык пособие хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең 100 баласына түләнә.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон нигезендә ата-аналарга ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация түләнә:

беренче балага – мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыручы дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең уртача күләменнән 20 процент;

икенче балага – күрсәтелгән түләү күләменең 50 проценты;

өченче һәм аннан соң килүче балаларга – күрсәтелгән түләү күләменең 70 проценты.

2014 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасындагы муниципаль берәмлекләр дәрәҗәсендә мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләве өлешендә өстәмә компенсация билгеләнде. Өстәмә компенсация җан башына айлык уртача керемнәре 20 мең сумнан артмаган

гражданнарга бирелә. 2014 елның 1 сентябре хәленә карата өстәмә компенсация 52 334 бала өчен билгеләнде.

18 яшькә кадәрге балалары булган гражданнарга республика социаль ярдәм чаралары «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә бирелә. Аларга түбәндәгеләр керә:

җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән халыкның яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрдән булган өч яшькә кадәрге балаларны һәм республика сәламәтлек саклау учреждениеләрендә яшәү урыны буенча амбулатор исәптә торучы ясалма һәм катнаш туклануны хроник авырулары булган балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү;

исемлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели торган өч яшькә кадәрге балаларны дару чаралары белән түләүсез тәэмин итү;

балаларны лагерьларда, шифаханәләрдә, шифаханә-профилакторийларда савыктыруга юлламалар бирү. 2014 елда тормыш хәле авыр булган 9 390 бала төрле типтагы савыктыру оешмаларына юллама алды;

уку чорында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәр белеме бирүче оешмаларда белем алучыларны бер укучыга, бәясе көнгә 5,8 сум исәбеннән чыгып, туклану белән тәэмин итү.

Җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган балалы гаиләләргә 16 яшькә кадәрге балага айлык пособие түләнә (гомуми белем бирү учреждениесендә белем алучыга – укуын тәмамлаганга кадәр, әмма 18 яшькә җиткәнгә кадәр генә).

Балага айлык пособие алучылар булган гаиләләрдә яшәүче мәктәп яшендәге балалар саны 2014 елда 35 520 кеше тәшкил итте (2013 елда - 46 215 бала).

2014 елның 1 гыйнварыннан балага түләнә торган айлык пособие күләме 249 сум тәшкил итә; ялгыз ана баласына – 662 сум, хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәр баласына һәм ата-аналары алиментлар түләүдән качып йөрүче балага 374 сум. Айлык пособие алучылар булып 83 560 бала тора.

18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган (тәрбиягә алганнарны да кертеп) гаиләләргә өстәмә рәвештә түбәндәгеләр бирелә:

6 яшькә кадәрге бала өчен дару чаралары сатып алуга 101 сум күләмендә субсидия (2014 елның 1 гыйнварыннан);

Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән торак мәйданының социаль нормасы чикләрендә торакка түләү чыгымнарының 30 проценты күләмендә субсидия;

халык өчен хезмәт күрсәтүләрдән файдалануның билгеләнгән нормативлары чикләрендә коммуналь хезмәт күрсәтүләргә түләү чыгымнарының 30 проценты күләмендә, ә үзәкләштереп җылытылмый торган йортларда яшәүче гаиләләр өчен халыкка сату өчен билгеләнгән нормалар чикләрендә сатып алына торган ягулык бәясеннән субсидия;

гомуми белем бирү оешмалары укучыларына һәм һөнәр белеме бирү оешмалары студентларына укуларын тәмамлаганга кадәр, әмма 18 яшькә җиткәнче генә, 229 сум күләмендә юлда йөрүгә айлык субсидия. Субсидия алучылар шәһәр

җәмәгать транспортының барлык төрләрендә һәм шәһәр яны элемтәсе автомобиль транспортында йөрү өчен бердәм айлык балалар социаль юл билеты сатып алырга мөмкин.

2014 елның 1 сентябре хәленә карата 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләрдән 65 142 бала өстәмә социаль ярдәм чараларын алучылар булып тора.

Юлда йөрү өчен субсидия шулай ук белем бирү оешмаларында укучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга бирелә. 2014 елның 1 сентябре хәленә карата әлеге субсидия алучылар булып 3 641 кеше тора.

Татарстан Республикасы Президентының «Берьюлы өч һәм аннан да күбрәк бала туугa бәйле рәвештә балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» 2008 ел, 20 август, ПУ-397 нче Указы нигезендә түбәндәгеләр түләнә:

берьюлы өч һәм аннан күбрәк бала туганда һәр балага 10 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие;

яшь ярымга кадәр берьюлы туган өч һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә һәр балага 1 мең сум күләмендә айлык пособие. Бер тапкыр бирелә торган пособие 6 балага түләнде, айлык пособие 12 балага түләнә.

тормыш хәлләре авыр булган һәм дәүләт ягыннан социаль ярдәмгә мохтаҗ балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары күрсәтү системасының әһәмиятле өлешләренең берсе булып эзлекле рәвештә тормышка ашырыла торган халыкка дәүләт социаль ярдәме күрсәтү программасы тора.

Дәүләт социаль ярдәмен алучылар арасында керемнәре дәрәҗәсе түбән булуга бәйле рәвештә үз тормыш проблемаларын мөстәкыйль хәл итәргә реаль мөмкинлекләре булмаган гражданнар шактый зур өлеш тәшкил итә. Бу, беренче чиратта, инвалид балалы гаиләләр, тулы булмаган һәм күпбалалы гаиләләр.

Баланың иң беренче һәм мөһим хокукларыннан берсе – гаиләгә хокук. Нәкъ менә гаилә мохите балага шәхес буларак формалашырга һәм җәмгыятьтә яшәргә әзерләнергә мөмкинлек бирә. Шуңа күрә балачакны яклауның беренче дәрәҗәдәге бурычы – бала өчен аның туган гаиләсен саклап калу, аны тернәкләндерү, баланы тәрбияләү өчен шартлар тудыра алмаслык хәлдә калган очракта гаиләне торгызу.

Гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар саны

| | 2010 ел, 1 гыйнвар | 2011 ел, 1 гыйнвар | 2012 ел, 1 гыйнвар | 2013 ел, 1 гыйнвар | 2014 ел, 1 гыйнвар |
|---|---|---|---|---|---|
| Гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар саны, шул исәптән: | 10 828 | 10 999 | 11 102 | 11 005 | 10 991 |
| уллыкка (кызлыкка) алынган | 2 805 | 2 857 | 2 892 | 2 897 | 2 787 |
| опекадагы (попечительлектәге) | 5 952 | 5 959 | 5 896 | 5 697 | 5 625 |
| тәрбиягә алган гаиләләрдә | 2 071 | 2 183 | 2 314 | 2 411 | 2 579 |

Безнең республикада ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруның дәүләт ярдәме чаралары, ведомствоара хезмәттәшлек, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм халык белән бергә эшләү ярдәмендә ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны (алга таба – ятим балалар) гаиләгә урнаштыруда республикада соңгы елларда кайбер уңай тенденцияләр күренде.

Республикада соңгы биш ел эчендә:

бер ел эчендә ачыклана торган ятим балалар саны 36 процентка кимеде;

ятим балалар өчен дәүләт учреждениеләре саны 14 процентка кимеде;

әлеге учреждениеләрдә булган балалар саны 54 процентка кимеде.

Тормышларын җайга салуга мохтаҗ булган балалар саны кимеде (мәгълүматларның төбәк банкында исәптә 2009 елда - 1 363 кеше, 2010 елда – 1 344 кеше, 2011 елда – 1 218 кеше, 2012 елда – 1 116 кеше, 2013 елда - 1 002 кеше торды).

2013 елда гражданнар гаиләләренә 1 150 ятим бала тапшырылды, шулардан опекага (попечительлеккә) – 709 бала, тәрбиягә алучы гаиләгә – 264 бала, 177 бала уллыкка (кызлыкка) алынды, шул исәптән 34 инвалид бала.

Бүгенге көндә республикада интернат учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәле системасын булдыру буенча уңай тәҗрибә бар, аңа түбәндәгеләр керә:

уллыкка (кызлыкка) алучыларны һәм опекуннарны әзерләү (2012 елның 1 сентябреннән 10 вәкаләтле оешма әзерлек гамәлгә ашыра). 2014 елда вәкаләтле оешмаларда 517 гаилә әзерлек алды;

укуын тәмамлап чыгучыларны интернаттан соң тәэмин итү хезмәтләре эше (2009 елдан 14 хезмәт эшли);

тәрбиягә бала алган ата-аналарны тәэмин итү хезмәтләре эше (4 хезмәт).

Хәзерге вакытта бетерелә торган 2 балалар йорты базасында ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруга булышлык күрсәтү, алыштыручы гаиләләрне әзерләү һәм тәэмин итү зона үзәкләре (алга таба – Үзәкләр) төзелә. Үзәкләр эше Татарстан Республикасында гаиләләрнең уңышсызлыгын профилактикалау, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны тәрбиягә ала торган гаиләләрне әзерләү һәм комплексны тәэмин итү, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар учреждениеләрен тәмамлаучыларны, алар арасындагы затларны җәмгыятьтә социальләштерү өчен интернаттан соң тәэмин итү системасын үстерү буенча уңай шартлар тудыруның нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итәргә ярдәм итәчәк.

Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары эшчәнлеге гаиләләрнең уңышсызлыгын кисәтү, балигъ булмаганнарның күзәтүчесез һәм караучысыз калуын профилактикалау, аларны адаптацияләү һәм тернәкләндерү, социаль ярдәм күрсәтүнең адреслылыгын тәэмин итү максатларында балалы гаиләләргә булышлык күрсәтү буенча закон актларын һәм максатчан программаларны үз вакытында һәм тулысынча гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән. Социаль хезмәт күрсәтүне оештыру балалы гаиләләргә булышлык күрсәтү проблемаларын хәл итүгә комплексны мөнәсәбәт булдыруны күздә тота.

Татарстан Республикасында гаиләләргә һәм балаларга социаль хезмәт күрсәтү системасы түбәндәге оешмалардан тора:

| Оешмаларның төрләре | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел *(2014 елның 1 октябре хәленә карата)* |
|---|---|---|---|---|---|
| Балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар | 24 | 21 | 21 | 21 | 21 |
| Балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләре | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар йортлары-интернатлар | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләре | 13 | 13 | 13 | 13 | 13 |
| Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча территориаль үзәкләр | 4 | 4 | 3 | 3 | 3 |
| Халыкка социаль ярдәм күрсәтүче комплекслы үзәкләрнең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекләре | 48 | 48 | 42 | 42 | 42 |
| Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча «Гаилә» республика мәгълүмат-методик үзәге | - | - | 1 | 1 | 1 |

2013 ел йомгаклары буенча тормыш хәле авыр булган һәм гаиләгә һәм балаларга социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларында социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланган гражданнар саны 460 758 кеше тәшкил итте, шул исәптән 228 427 балигъ булмаган зат (хөкем ителгәннәр санынннан 50,4 процент). Барлыгы 136 966 балалы гаиләгә, шул исәптән 19 331 күпбалалы гаиләгә, 35 784 тулы булмаган гаиләгә, аз керемле 67 716 гаиләгә, инвалид балалары булган 14 068 гаиләгә, качакларның һәм мәҗбүри күчеп килүчеләрнең 10 гаиләсенә хезмәт күрсәтелде.

Гаиләгә һәм балаларга социаль хезмәт күрсәтү оешмалары 2013 елда - 3 716 809, 2012 елда – 3 865 784, 2011 елда – 5 534 814, 2010 елда – 4 057 944, 2009 елда 4 063 363 социаль хезмәт күрсәтте.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау проблемасы иң актуаль булып тора, аны хәл итүгә профилактикалау системасының барлык субъектлары да кушылды.

Гаиләләрнең уңышсызлыгын иртә ачыклау белгечләрнең гаиләне торгызу һәм бала хокукларын яклау өчен кирәкле чыгымнарын һәм тырышлыкларын мөмкин кадәр киметергә, ата-аналарны нормаль яшәү рәвешенә кайтаруга юнәлдерелгән чаралар комплексын үткәрү өчен кирәкле ата-ана хокукларын чикләү практикасын ешрак кулланырга мөмкинлек бирә, болар ата-аналарны хокукларыннан мәхрүм итүләрне киметергә һәм балаларга биологик гаиләләрен саклап калырга ярдәм итәчәк.

Социаль хәле куркыныч булган балигъ булмаганнарны һәм аларның гаиләләрен ачыклау, исәпкә алу һәм алар белән индивидуаль тернәкләндерү эшен алып баруның ведомствоара тәртибе Социаль хәле куркыныч булган гаиләләргә һәм балаларга социаль патронажлык итеп тору ведомствоара муниципаль системасы турындагы нигезләмәгә, шулай ук Социаль хәле куркыныч булган балигъ булмаганнарның һәм аларның гаиләләренең бердәм мәгълүматлар банкын формалаштыру буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү турындагы нигезләмәгә таянып оештырылды.

Бу система кысаларында норматив-хокукый база, документлар әйләнешенең бердәм унификацияләнгән пакеты эшләнде.

Һәр муниципаль районда муниципаль районнарның башкарма комитетлары каршындагы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе карарлары белән ведомствоара системаның эшче органы – муниципаль социаль-тернәкләндерү консилиумы төзелде һәм эшләп килә.

Статистика мәгълүматлары нигезендә, 2014 елның 1 октябре хәленә карата Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә 2 025 гаиләдән максатчан төркемдәге 3 539 балигъ булмаган зат (барлыгы 3 825 балигъ булмаган зат) ведомствоара патронажлык итүгә тартылган.

Социаль хәле куркыныч булган гаиләләр (балалар) саны киму тенденциясе күзәтелә. Әгәр 2009 елда гаиләләрнең ведомствоара патронажлык итеп торуда исәптә торучылар саны уртача 2 700 дән 2 900 гә кадәр, 5 300 дән 5 700 гә кадәр бала тәшкил итсә (тиешенчә ел башына һәм ел азагына), 2014 елның 1 октябре хәленә карата бу саннар тиешенчә 2 025 (гаиләләр), 3 539 (балигъ булмаганнарның максатчан төркеме) тәшкил итте һәм ведомствоара патронажлык итеп торуда исәптә торучы балалар/гаиләләр саны киму тенденциясе дәвам итә.

2009 елдан Татарстан Республикасы социаль партнерлык кысаларында Тормыш хәле авыр булган балаларга ярдәм фонды (алга таба – Фонд) белән актив хезмәттәшлек итә. Фондның финанс ярдәме белән республикада тормыш хәле авыр булган балаларны (шул исәптән инвалид балаларны һәм аларның гаиләләрен) яклау буенча 7 инновацион технология кертелде.

Татарстан Республикасында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләр проблемаларын хәл итүгә инновацион ведомствоара мөнәсәбәтне алга таба кертү, бу гаиләләрне тәэмин итеп тору буенча ведомствоара хезмәттәшлек механизмын булдыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 16 ноябрь, 991 нче карары белән расланган «2012 - 2014 елларга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору системасын формалаштыру комплексы программасы» озак вакытлы максатчан программасы (алга таба – Комплексы программа) кабул ителде һәм 2012 – 2014 еллар дәвамында уңышлы эшләп килде.

Комплексы программаның төп үзенчәлеге булып тернәкләндерүнең ике төп звеносы – сәламәтлек саклау һәм социаль яклау системалары үзара тыгыз элемтәдә булу тора. Аерым ихтыяҗлары булган бала тәрбияләүче гаиләнең җәмгыятьтә интеграцияләнү процессына ярдәм итә торган өченче звено булып патронаж хезмәтләренең ярдәмчеләре буларак эшләүче ирекле затлар торды.

Комплексы программаны төп эшләүчеләр һәм үтәүчеләр булып Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм ике министрлык ведомство буйсынуындагы учреждениеләр торды.

Комплексы программаны Фонд тарафыннан финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Фонд һәм «Татарстан Республикасы психологлары ассоциациясе» коммерциягә карамаган партнерлыгы (алга таба - Грант алучы) арасында төзелгән программа чараларын үтәүгә грант рәвешендә акча

бүлеп бирү турындагы 2012 елның 30 ноябрендәге 22-РП4-ПБР килешүе (алга таба – Килешү) нигезендә гамәлгә ашырылды.

Комплекслы программа чаралары тормышка ашырылган ике ел эчендә Фонд 27 700,0 мең сумнан артык күләмдә акча бүлеп бирде. «2014 елга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору системасын формалаштыруның комплексы программасы» ярдәмче программасында күрсәтелгән кайбер уңай нәтиҗәләргә ирешелде: балалар патологиясен яшьтән ук ачыклау проценты шактый үсте һәм, тиешенчә, тернәкләндерү чаралары тагын да иртәрәк үткәрелә башлады, болар аларның нәтиҗәлелеген шактый арттырды. Сәламәтлегенең мөмкинлекләре чикләнгән бала яши торган гаиләләр проблемаларын хәл итүгә җирле бергәлек әгъзалары күбрәк җәлеп ителә башлады.

Комплекслы программа кабул итүнең актуальлеге шулай ук Россия Федерациясе Президентының сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалары булган гаиләләрне туган вакыттан башлап социаль хезмәткәр белән тәэмин итү турындагы 2011 ел, 15 март, Пр-653 нче кушкан эшләр исемлеген тормышка ашыру зарурлыгына бәяле.

Шулай да «Бюджет процессы камилләштерелүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел, 7 май, ФЗ-104 нче Федераль закон (алга таба – Федераль закон) кабул ителү белән, 2014 елдан башлап, федераль һәм төбәк дәрәҗәләрендә дәүләт программаларын формалаштыруның һәм тормышка ашыруның хокукый нигезләрен кертү белән бер үк вакытта озак вакытлы максатчан программаларны формалаштыруның һәм тормышка ашыруның хокукый нигезләре төшереп калдырылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын (алга таба – Программа) кабул итү белән Комплексы программа үз көчен югалтты.

Комплексы программада күздә тотылган чараларны 2014 елда тормышка ашыруны тәгәлләү, көтелә торган соңгы нәтиҗәләргә ирешү, шулай ук Фонд акчасы исәбеннән грант рәвешендә 1 654,537 мең сум күләмендә финанслашу максатларында, Программа составында, Федераль закон һәм Фонд таләпләрен исәпкә алып, «2014 елга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору системасын төзү комплексы программасы» дигән аерым ярдәмче программа эшләнде.

Кредит учреждениеләренең үзләрендә турыдан-туры аерым социаль ярдәм чараларын (айлык акчалата түләүләр, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә субсидия-ташламалар) билгеләүгә халыктан гаризалар кабул итү өлешендә 2012 елда территориаль социаль яклау органнарының кредит учреждениеләре белән үзара хезмәттәшлек итү механизмы кертелде.

Ведомствоара хезмәттәшлек итү тәртибендә алынган мәгълүматлар нигезендә хәзерге вакытта гамәлгә ашырыла торган медицина-социаль экспертиза

органнарында янадан таныклану үткән инвалидларга торак-коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә субсидия-ташламалар бирү процедурасы гадиләштерелде.

Хәзерге вакытта тармакта автоматлаштырылган процессларны, шул исәптән гражданнарның аерым категорияләренә пенсияләр исәпләү буенча мәгълүмат системасын; социаль ярдәм чараларыннан файдаланучыларның шәхси эшләрен электрон саклагыч; «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшчәнлеген автоматлаштыру» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын; «Татарстан Республикасы инвалидларының мәгълүматлар базасы» мәгълүмат системасын; «Татарстан Республикасында социаль хәле куркыныч булган балигъ булмаганнарны һәм аларның гаиләләрен исәпкә алу һәм мониторинглау» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кертү һәм үстерү буенча актив эш алып барыла.

Шулай ук Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү системасын алга таба камилләштерү эше (шул исәптән модернизацияләү юлы белән) дәвам иттерелә. Аның өстенлекле юнәлешләре булып түбәндәгеләр тора:

янгын куркынычсызлыгы таләпләренә һәм санитария-эпидемиология нормаларына туры килми торган социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре челтәрләрен оптимальләштерү, шул исәптән нәтиҗәсез эшләүче хезмәтләрне бетерү юлы белән;

Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә норматив хокукый җайга салуны (шул исәптән федераль законнар үзгәрүгә бәйле рәвештә) даими камилләштерү;

социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт учреждениеләренең матди-техник базасын модернизацияләү, шул исәптән аларда инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңайлы мохит булдыру;

социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге дәүләт стандартларын, норматив-җан башы исәбеннән финанслау механизмнарын, социаль хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт йөкләмәсен һәм дәүләт заказын камилләштерү һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшчәнлегенә алга таба кертү;

инновацион технологияләр кертү.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү системасын модернизацияләү һәм үстерү турында» 2006 ел, 3 июль, 335 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү системасын модернизацияләү һәм үстерү концепциясен тормышка ашыру кысаларында халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре инфраструктурасы оптимальләштерелде. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре үзгәртеп оештырылды, нәтиҗәсез эшләүче социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эш юнәлешен үзгәртте, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә һәм санитария-эпидемиология нормаларына җавап бирми торган учреждениеләр бетерелде. Социаль-савыктыру үзәкләре һәм ялгыз картлар өчен махсус торак йортлар муниципаль дәрәҗәгә тапшырылды. Социаль ашханәләр дәүләткә карамаган секторга күчерелде.

Оптимальләштерү чараларын үткәрү нәтиҗәсендә социаль хезмәтләр саны - 40 процентка, социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре саны 16,4 процентка кыскартылды. Янга калган бюджет ассигнованиеләре эш хакын арттыруга, капиталь ремонт үткәрүгә, шулай ук балалар йортлары-интернатларда койкалар челтәрен

арттыруга җибәрелде. Алдагы елларда чаралар дәвам иттерелде һәм 2013 елның 1 июле хәленә карата социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт учреждениеләре челтәре 132 учреждениедән торды, шуларның 28е - картлар һәм инвалидлар өчен интернат йортлар, 6 сы - психоневрология интернаты, 2 се - акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар йорты-интернат, 45е халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге, 3 гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәге һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре структурасында 42 гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләре, халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре структурасында 18 социаль-тернәкләндерү бүлеге, 7 инвалидларны тернәкләндерү үзәге, 13 мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәге, балигъ булмаганнар өчен 2 социаль-тернәкләндерү үзәге, билгеле яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен 3 социаль адаптация үзәге. Моннан тыш, республикада 2 республика методик үзәге – халыкка социаль-психологик ярдәм үзәге һәм гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм мәгълүмат-методик үзәге эшләп тора.

2007 елдан республикада өлкән яшьтәге гражданның һәм инвалидның социаль хезмәт күрсәтүгә булган шәхси ихтыяҗын бәяләү һәм якын туганнарының социаль хезмәт күрсәткән өчен түләүдә катнашуы нигезендә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга стационар социаль хезмәт күрсәтү һәм өйдә социаль хезмәт күрсәтү механизмы кертелде.

2011 – 2012 еллар эчендә социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү төрләре буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының 7 стандарты эшләнде һәм кертелде. Социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшчәнлеген дәүләт хезмәтләре күрсәтү стандарты сыйфаты нигезендә төзү дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатын һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген алга таба күтәрүгә юнәлдерелде, шул исәптән аларның эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген тикшерү системасын булдыру исәбенә. Нәтиҗәдә бу дәүләт хезмәтләре күрсәтүдән файдаланучыларның канәгать булу дәрәҗәсен арттырырга тиеш.

2012 елда социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт учреждениеләре тарафыннан тормыш хәле авыр булган 600 меңнән артык Татарстан Республикасы гражданына хезмәтләр күрсәтелде. Шуның белән бергә, кайбер категорияле гражданнарның стационар социаль хезмәт күрсәтүгә булган ихтыяҗы канәгатьләндерелми кала.

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче затлар санынннан өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларның махсус йорт - интернатка булган чиратын бетерү максатларында, 2010 елда Мамадыш картлар һәм инвалидлар йорты, койкалар челтәре 50 койка-урыннан 70 койка-урынга кадәр арттырылып, картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат йорт итеп үзгәртелде.

2011 елда Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының шәһәр тибындагы Кама Аланы поселогында 400 койка-урынга исәпләнгән психоневрология интернаты ачылды, шуңа күрә психик авырулар белән интегүче өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның психоневрология интернатларында урыннар белән тәэмин ителү дәрәҗәсе 80 проценттан 88 процентка кадәр артты. Учреждениене ачу психоневрология интернатларына чиратны 1,5 тапкырга киметергә мөмкинлек бирде.

Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар йортлары-интернатларга чиратны бетерү максатларыннан чыгып, 2012 елда акыл үсеше артта калган балалар өчен эшләп торучы балалар йортлары-интернатларның куәте 15 койка-урынга арттырылды.

Республикада балигъ булмаган балаларны, шулай ук балалы гаиләләрне социаль яклау системасы алга киткән.

Татарстан Республикасында халыкны социаль яклау өлкәсендә тормышка ашырыла торган дәүләт сәясәтенең өстенлекләре булып түбәндәгеләр тора:

гражданнарга халыкны социаль яклау өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүне сыйфатка һәм алардан һәркем файдалана алу мөмкинлеге таләпләреннән чыгып камилләштерү;

гаиләдә баланы саклауны тәэмин итүче гаиләне социаль яклау системасын ныгыту, тормышта авыр хәлгә юлыккан балаларның үсеше һәм тереклек эшчәнлеге өчен уңай шартлар тудыру, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруның төрле формаларын үстерү;

гражданнарга, беренче чиратта ветераннарга һәм инвалидларга, социаль хезмәт күрсәтү системасын камилләштерү;

социаль инфраструктураның өстенлекле объектларына инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тарафыннан тоткарлыксыз керү һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген, тереклек эшчәнлегенең төп чикләнүләреннән чыгып, аларның аерым ихтыяҗларын исәпкә алып тәэмин итү.

Яңа технологияләр кертмичә, инновацион мөнәсәбәтләр булдырмыйча, шулай ук электрон формада дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә күчмичә халыкны социаль яклау өлкәсендә дәүләтнең социаль йөкләмәләре үтәлешен камилләштерү, хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның киң даирәсенә сыйфатлы дәүләт хезмәтләре күрсәтү дәрәҗәсен күтәрү мөмкин түгел.

## II. Программаның төп максатлары, бурычлары һәм көтелә торган соңгы нәтиҗәләре тасвирнамәсе, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Хәзерге вакытта халыкка социаль ярдәм күрсәтү, өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге гамәлдәге законнар һәм билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә гражданнарның социаль гарантияләрен тормышка ашыру Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең мөһим юнәлеше булып тора.

Моннан тыш, җәмгыятьтә гаилә, бала, җаваплы ата-ана булу кыйммәтләрен формалаштыру; гаиләнең уңышсызлыгын иртә ачыклауга; тормыш хәле авыр булган гаиләгә ведомствоара нигездә күрсәтелә торган шәхсиләштерелгән адекват ярдәмгә нигезләнгән профилактикалауны тәэмин итү; баланы туган гаиләсендә тәрбияләү өстенлеге, социаль хәле куркыныч булган гаиләләр санын киметү; ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү очракларын киметүгә, «куркыныч төркеменә» керә торган гаиләләрне ачыклауга, аларны социаль тәэмин итүгә һәм тернәкләндерүгә, гаиләдә балаларга карата рәхимсез булу очраклары санын киметүгә ярдәм итә торган нәтиҗәле механизмнар булдыру, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар санын киметү иң актуаль булып тора.

Программаның максаты – социаль ярдәм һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәле адреслы системасын булдыру, шулай ук аерым категорияле гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

тормыш сыйфатын күтәрү һәм Татарстан Республикасы гражданнарының аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларын күрсәтү;

өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү;

үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне тәэмин итеп тору буенча ведомствоара хезмәттәшлек механизмын булдыру;

гаиләләрне һәм гаилә тормышы кыйммәтләрен ныгыту, аларга булышлык күрсәтү, гаиләләрнең тормыш сыйфатын күтәрү;

Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге өстенлекле объектларга керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу дәрәҗәсен күтәрү;

Татарстан Республикасында инвалидларны социаль интеграцияләү һәм тернәкләндерү системасын мәгълүмати-методик яктан һәм кадрлар белән тәэмин итү;

җәмгыятьтә социаль таркаулыкны бетерү һәм инвалидлар проблемаларына һәм Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен тереклек эшчәнлегенең уңай мохитен тәэмин итү проблемасына карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру;

3 яшькә кадәрге балаларның тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту;

ятим балаларны һәм ата-ана кайтыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру өчен уңай шартлар тудыру.

Әлеге максатларга һәм бурычларга ирешү тормышка ашыруга каралган сигез ярдәмче программа кысаларда гамәлгә ашырылачак:

2014 – 2020 елларга «Социаль түләүләр»;

2014 – 2020 елларга «Өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү»;

2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү»;

2014 елга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору системасын формалаштыру комплекслы программасы»;

2015 – 2020 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту»;

2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит»;

2014 елга «Бәләкәч – Малыш»;

2014 елга «Опекуннарга һәм тәрбиягә бала алган ата-аналарга дәүләт ярдәме күрсәтү».

Ярдәмче программалар яктылыгында Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары турындагы мәгълүматлар бу Программага теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелә.

Программаны тормышка ашыру вакытлары: 2014 – 2020 еллар.

## III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 171 804 670,42 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 126 952 950,266 мең сум; билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелгән федераль бюджет акчасы – 44 836 193,717 мең сум, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидияләр – 13 871,900 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан – 1 654,537 мең сум (2013 елда Тормыш хәле авыр булган балаларга ярдәм фондыннан алынган тотылмый калган акча).

мең сум

| Ел | Гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүгә акча күләме, барлыгы | Шул исәптән | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | федераль бюджет акчасы | Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия | бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2014 | 22 093 722,520 | 16 070 809,883 | 6 007 386,200 | 13 871,900 | 1 654,537 |
| 2015 | 23 089 730,7 | 16 622 302,983 | 6 467 427,717 | - | - |
| 2016 | 23 141 154,1 | 17 139 160,2 | 6 001 993,9 | - | - |
| 2017 | 24 327 863,9 | 18 132 505,8 | 6 195 358,1 | - | - |
| 2018 | 25 369 288,7 | 18 907 530,2 | 6 461 758,5 | - | - |
| 2019 | 26 404 974,0 | 19 678 283,1 | 6 726 690,9 | - | - |
| 2020 | 27 377 936,5 | 20 402 358,1 | 6 975 578,4 | - | - |
| Барлыгы | 171 804 670,42 | 126 952 950,266 | 44 836 193,717 | 13 871,900 | 1 654,537 |

Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Программаны ресурслар белән тәэмин итү буенча җентекле мәгълүмат Программага теркәлгән 2 нче кушымтада китерелә.

## IV. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысы булып Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тора.

Программаның дәүләт заказчылары булып Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәдәният

министрлыгы, Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе, Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды тора.

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Программаның дәүләт заказчылары белән үзара хезмәттәшлек итеп, Программаны тормышка ашыру процессында уртак эшчәнлекне яраштыруны, кирәк булганда аңа үзгәрешләр кертүне, шулай ук Программаның нәтиҗәлелеген бәяләүне, чираттагы финанс елына бюджет ихтыяҗын формалаштыруны тәэмин итә.

Программаның дәүләт заказчылары квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 15 енә кадәр, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Программа чараларын тормышка ашыру, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә (алга таба – Тәртип) теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форманы тутырып, финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында статистика, белешмә һәм аналитик мәгълүмат кертә.

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 25 енә кадәр, Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына Программаны тормышка ашыру, шулай ук Тәртипкә теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форманы тутырып, финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында җыелма статистика, белешмә һәм аналитик мәгълүмат кертә.

## V. Программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

2020 елга кадәрге чорга Идел буе федераль округының социаль-икътисадый үсеш стратегиясенең төп өстенлекләреннән берсе булып халыкның тормыш шартларын һәм социаль мохит сыйфатын яхшырту билгеләнгән, шуңа күрә Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләре Татарстан Республикасының стратегик максатларына ирешүдә зур әһәмияткә ия.

Күрсәтелгән юнәлешләр буенча үткәреләэ торган чаралар, социаль юнәлешнең башка чаралары белән берлектә, кайбер төп бурычларны хәл итүгә – халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын эзлекле рәвештә күтәрүгә, халыкның җан башына керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумына житкән яки аларга социаль ярдәм (шул исәптән дәүләт социаль ярдәме) чараларын күрсәтү хисабына аннан артып киткән гражданнар саны артуга булышлык күрсәтәчәк.

Халыкка күрсәтелә торган адреслы социаль ярдәмне көчәйтү ярлылык процентын киметергә, җәмгыятьтәге социаль климатны яхшыртырга, шулай ук барлык дәрәҗәдәге бюджетлар акчасын тагын да нәтиҗәлерәк файдаланырга мөмкинлек бирәчәк.

Балалы гаиләләргә социаль ярдәм чараларын тормышка ашыру һәр гаиләнең, бигрәк тә күпбалалы гаиләнең, керемнәрен арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруны камилләштерү гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрүгә, аларның физик һәм психик сәламәтлеген тиешле дәрәҗәдә тотуга булышачак.

2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына 1 нче кушымта

## 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| Максатның исеме | Бурычның исеме | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, процент | Индикаторларның мәгънәләре | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2013 ел (база) | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| Социаль ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәле адреслы системасын булдыру һәм социаль хезмәтләр күрсәтү, шулай ук гражданнарның аерым категорияләре тормыш сыйфатын күтәрү | Татарстан Республикасының аерым категорияле гражданнарына социаль ярдәм чараларын күрсәтү һәм аларның тормыш сыйфатын күтәрү | Хәрби хезмәткәрләрнең йөкле хатыннарына бер тапкыр бирелә торган пособиеләрне, хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр балаларына айлык пособиеләрне тулы күләмдә бирү | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - |
| | | Социаль яклау органнарына мөрәҗәгать иткән аз керемле гражданнарның гомуми санында керемнәре яшәү минимумы күләменә кадәр җиткерелгән һәм социаль ярдәм чараларын күрсәтү хисабына аннан югарырак булган гражданнар өлеше | 25,5 | 25,8 | - | - | - | - | - | - |
| | | Татарстан Республикасында гаиләләрнең гомуми санында торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә торак субсидияләре алган гаиләләр өлеше | 8,4 | 8,3 | - | - | - | - | - | - |
| | | Балага айлык пособиене тулы күләмдә бирү | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - |
| | | Берьюлы өч һәм аннан да күбрәк туган бала тәрбияләүче гаиләләргә пособиеләрне тулы күләмдә бирү | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - |
| | | Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә тулы күләмдә компенсация бирү | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - |
| | | «Ата-ана даны» ордены белән бүләкләнгән ана-аналарга (уллыкка (кызлыкка) алучыларга), «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән аналарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне тулы күләмдә бирү | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Дәүләт һөнәр белеме бирүче мәгариф оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга социаль түләүләрне тулы күләмдә бирү | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - |
| | | Вакцинациядән соң өзлегүләр барлыкка килгәндә гражданнарга тулы күләмдә пособиеләр һәм компенсацияләр бирү | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәләре буенча инвалидларга иминият премияләре компенсацияләрен тулы күләмдә бирү | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - |
| | | Социаль яклау органнарына мөрәҗәгать иткән аз керемле гражданнарның гомуми санында керемнәре яшәү минимумы күләменә кадәр җиткерелгән һәм социаль ярдәм чараларын күрсәтү хисабына аннан югарырак булган гражданнар өлеше | 25,5 | 25,8 | 25,9 | 26,0 | 26,0 | 26,1 | 26,1 | 26,1 |
| | | Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәвалану алучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарына тулы күләмдә компенсацияләр бирү | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә субсидия-ташламаларны тулы күләмдә бирү | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Даими рәвештә кеше каравына мохтаж инвалид балаларга айлык акчалата түләү бирү | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин ителгән гражданнар саны, кеше | 5 407 | 5 677 | 5 860 | 6 150 | 6 150 | 6 150 | 6 150 | 6 150 |
| | | Планлаштырылган оештыру һәм социаль әһәмияткә ия булган чараларны тулы күләмдә үткәрү | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Гражданнар түләүгә керткән торак сатып алу турындагы шартнамәләрне финанслауны тулы күләмдә тәэмин итү | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Күмүгә социаль пособие бирү һәм күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча чыгымнарны тулы күләмдә каплау | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «СССРның мактаулы доноры», «Россиянең мактаулы доноры» билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне тулы күләмдә бирү | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Гаиләләрдән, балалар йортларыннан, интернат мәктәпләрдән, махсус уку-укыту-тәрбия һәм башка балалар учреждениеләреннән рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны транспортта йөртү чыгымнарына түләү | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Онкология авырулары белән интегүче затларга махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренә дәвалану урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарына компенсацияләрне тулы күләмдә бирү | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Республика тернәкләндерү техник чаралары исемлеге нигезендә инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - |
| | | Яшь белгечләр – җәза-үтәтү системасы табибларына билгеләнгән социаль түләүләрне тулы күләмдә бирү | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - |
| | | Вакытлыча эшкә яраксыз булу очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерелергә тиеш булмаган гражданнарга дәүләт пособиеләрен тулы күләмдә түләү | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль ярдәмнең аерым чараларын тулы күләмдә күрсәтү | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Һөнәр белеме бирү оешмаларында белем алучыларны туклану белән тулы күләмдә тәэмин итү | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | Өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү | Социаль ярдәм чараларын алу хисабына өлкән яшьтәге гражданнарның керемнәре арту (2030 елга кадәр Россия Федерациясен социаль-икътисадый үстерүнең озак вакытлы фаразы инфляция индексыннан түбән итмичә) Россия Федерациясен озак вакытлы социаль-икътисадый үстерү фаразы инфляциясе индексыннан түбән итмичә | 6,5 | 6,7 | 6,7 | 7,0 | 7,2 | 7,4 | 7,7 | 7,9 |
| | | Теш протезлары һәм (яки) колак аппаратлары ясату хезмәте күрсәтүләрдән файдаланган гражданнар өлеше | 95,0 | 95,4 | 95,6 | 95,8 | 95,9 | 96 | 96,4 | 96,6 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Хокуклары булган һәм алуга гариза биргәннәр санынннан тиешле елларны эшләгән өчен пенсияләр һәм пенсиягә өстәмә түләүләр алуга хокукын тормышка ашырган дәүләт граждан (муниципаль) хезмәткәрләре өлеше | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Хокуклары булган һәм алуга гариза биргәннәр санынннан дәүләт пенсиясенә өстәмәләр алу хокукын тормышка ашырган Татарстан Республикасы алдында аерым казанышлары булган гражданнар өлеше | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Хокуклары булган һәм алуга гариза биргәннәр санынннан тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү алган дәүләт граждан (муниципаль) хезмәткәрләре өлеше | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Гомерлек айлык тулы керемен, эштән чыкканда бирелә торган пособие, шулай ук матди һәм социаль тәэмин итүнең башка чараларын алган гражданнар өлеше, аларны алырга хокуклары булган затлар санынннан | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Хокуклары булган һәм алуга гариза биргәннәр санынннан вакытыннан алда пенсияләр алу хокукларын тормышка ашырган ашыгыч медицина ярдәме станцияләре хезмәткәрләре өлеше | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Хокуклары булган һәм алуга гариза биргәннәр санынннан түләүсез юридик ярдәм алуга хокукларын тормышка ашырган гражданнар өлеше | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдалануга хокуклары булган һәм аннан файдалану өчен социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына мөрәҗәгать иткән гражданнарның гомуми санында социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларында социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланган гражданнар өлеше | 95,6 | 95,6 | 96,0 | 98,7 | 99,0 | 100 | 100 | 100 |
| | | Татарстан Республикасы балаларының гомуми санында күзәтүчесез балаларның чагыштырма авырлыгы | 0,41 | 0,40 | 0,39 | 0,39 | 0,39 | 0,38 | 0,38 | 0,38 |
| | | Эшчәнлекләре билгеләнгән критерийларга (стандартларга) туры килми торган халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары өлеше | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлык милек рәвешендәге социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында хезмәт күрсәтүләрдән файдаланган өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның (өлкәннәрнең һәм балаларның) гомуми санында социаль хезмәт күрсәтүче дәүләткә карамаган оешмаларда хезмәт күрсәтүләрдән файдаланган өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның (өлкәннәрнең һәм балаларның) чагыштырма авырлыгы | 4,5 | 4,5 | 4,6 | 4,7 | 4,8 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| | | Барлык милек рәвешендәге оешмаларның гомуми саныннан социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләткә карамаган оешмаларның чагыштырма авырлыгы | 0,7 | 0,7 | 0,7 | 1,4 | 1,4 | 1,4 | 1,4 | 1,4 |
| | | Татарстан Республикасында фаразлана торган уртача эш хакы белән социаль хезмәткәрләрнең уртача эш хакы чагыштырмасы | 56 | 56 | 68,5 | 79 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының гомуми санында СанПиН нормаларына кадәр җиткерелгән социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының чагыштырма авырлыгы | 50.0 | 50.5 | 59.7 | 70.1 | 80.4 | 94.2 | 95,0 | 95,0 |
| | | Өлкәннәргә кичектергесез социаль һәм медицина-социаль хезмәтләр күрсәтү буенча мобиль бригадалар эшчәнлеген тәэмин итү өчен яңа автотранспорт белән җиһазландырылган социаль хезмәт күрсәтүче территориаль комплекслы үзәкләрнең чагыштырма авырлыгы | 11,1 | 46,6 | - | - | - | - | - | - |
| | Үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне тәэмин итеп тору буенча ведомствоара хезмәттәшлек механизмын булдыру | Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 4 яшькә кадәрге балаларның гомуми санында яштән үк чара күрү кабинетларында тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүдән файдаланган сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 4 яшькә кадәрге балаларның чагыштырма авырлыгы | 10.5 | 11 | - | - | - | - | - | - |
| | | Ведомствоара патронажлык итеп тору хезмәте тарафыннан ачыкланганнар һәм исәпкә куелганнар арасыннан 2014 ел эчендә үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны ведомствоара патронажлык итеп торуга тарту | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - |
| | | Ведомствоара патронажлык итеп тору хезмәте шөгыльләнә торган гаиләләрнең гомуми саныннан социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең көндез була торган бүлекләрендә | 85 | 90 | - | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланган (бала авыруының авырлыгын исәпкә алып) үсеш-ләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрнең чагыштырма авырлыгы | | | | | | | | |
| | Гаиләне һәм гаилә тормышы кыйммәт-ләрен ныгыту, аларга булышлык күрсәтү, гаиләләрнең тормыш сыйфатын күтәрү | Хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәр-би хезмәткәрләрнең йөкле хатыннарына бер тапкыр бирелә торган һәм хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр балаларына айлык пособиеләрне тулы күләмдә бирү | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Социаль яклау органнарына мөрәҗәгать иткән аз керемле гражданнарның гомуми санында керемнәре яшәү минимумы күләменә кадәр җиткән яки аларга социаль ярдәм итү чараларын күрсәтү хисабына аннан артып киткән гражданнар (шул исәптән күпбалалы гаиләләр) өлеше | - | 25,8 | 25,9 | 26,0 | 26,0 | 26,1 | 26,1 | 26,1 |
| | | Татарстан Республикасындагы гаиләләрнең гомуми санында торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә торак субсидияләрен алган гаиләләр өлеше | - | 8,3 | 8,3 | 8,2 | 8,2 | 8,2 | 8,1 | 8,1 |
| | | Балага айлык пособиене тулы күләмдә бирү | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә пособиеләрне тулы күләмдә бирү | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү про-граммасын тормышка ашыручы мәгариф оешма-ларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компен-сацияне тулы күләмдә бирү | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Дәүләт һөнәр белеме бирүче мәгариф оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга социаль түләүләрне тулы күләмдә бирү | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Түләүсез нигездә махсус балалар туклануы продуктларын алган, җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасы террито-риясендә билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган гаиләләрдән өч яшькә кадәрге балаларның чагыштырма авырлыгы | - | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Түләүсез нигездә табиблар рецептлары буенча махсус балалар туклануы продуктларын алган хроник авырулары булган өч яшькә кадәрге балаларның чагыштырма авырлыгы | - | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| | | Балалар туклануын житештерү өчен файдаланыла торган сөткә базар бәясе һәм теркәлгән бәяләр арасындагы аерманы тулы күләмдә каплау | - | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| | | Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруның барлык формаларында бер тапкыр бирелә торган пособиене тулы күләмдә бирү | - | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| | | Опекага алынган балаларны карап торуга тәрбиягә бала алган гаиләгә бүләкләүне тулы күләмдә бирү | - | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| | | Опекага алынган балаларны карап торуга тәрбиягә бала алган гаиләгә түләүне тулы күләмдә бирү | - | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| | | Опекага алынган балаларны карап торуга опекуннар гаиләләренә түләүне тулы күләмдә бирү | - | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| | | Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән затларны, таныклык биреп, 80 сәгатьлек программа буенча вәкаләтле оешмаларда өйрәтү | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өлеше | - | 98,7 | 98,8 | 98,8 | 98,8 | 98,8 | 98,8 | 98,8 |
| | | «Ата-ана даны» ордены белән бүләкләнгән ана-аналарга (уллыкка (кызлыкка) алучыларга), «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән аналарга бер тапкыр бирелә торган бүләкләүне тулы күләмдә бирү | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | Никахларын дәүләт теркәвенә алу өчен гариза биргән гражданнарны, яшь гаилә мәктәбе/клубы дәресләренә тарту | - | 15 | 17 | 20 | 23 | 25 | 27 | 30 |
| | | Гомуми белем бирү мәктәпләрендә «Гаилә белеме» курсы буенча дәресләр үткәрү | - | да | да | да | да | да | да | да |
| | | Татарстан Республикасы гаиләләренә «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медальләрен тапшыру | - | да | да | да | да | да | да | да |
| | | Татарстан Республикасының иң яхшы гаиләләре хөрмәтенә Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миннеханов һәм аның хатыны Г.Ә.Миңнеханова исеменнән тантанлы кабул итү мәҗлесе үткәрү | - | да | да | да | да | да | да | да |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне» бөтенроссия ир белән хатын мәхәббәте һәм гаилә бәхете көнен оештыру һәм үткәрү | - | да | да | да | да | да | да | да |
| | | Халыкара гаилә көнен оештыру һәм үткәрү | - | да | да | да | да | да | да | да |
| | | Никахны тантаналы рәвештә теркәгән вакытта яңа өйләнешүчеләргә «Гаилә битләре» белешмә ярдәмлеген тапшыру | - | да | да | да | да | да | да | да |
| | | Татарстан Республикасы балаларының гомуми санында күзәтүчесез балаларның чагыштырма авырлыгы | - | 0,40 | 0,39 | 0,39 | 0,39 | 0,38 | 0,38 | 0,38 |
| | | Тернәкләндерү вакытларын арттырмыйча уңай нәтиҗәләр белән ведомствоара тәэмин итүдән алынган балалы гаиләләр өлеше | - | 80,8 | 80,9 | 80,9 | 81,0 | 81,0 | 81,1 | 81,1 |
| | Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге өстенлекле объектларга керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу дәрәҗәсен күтәрү | Өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен керә алырлык булган социаль, транспорт, инженерлык инфраструктурасының өстенлекле объектлары өлеше | 16,8 | 30,9 | 45 | - | - | - | - | - |
| | | Хәрәкәт итүче бу состав паркында халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәрен йөртү өчен җиһазландырылган гомуми файдаланудагы автомобиль һәм җир өсте шәһәр электр транспортының хәрәкәт итүче составы паркы өлеше | 8,3 | 10,0 | 11,7 | - | - | - | - | - |
| | | Һөнәр белеме бирүче оешмаларның һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының гомуми санында инвалидларның һәм үсешләрендә бозыклыклар булмаган затларның бергә укуын тәэмин итүче универсаль киртәсез мохит булдырылган һөнәр белеме бирүче оешмалар һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары өлеше | 4,9 | 11,8 | 15,4 | - | - | - | - | - |
| | | Системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге инвалидлар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның халыкның әлеге категориясе гомуми санындагы өлеше | 13,9 | 14,5 | 15,0 | - | - | - | - | - |
| | Җәмгыятьтә социаль таркаулыкны бетерү һәм инвалидлар проблемаларына һәм һәм Татарстан Республикасында инвалидлар | Сораштырылган инвалидларның гомуми санында инвалидлар проблемаларына халыкның мөнәсәбәтен уңай бәяләүче инвалидлар өлеше | 40,8 | 45,2 | 49,6 | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен тереклек эшчәнлегенең уңай мохитен тәэмин итү проблемасына карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру | | | | | | | | | |
| | Татарстан Республикасында инвалидларны тернәкләндерү һәм социаль интеграцияләү системасын мәгълүмати-методик яктан һәм кадрлар белән тәэмин итү | Инвалидларны тернәкләндерү, социаль интеграцияләү мәсьәләләре буенча өйрәтелгән һәм квалификациясен күтәргән белгечләр өлеше, бу өлкәдә эшләүче белгечләрнең барлык санында | 11,0 | 19,0 | 26,0 | - | - | - | - | - |
| | 3 яшькә кадәрге балаларның тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту | Түләүсез нигездә махсус балалар туклануы продуктлары алган, җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрдән өч яшькә кадәрге балаларның чагыштырма авырлыгы | 100,0 | 100,0 | - | - | - | - | - | - |
| | | Түләүсез нигездә табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус продуктлар алган хроник авырулары булган өч яшькә кадәрге балаларның чагыштырма авырлыгы | 100,0 | 100,0 | - | - | - | - | - | - |
| | | Балалар туклануын житештерү өчен файдаланыла торган сәткә базар һәм теркәлгән бәяләр арасындагы аерманы тулы күләмдә каплау | 100,0 | 100,0 | - | - | - | - | - | - |
| | Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру өчен уңай шартлар тудыру | Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруның барлык формаларында бер тапкыр бирелә торган пособиене тулы күләмдә бирү | 100,0 | 100,0 | - | - | - | - | - | - |
| | | Тәрбиягә бала алган гаиләгә опекага алынган балаларны карап торуга бүләкләүне тулы күләмдә бирү | 100,0 | 100,0 | - | - | - | - | - | - |
| | | Тәрбиягә бала алган гаиләгә опекага алынган балаларны карап торуга түләүләрне тулы күләмдә бирү | 100,0 | 100,0 | - | - | - | - | - | - |
| | | Опекага алган гаиләләргә опекага алынган балаларны карап торуга түләүләрне тулы күләмдә бирү | 100,0 | 100,0 | - | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләге булган затларны, таныклык биреп, 80 сәгатьлек программа буенча вәкаләтле оешмаларда өйрәтү | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - |
| | | Гражданнар гаиләләрендә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өлеше | 98.7 | 98.7 | - | - | - | - | - | - |

2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына 2 нче кушымта

## 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын тормышка ашыруның ресурслар белән тәэмин ителеше

(мең сум)

| Ярдәмче программаның исеме | Финанслау чыганагы | Финанслау күләме | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 2014 – 2020 елларга «Социаль түләүләр» | Татарстан Республикасы бюджеты<br>федераль бюджет | 4 522 747,9<br>5 768 163,1 | 310 393,3<br>6 211 092,7 | 323 992,8<br>5 958 035,4 | 337 572,5<br>6 165 582,6 | 351 736,4<br>6 430 702,7 | 365 822,3<br>6 694 361,7 | 379 054,9<br>6 942 053,0 |
| 2014 – 2020 елларга «Өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү» | Татарстан Республикасы бюджеты<br>федераль бюджет | 6 618 740,1<br>- | 6 643 647,5<br>- | 6 900 204,4<br>- | 7 047 723,3<br>- | 7 346 453,9<br>- | 7 643 538,1<br>- | 7 922 630,4<br>- |
| 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» | Татарстан Республикасы бюджеты<br>федераль бюджет<br>Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджеты | 3 173 214,625<br>-<br>13 871,9 | 3 408 478,7<br>-<br>- | 3 700 135.7<br>-<br>- | 4 266 980,1<br>-<br>- | 4 450 460,2<br>-<br>- | 4 632 929,0<br>-<br>- | 4 804 347,4<br>-<br>- |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2014 елга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору системасын формалаштыру комплекслы программасы | Татарстан Республикасы бюджеты<br><br>бюджеттан тыш чыганаклар | 12 803, 075<br><br>1 654.537 | -<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- |
| «2015 – 2020 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту» | Татарстан Республикасы бюджеты<br><br>федераль бюджет | -<br><br>- | 5 949 257,1<br><br>40 545,5 | 6 214 827,3<br><br>43 958,5 | 6 480 229,9<br><br>29 775,5 | 6 758 879,7<br><br>31 055,8 | 7 035 993,7<br><br>32 329,2 | 7 296 325,4<br><br>33 525,4 |
| 2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» | Татарстан Республикасы бюджеты<br><br>федераль бюджет | 310 526,383<br><br>215 789,500 | 310 526,383<br><br>215 789,517 | -<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- |
| 2014 елга «Бәләкәч – Малыш» | Татарстан Республикасы бюджеты<br>федераль бюджет | 459 283,0<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- |
| 2014 елга «Опекуннарга һәм тәрбиягә бала алган ата-аналарга дәүләт ярдәме күрсәтү» | Татарстан Республикасы бюджеты<br><br>федераль бюджет | 973 494,8<br><br>23 433,6 | -<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- | -<br><br>- |
| Программа буенча барлыгы, шул исәптән: | | 22 093 722 ,520 | 23 089 730,7 | 23 141 154,1 | 24 327 863,9 | 25 369 288,7 | 26 404 974,0 | 27 377 936,5 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | | 16 070 809,883 | 16 622 302,983 | 17 139 160,2 | 18 132 505,8 | 18 907 530,2 | 19 678 283,1 | 20 402 358,1 |
| федераль бюджет | | 6 00 386,2 | 6 467 427,717 | 6 001 993,9 | 6 195 358,1 | 6 461 758,5 | 6 726 690,9 | 6 975 578,4 |
| Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджеты | | 13 871,90 | - | - | - | - | - | - |
| бюджеттан тыш чыганаклар | | 1 654.537 (2013 елда Тормыш хәле авыр булган балаларга ярдәм фондыннан алынган тотылмый калган акча) | - | - | - | - | - | - |

2014 – 2020 елларга «Социаль түләүләр»
ярдәмче программасы

Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | 2014 – 2020 елларга социаль түләүләр (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысы | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| Ярдәмче программаның максаты | Татарстан Республикасының аерым категорияле гражданнары тормыш сыйфатын күтәрү һәм аларның социаль ярдәм итү чараларына хокукларын тәэмин итү |
| Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Гражданнарның аерым категорияләренә федераль һәм республика законнары белән билгеләнгән социаль ярдәм итү чараларын күрсәтү.<br>2. Һөнәр белеме бирү оешмаларында белем алучыларны туклану белән тәэмин итү |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2020 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 50 761 311,3 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 6 591 320,1 мең сум; федераль бюджет акчасы исәбеннән – 44 169 991,2 мең сум. |

мең сум

| Ел | Социаль түләүләргә акча күләме, барлыгы | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | федераль бюджет акчасы |

<table>
<tr>
<td></td>
<td>
<table>
<tr><td>2014</td><td>10 290 911,0</td><td>4 522 747,9</td><td>5 768 163,1</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>6 521 486</td><td>310 393,3</td><td>6 211 092,7</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>6 282 028,2</td><td>323 992,8</td><td>5 958 035,4</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>6 503 155,1</td><td>337 572,5</td><td>6 165 582,6</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>6 782 439,10</td><td>51 736,4</td><td>6 430 702,7</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>7 060 184,0</td><td>365 822,3</td><td>6 694 361,7</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>7 321 107,9</td><td>379 054,9</td><td>6 942 053,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>50 761 311,3</td><td>6 591 320,1</td><td>44 169 991,2</td></tr>
</table>
Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш
</td>
</tr>
<tr>
<td>Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)</td>
<td>Ярдәмче программаны тормышка ашыру ел саен 2020 елга кадәр түбәндәгеләрне тулы күләмдә бирүне тәэмин итәргә ярдәм итәчәк:<br>вакцинациядән соң өзлегүләр барлыкка килгәндә пособиеләрне һәм компенсацияләрне;<br>танспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәләре буенча иминият премияләре компенсацияләрен;<br>хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән интегүче затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарына компенсацияләрне;<br>авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә субсидия-ташламаларны;<br>даими рәвештә кеше каравына мохтаҗ инвалид балаларга айлык акчалата түләүне;<br>күмүгә социаль пособиене һәм күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча чыгымнарны каплауны;<br>«СССРның мактаулы доноры», «Россиянең мактаулы доноры» билгеләре белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне;<br>гаиләләрдән, балалар йортларыннан, интернат мәктәпләрдән, махсус уку-укыту-тәрбия һәм башка балалар учреждениеләреннән рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны транспортта йөртү чыгымнарын түләүне;<br>һөнәр белеме бирү оешмаларында белем алучыларга тукланууны;<br>республика тернәкләндерү техник чаралары исемлеге нигезендә инвалидларга тернәкләндерүнең техник</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | чараларын;<br>онкология авырулары белән интегүче затларга дәвалану урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнары компенсациясен;<br>яшь белгечләр – җәза-үтәтү системасы табибларына билгеләнгән социаль түләүләрне;<br>вакытлыча эшкә яраксыз булу очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерелергә тиеш булмаган гражданнарга пособиеләрне;<br>гражданнар түләүгә керткән торак сатып алу турындагы шартнамәләрне финанслауны;<br>планлаштырылган оештыру һәм социаль әһәмияткә ия чараларны үткәрүне.<br>Ярдәмче программаны тормышка ашыру 2020 елда түбәндәгеләргә ярдәм итәчәк:<br>социаль яклау органнарына мөрәҗәгать иткән аз керемле гражданнарның гомуми санында керемнәре яшәү минимумы күләменә кадәр житкерелгән яки аларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү хисабына аннан югарырак булган гражданнар өлешен 26,1 процентка кадәр житкерергә;<br>Татарстан Республикасында гаиләләрнең гомуми санында торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә торак субсидияләре алган гаиләләр өлешен 8,1 процентка кадәр киметергә;<br>шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин ителгән гражданнар санын 6 150 кешегә кадәр арттырырга. |

I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсе тасвирламасы.
Ярдәмче программа хәл итәргә йөз тоткан проблемалар

Бу Ярдәмче программа Татарстан Республикасының аерым категорияле гражданнары тормыш сыйфатын күтәрү һәм аларның социаль ярдәм итү чараларына хокукларын тәэмин итү максатында эшләнде.

Аларның күпчелеге – федераль һәм республика законнары нигезендә категория принцибы буенча айлык социаль ярдәм чараларын алучылар.

(кеше)

| Гражданнар категорияләре | Социаль ярдәм чараларын алучылар саны | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2009 ел | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел |
| Региональ законнар нигезендә социаль ярдәм чараларын алучылар | | | | |
| Торак-коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә субсидияләр алучылар | 107 776 | 67 905 | 64 367 | 231 364 |
| Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләре | 26 998 | 35 405 | 25 236 | 25 001 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ инвалид балаларга айлык акчалата түләүләр | - | - | - | 642 |
| **Федераль законнар нигезендә социаль ярдәм чараларын алучылар** | | | | |
| Натуралата, айлык акчалата түләү һәм социаль хезмәт күрсәтүләр җыелмасы рәвешендә социаль ярдәм чараларын алучылар арасындагы гражданнар | 333 588 | 335 038 | 334 739 | 334 500 |
| «Россиянең мактаулы доноры» һәм «СССРның мактаулы доноры» билгеләре белән бүләкләнгән гражданнар | 10 007 | 10 083 | 9 915 | 9 829 |

Социаль яклау органнары аша дәүләт социаль ярдәмен алучыларның гомуми саны 2013 елның 1 гыйнварына 1,59 миллионнан артык кеше тәшкил итә, шулардан 364,8 мең кеше җаваплылыкның федераль дәрәҗәсенә кертелгән. 2012 елда Татарстан Республикасы халкына социаль ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыруга 10,3 млрд.сум акча җибәрелгән иде.

«Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» 1995 ел, 19 май, ФЗ-81 нче Федераль закон белән билгеләнгән барлык төр пособиеләр түләнә. 2012 елда эшләмәүче ата-аналар - 7 712 бала тууга бер тапкыр бирелә торган пособие, 19 324 эшләмәүче граждан бала карау буенча пособие алды, хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең 54 йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие, хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең 129 баласына айлык пособие түләнде.

Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән түләү буенча социаль ярдәм чаралары күрсәтелә. 2012 елда торак-коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә 687 109 кеше субсидия-ташлама алды. Ел йомгаклары буенча әлеге максатларга 3,877 млрд.сум акча җибәрелде.

Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә, шул исәптән Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә билгеләнгән субсидияләрне бирүгә 864,2 млн.сум акча җибәрелде, 231 364 гаилә субсидия алучы булды.

2012 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы территориясендә катнаш җитештерү режимында җитештерелә торган җылылык энергиясе белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Таттеплосбыт» ачык акционерлар җәмгыяте җылылык белән тәэмин итә торган торак урыннарда яшәүче гражданнарга торак-коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнарның түләүләре артуны тигезләү өчен максатчан субсидия бирелә. Төрле яклап субсидияләү бетерелү гамәле кагыла торган 515 мең йорт хуҗалыгыннан социаль яклау органнарына 2012 елның сентябреннән декабренә кадәр 198,6 мең йорт хуҗалыгы максатчан субсидия алу турында мөрәҗәгать итте һәм үз хокукларын раслады, бу субсидия сорап мөрәҗәгать итүчеләр саныннан 38,5 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе Президентының «1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү турында» 2008 ел, 7 май, 714 нче Указын тормышка ашыру кысаларында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ Бөек Ватан сугышы ветераннарын уңайлыклары булган торак белән тәэмин итү буенча дәүләт программасын тормышка ашыру эше дәвам иттерелә. Указны тормышка ашыру өчен республикага кергән финанслау күләмнәреннән чыгып, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә куелган 18,0 мең сугыш ветеранынннан 17,6

меңнән артык кеше субсидия алды. Шулардан 16,9 меңнән артык ветеран сатып алынган торакка урнаштырылды инде.

Гражданнарның башка категорияләре арасындагы (хәрби хәрәкәтләр ветераннары, хәрби хәрәкәтләрдә һәлак булган (үлгән) ветераннарның гаилә әгъзалары, инвалид балалары булган гаиләләр) субсидия алуга дәгъва итүчеләрнең җыелма реестрында 5 051 кеше исәпләнә. 2006 – 2012 елларда алар арасындагы 1 411 кеше торак шартларын яхшыртты, шул исәптән 2012 елда – 325 кеше.

2012 ел эчендә аз керемле гаиләләргә, тормыш хәле авыр булган гаиләләргә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (шул исәптән социаль контракт нигезендә) эше үткәрелде. 19 053 кеше матди ярдәм алды, 2012 елда түләүнең бер кешегә уртача күләме 2 677 сум тәшкил итте. Тулаем алганда әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан 51,0 млн. сум акча җибәрелде.

Ярдәмче программа кысаларында социаль ярдәм чараларына гражданнарның аерым категорияләре хокукларын тулы күләмдә һәм үз вакытында тәэмин итүне оештыруга җибәрелгән чаралар гамәлгә ашырылачак.

## II. Ярдәмче программаның төп максатлары, бурычлары һәм көтелә торган соңгы нәтиҗәләре тасвирнамәсе, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Ярдәмче программаның максаты – Татарстан Республикасының аерым категорияле гражданнары тормыш сыйфатын күтәрү һәм аларның социаль ярдәм чараларына хокукларын тәэмин итү.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

гражданнарның аерым категорияләренә федераль һәм республика законнарында билгеләнгән социаль ярдәм чараларын күрсәтү;

һөнәр белеме бирү оешмаларында белем алучыларны уку чорында туклану белән тәэмин итү.

Гражданнарның аерым категорияләренә федераль һәм республика законнарында билгеләнгән социаль ярдәм чараларын күрсәтү бурычларын тормышка ашыру кысаларында түбәндәге чараларның үтәлешен тәэмин итәргә кирәк:

вакцинациядән соң өзлегүләр барлыкка килгәндә гражданнарга бер тапкыр бирелә торган пособиене һәм айлык акчалата компенсацияләрне бирүне;

транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәләре буенча инвалидларга иминият премияләре компенсацияләрен бирүне;

гражданнарның аерым категорияләренә торак-коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирүне;

гражданнарга торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә субсидияләр бирүне;

хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән интегүче, амбулатор гемодиализ методы белән дәва алучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарына компенсацияләр бирүне;

авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә субсидия-ташламалар бирүне;

даими рәвештә кеше каравына мохтаҗ инвалид балаларга айлык акчалата түләү бирүне;

гражданнарның аерым категорияләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итүне һәм аз керемле гражданнарга матди ярдәм күрсәтүне;

оештыру чараларын һәм социаль әһәмияткә ия булган чаралар үткәрүне;

«Ветераннар турында» һәм «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау хакында» федераль законнарда билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итүне;

күмүгә социаль пособие бирүне һәм күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча чыгымнарны каплауны;

«СССРның мактаулы доноры», «Россиянең мактаулы доноры» билгеләре белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләү бирүне;

онкология авырулары белән интегүче затларга махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасының дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренә дәвалану урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарына компенсацияләр бирүне;

яшь белгечләр – җәза-үтәтү системасы табибларына социаль ярдәм күрсәтүне;

гаиләләрдән, балалар йортларыннан, интернат мәктәпләрдән, махсус уку-укыту-тәрбия һәм башка балалар учреждениеләреннән рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны транспортта йөртүне тәэмин итүне;

республика тернәкләндерү техник чаралары исемлеге нигезендә инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итүне;

вакытлыча эшкә яраксыз булу очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерелергә тиеш булмаган гражданнарга дәүләт пособиеләрен түләүне.

Һөнәр белеме бирү оешмаларында белем алучыларны уку чорында туклану белән тәэмин итү бурычын тормышка ашыру кысаларында һөнәр белеме бирү оешмаларында белем алучыларны туклану белән тәэмин итәргә кирәк.

Максат, бурычлар һәм чаралар яктылыгында Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары турындагы мәгълүматлар Ярдәмче программага теркәлгән кушымтада китерелә.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары: 2014 – 2020 еллар.

## III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 50 761 311,3 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 6 591 320,1 мең сум; федераль бюджет акчасы исәбеннән – 44 169 991,2 мең сум.

(мең сум)

| Ел | Социаль түләүләргә акча күләме, барлыгы | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | федераль бюджет акчасы |
| 2014 | 10 290 911,0 | 4 522 747,9 | 5 768 163,1 |
| 2015 | 6 521 486 | 310 393,3 | 6 211 092,7 |
| 2016 | 6 282 028,2 | 323 992,8 | 5 958 035,4 |
| 2017 | 6 503 155,1 | 337 572,5 | 6 165 582,6 |
| 2018 | 6 782 439,10 | 351 736,4 | 6 430 702,7 |
| 2019 | 7 060 184,0 | 365 822,3 | 6 694 361,7 |
| 2020 | 7 321 107,9 | 379 054,9 | 6 942 053,0 |
| Барлыгы | 50 761 311,3 | 6 591 320,1 | 44 169 991,2 |

Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

## IV. Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы

Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы-эраштыручысы – Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы.

Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары булып Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы тора.

Дәүләт заказчылары һәм Ярдәмче программа чараларын үтәүчеләр түбәндәгеләрне башкара:

чараларны үтәү барышын тикшерүдә тотуны;

үтәүчеләрнең бүлеп бирелә торган финанс чараларыннан рациональ файдалануын тикшерүдә тотуны;

Ярдәмче программа чаралары яктылыгында узган чор (квартал, ел) өчен Ярдәмче программаны үтәү турында хисаплар төзүне;

Ярдәмче программаны тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган финанс чараларын исәпкә алып, Ярдәмче программа чаралары буенча максатчан күрсәткечләрне һәм чыгымнарны, Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмын һәм аны үтәүчеләр составын ачыклауны.

Финанслау тәртибе, шулай ук Ярдәмче программада каралган чараларны тормышка ашыру механизмы федераль һәм республика законнары белән билгеләнгән.

Дәүләт заказчылары квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 енә кадәр, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Ярдәмче программаны тормышка ашыру, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә (алга таба – Тәртип) теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форманы тутырып, финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында статистика, белешмә һәм аналитик мәгълүмат кертә.

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 25 енә кадәр, Тәртипкә теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форманы тутырып, 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы составындагы Ярдәмче программаны тормышка ашыру һәм финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына җыелма статистика, белешмә һәм аналитик мәгълүмат кертә.

## V. Ярдәмче программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Бу юнәлешләр буенча үткәрелә торган чаралар, социаль юнәлештәге башка чаралар белән берлектә, кайбер төп бурычларны хәл итүгә булышлык күрсәтәчәк - халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын эзлекле күтәрүгә; балалы гаиләләрнең керемнәрен арттыруга; халыкның җан башына керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумына җиткән яки аларга социаль ярдәм (шул исәптән дәүләт социаль ярдәмен) чараларын күрсәтү хисабына аннан артып киткән гражданнар саны артуга.

2014 – 2020 елларга «Социаль түләүләр» ярдәмче программасына кушымта

## 2014 – 2020 елларга «Социаль түләүләр» ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Ярдәмче программа чараларын финанслау

| Төп чаралар исеме | Үтәүчеләр | Төп чараларны үтәү вакытлары | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Еллар буенча индикаторларның мәгънәләре | | | | | | | | Еллар буенча финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау, мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2014ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| Максатның исеме: Татарстан Республикасының аерым категорияле гражданнары тормыш сыйфатын күтәрү һәм аларның социаль ярдәм чараларына хокукларын тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 нче бурычның исеме: Гражданнарның аерым категорияләренә федераль һәм республика законнары белән билгеләнгән социаль ярдәм чараларын күрсәтү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие, шулай ук хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең балаларына айлык пособие бирү | ТР ХХӘб ТИһ СЯМ | 2014 ел | Хәрби хезмәткәрләрнең йөкле хатыннарына бер тапкыр бирелә торган пособиеләрне, хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр балаларына айлык пособиеләрне тулы күләмдә бирү, % | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | 44 530,0 РФБ | - | - | - | - | - | - |
| Күпбалалы гаиләләргә торак һәм коммуналь | ТР ХХӘб ТИһ СЯМ | 2014 ел | Социаль яклау органнарына мөрәҗәгать | 25,5 | 25,8 | - | - | - | - | - | - | 396 880,9 ТРБ | - | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә субсидия-ташламалар бирү | | | иткән аз керемле гражданнарның гомуми санында керемнәре яшәү минимумы күләменә кадәр җиткерелгән һәм социаль ярдәм чараларын күрсәтү хисабына аннан югарырак булган гражданнар өлеше, % | | | | | | | | | | | | | | | |
| Гражданнарга торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә субсидияләр бирү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 ел | Татарстан Республикасында гаиләләрнең гомуми санында торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә торак субсидияләре алган гаиләләр өлеше, % | 8,4 | 8,3 | - | - | - | - | - | - | 2 518 905,2 ТРБ | - | - | - | - | - | - |
| Балага айлык пособие бирү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 ел | Балага айлык пособиене тулы күләмдә бирү, % | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | 392 792,2 ТРБ | - | - | - | - | - | - |
| Берьюлы туган өч һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә пособиеләр бирү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 ел | Берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә пособиеләрне тулы күләмдә бирү, % | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | 560,7 ТРБ | - | - | - | - | - | - |
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында баланы караштыр- | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 ел | Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | 661 559,2 ТРБ | - | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| рып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация бирү | | | ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә тулы күләмдә компенсация бирү | | | | | | | | | | | | | | | |
| «Ата-ана даны» ордены белән бүләкләнгән ана-аналарга (уллыкка (кызлыкка) алучыларга, «Ана даны Материнская слава» медале белән бүләкләнгән аналарга бер тапкыр бирелә торган бүләкләүне бирү | ТР ХХӘб ТИһ СЯМ | 2014 ел | «Ата-ана даны» ордены белән бүләкләнгән ана-аналарга (уллыкка (кызлыкка) алучыларга), «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән аналарга бер тапкыр бирелә торган бүләкләүне тулы күләмдә бирү, % | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | 3 710,0 ТРБ | - | - | - | - | - | - |
| Дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга | ТР ХХӘб ТИһ СЯМ | 2014 ел | Дәүләт һөнәр белеме бирүче мәгариф оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга социаль түләү- | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | 223 407,5 ТРБ | - | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| социаль түләүләр бирү: дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлап чыкканда өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһазлар белән тәэмин итүгә бер тапкыр бирелә торган пособие; дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлап чыкканда бер тапкыр бирелә торган пособие; өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь сатып алуга еллык пособие; уку әдәбияты һәм язу кирәк-яраклары | | | ләрне тулы күләмдә бирү, % | | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| сатып алуга еллык пособие; туклануга айлык пособие; ятим балаларга һәм инвалид балаларга айлык стипендия; транспортта йөрүгә ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга айлык субсидияләр | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Вакцинациядән соң өзлегүләр барлыкка килгәндә гражданнарга бер тапкыр бирелә торган пособие һәм айлык акчалата компенсацияләр бирү | ТР ХХӘб ТИһ СЯМ | 2014 – 2020 еллар | Вакцинациядән соң өзлегүләр барлыкка килгәндә гражданнарга тулы күләмдә пособиеләр һәм компенсацияләр бирү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 154,0 РФБ | 151,6 БРФ | 151,6 БРФ | 151,6 БРФ | 158,1 БРФ | 164,6 БРФ | 170,7 БРФ |
| Транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәләре буенча иминият премияләр- | ТР ХХӘб ТИһ СЯМ | 2014 2015 еллар | Транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәләре буенча инвалидларга иминият премияләре ком- | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | 1 599,7 РФБ | 1 599,7 БРФ | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ре компенсацияләрен бирү | | | пенсацияләрен тулы күләмдә бирү, % | | | | | | | | | | | | | | | |
| Гражданнарның аерым категорияләренә торак-коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә субсидия-ташламар бирү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 – 2020 еллар | Социаль яклау органнарына мөрәҗәгать иткән аз керемле гражданнарның гомуми санында керемнәре яшәү минимумы күләменә кадәр җиткерелгән һәм социаль ярдәм чараларын күрсәтү хисабына аннан югарырак булган гражданнар өлеше, % | 25,5 | 25,8 | 25,9 | 26,0 | 26,0 | 26,1 | 26,1 | 26,1 | 4 097 278,3 РФБ | 4 230 889,5 БРФ | 4 346 034,1 БРФ | 4 495 690,2 БРФ | 4 689 004,9 БРФ | 4 881 254,1 БРФ | 5 061 860,5 БРФ |
| Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәвалану алучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарына компенсацияләр бирү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 2020 еллар | Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәвалану алучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарына тулы күләмдә компенсацияләр бирү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 2 372,0 ТРБ | 3 691,6 БРТ | 3 857,7 БРТ | 4 023,5 БРТ | 4 196,5 БРТ | 4 368,6 БРТ | 4 530,2 БРТ |
| Авыл | ТР | 2014 | Авыл жи- | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 25 809,1 | 4 349,2 | 4 544,9 | 4 740,3 | 4 944,1 | 5 146,8 | 5 337,2 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| жирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә субсидия-ташламар бирү | ХХЭб ТИһ СЯМ | 2020 еллар | рендә, шәһәр тибындагы поселокларда эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә субсидия-ташламаларны тулы күләмдә бирү | | | | | | | | | ТРБ | БРТ | БРТ | БРТ | БРТ | БРТ | БРТ |
| Даими рәвештә кеше каравына мохтаҗ инвалид балаларга айлык акчалата түләүләр бирү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 2020 еллар | Даими рәвештә кеше каравына мохтаҗ инвалид балаларга айлык акчалата түләү бирү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 27 472,2 ТРБ | 28 961,6 БРТ | 30 264,9 БРТ | 31 566,3 БРТ | 32 923,7 БРТ | 34 273,6 БРТ | 35 541,7 БРТ |
| Гражданнарның аерым категорияләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү һәм аз керемле гражданнарга матди ярдәм күрсәтү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 – 2020 еллар | Шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин ителгән гражданнар саны, кеше | 5407 | 5677 | 5860 | 6150 | 6150 | 6150 | 6150 | 6150 | 168 635,0 ТРБ | 177 066,8 БРТ | 185 034,8 БРТ | 192 991,3 БРТ | 201 289,9 БРТ | 209 542,8 БРТ | 217 295,9 БРТ |
| Оештыру чаралары һәм социаль әһәмияткә ия | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 – 2020 еллар | Планлаштырылган оештыру чараларын һәм социаль әһә- | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 8 480,0 ТРБ | 8 180,0 БРТ | 8 180,0 БРТ | 8 180,0 БРТ | 8 180,0 БРТ | 8 180,0 БРТ | 8 180,0 БРТ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| булган чаралар үткәрү | | | мияткә ия булган чараларны тулы күләмдә үткәрү, % | | | | | | | | | | | | | | | |
| «Ветераннар турында» һәм «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау хакында» федераль законнарда билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү | ТР ХХӘб ТИһ СЯМ | 2014 – 2020 еллар | Гражданнар түләүгә керткән торак сатып алу турындагы шартнамәләрне финанслауны тулы күләмдә тәэмин итү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 392 659,1 РФБ | 609 719,9 БРФ | 178 445,0 БРФ | 178 522,7 БРФ | 186 199,2 БРФ | 193 833,4 БРФ | 201 005,2 БРФ |
| Күмүгә социаль пособие бирү һәм күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча чыгымнарны каплау | ТР ХХӘб ТИһ СЯМ | 2014 – 2020 еллар | Күмүгә социаль пособие бирү һәм күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча чыгымнарны тулы күләмдә каплау, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 27 669,4 ТРБ | 29 052,9 БРТ | 30 360,2 БРТ | 31 665,7 БРТ | 33 027,3 БРТ | 34 381,4 БРТ | 35 653,5 БРТ |
| «СССРның мактаулы доноры», «Россиянең мактаулы доноры» билгеләре белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләү бирү | ТР ХХӘб ТИһ СЯМ | 2014 – 2020 еллар | «СССРның мактаулы доноры», «Россиянең мактаулы доноры» билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне тулы күләмдә бирү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 133 955,7 РФБ | 135 801,6 БРФ | 141 907,8 БРФ | 148 003,0 БРФ | 154 367,1 БРФ | 160 696,2 БРФ | 166 642,0 БРФ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Гаиләләрдән, балалар йортларыннан, интернат мәктәпләрдән, махсус уку-укыту-тәрбия һәм башка балалар учреждениеләреннән рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны транспортта йөртүне тәэмин итү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 – 2020 еллар | Гаиләләрдән, балалар йортларыннан, интернат мәктәпләрдән, махсус уку-укыту-тәрбия һәм башка балалар учреждениеләреннән рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны транспортта йөртү чыгымнарына түләү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 422,4 РФБ | 264,0 БРФ | 264,0 БРФ | 264,0 БРФ | 275,4 БРФ | 286,7 БРФ | 297,3 БРФ |
| Онкология авырулары белән интегүче затларга махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасының дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренә дәвалану урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарына компенсацияләр бирү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 – 2020 еллар | Онкология авырулары белән интегүче затларга махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренә дәвалану урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарына компенсацияләрне тулы күләмдә бирү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 16 186,8 ТРБ | 17 124,4 БРТ | 17 895,0 БРТ | 18 664,5 БРТ | 19 467,1 БРТ | 20 265,3 БРТ | 21 015,1 БРТ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Республика тернәкләндерү техник чаралары исемлеге нигезендә инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 ел | Республика тернәкләндерү техник чаралары исемлеге нигезендә инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү, % | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | 10 000,0 ТРБ | - | - | - | - | - | - |
| Яшь белгечләр жаза-үтәү системасы табибларына социаль ярдәм күрсәтү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 ел | Яшь белгечләр җәза-үтәү системасы табибларына билгеләнгән социаль түләүләрне тулы күләмдә бирү, % | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | 43,1 ТРБ | - | - | - | - | - | - |
| Вакытлыча эшкә яраксыз булу очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерелергә тиеш булмаган гражданнарга дәүләт пособиеләрен түләү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 2020 еллар | Вакытлыча эшкә яраксыз булу очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерелергә тиеш булмаган гражданнарга дәүләт пособиеләрен тулы күләмдә түләү | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 1 097 563,9 РФБ | 1 172 255,7 БРФ | 1 227 801,7 БРФ | 1 276 982,6 БРФ | 1 331 892,9 БРФ | 1 386 500,5 БРФ | 1 437 801,0 БРФ |
| Радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль ярдәмнең аерым чараларын күрсәтү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2015 – 2020 еллар | Радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль ярдәмнең аерым чараларын тулы күләмдә күрсәтү, % | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | 60 410,7 БРФ | 63 431,2 БРФ | 65 968,5 БРФ | 68 805,1 БРФ | 71 626,2 БРФ | 74 276,3 БРФ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 нче бурычның исеме: Һөнәр белеме бирүче белем бирү оешмаларында белем алучыларны туклану белән тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Һөнәр белеме бирү оешмаларында белем алучыларны туклану белән тәэмин итү | ТР ССМ, ТР ММ, ТР МhЭМ, ТР МhФМ, ТР УХМ, ТР АХhАТМ | 2014 – 2020 еллар | Һөнәр белеме бирү оешмаларында белем алучыларны туклану белән тулы күләмдә тәэмин итү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 38 264,6 ТРБ | 41 966,8 БРТ | 43 855,3 БРТ | 45 740,9 БРТ | 47 707,8 БРТ | 49 663,8 БРТ | 51 501,3 БРТ |
| Ярдәмче программа буенча барлыгы, шул исәптән: | | | | | | | | | | | | 10 290 911,0 | 6 521 486,0 | 6 282 028,2 | 6 503 155,1 | 6 782 439,1 | 7 060 184,0 | 7 321 107,9 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | | | | | | | | | | | | 4 522 747,9 | 310 393,3 | 323 992,8 | 337 572,5 | 351 736,4 | 365 822,3 | 379 054,9 |
| федераль бюджет | | | | | | | | | | | | 5 768 163,1 | 6 211 092,7 | 5 958 035,4 | 6 165 582,6 | 6 430 702,7 | 6 694 361,7 | 6 942 053,0 |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

ТР ХХЭбТИhСЯМ – Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;
ТР ССМ – Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы;
ТР ММ – Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы;
ТР МhЭМ – Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы;
ТР МhФМ – Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы;
ТР АХhАТМ – Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы;
ТР УХМ – Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы;
РФБ – федераль бюджет;
ТРБ – Татарстан Республикасы бюджеты.

# 2014 – 2020 елларга «Өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү» ярдәмче программасы

## Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | 2014 – 2020 елларга өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысы | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды |
| Ярдәмче программаның максаты | Өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү |
| Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Өлкән яшьтәге гражданнарның социаль якланышын ныгыту чараларын тормышка ашыру.<br>2. Өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтүнең адреслылыгын көчәйтү |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2020 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 50 122 937,7 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2014 елда – 6 618 740,1 мең сум;<br>2015 елда – 6 643 647,5 мең сум;<br>2016 елда – 6 900 204,4 мең сум;<br>2017 елда – 7 047 723,3 мең сум;<br>2018 елда – 7 346 453,9 мең сум;<br>2019 елда – 7 643 538,1 мең сум;<br>2020 елда – 7 922 630,4 мең сум. |
| Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче | Ярдәмче программаны тормышка ашыру 2020 елга түбәндәгеләрне тәэмин итәргә ярдәм итәчәк: |

| | |
|---|---|
| программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | социаль ярдәм чараларын алу хисабына өлкән яшьтәге гражданнарның керемнәрен кимендә 7,9 процент күләмендә (2030 елга кадәр Россия Федерациясен озак вакытлы социаль-икътисадый үстерү фаразы инфляциясе индексыннан түбән итмичә) арттыруны;<br>теш протезлары һәм (яки) колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтүдән файдаланган гражданнар өлешен 96,6 процентка кадәр җиткерүне;<br>хокуклары булган һәм алуга гариза биргәннәр саныннан тиешле елларны эшләгән өчен пенсияләр һәм пенсиягә өстәмә түләүләрр алуга хокукын гамәлгә ашырган дәүләт граждан (муниципаль) хезмәткәрләре өлешен 100 процент дәрәҗәсендә саклауны;<br>хокуклары булган һәм алуга гариза биргәннәр саныннан дәүләт пенсиясенә өстәмә түләүләр алуга хокукын гамәлгә ашырган Татарстан Республикасы алдында аерым казанышлары булган гражданнар өлешен 100 процент дәрәҗәсендә саклауны;<br>хокуклары булган һәм алуга гариза биргәннәр саныннан тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү алган дәүләт граждан (муниципаль) хезмәткәрләре өлешен 100 процент дәрәҗәсендә саклауны;<br>хокуклары булган һәм алуга гариза биргәннәр саныннан вакытыннан алда пенсияләр алуга хокукларын гамәлгә ашырган ашыгыч медицина ярдәме станцияләре хезмәткәрләре өлешен 100 процент дәрәҗәсендә саклауны;<br>хокуклары булган һәм аны алуга гариза биргәннәр саныннан түләүсез юридик ярдәм алуга хокукларын гамәлгә ашырган гражданнар өлешен 100 процент дәрәҗәсендә саклауны |

## I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсе тасвирламасы. Ярдәмче программа хәл итәргә йөз тоткан проблемалар

Ярдәмче программа Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А.Медведев «Өлкән яшьтәге кешеләрнең тормыш сыйфатын күтәрү турында» дигән темага үткәрелгән киңәшмә йомгаклары буенча 2012 елның 18 декабрендә йөкләгән ДМ-П12-51-пр эшен үтәү йөзеннән әзерләнде һәм 2011 – 2013 елларда Татарстан Республикасында тормышка ашырылган озак вакытлы максатчан программаның дәвамы булып тора.

Өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү актуаль стратегик бурыч булып кала.

Татарстан Республикасының эшкә яраклы яшьтән өлкәнрәк халкы саны 2012 елның 1 гыйнвары хәленә карата 831,3 мең кеше тәшкил итте (барлык халык саныннан 21,8 процент). Керемнәре яшәү минимумыннан түбәнрәк булган халык

саны 8,3 процент дәрәҗәсендә кала бирә (313,9 мең кеше). Картлык буенча уртача хезмәт пенсиясенең күләме - 10 225 сум, инвалидлык буенча – 6 670 сум тәшкил итә. Моңа бәйле рәвештә социаль ярдәм чараларын күрсәтү өлкән яшьтәге гражданнарның матди иминлеге дәрәҗәсен арттыруга уңай йогынты ясый торган социаль сәясәтнең бер өлеше булып тора.

Татарстан Республикасында социаль ярдәм чараларыннан файдаланучыларның фактгагы саны соңгы елларда динамикада түбәндәгеләрне тәшкил итте:

| Гражданнар категорияләре | Файдаланучылар саны (кеше) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2009 ел | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел |
| Региональ ташламалары булган | | | | |
| Хезмәт ветераннары | 271 817 | 263 702 | 256 258 | 250 682 |
| Тыл хезмәткәрләре | 9 505 | 7 934 | 6 736 | 5 838 |
| Акланганнар | 2 683 | 2 564 | 2 465 | 2 358 |
| Репрессияләнгәннәр | 86 | 74 | 60 | 55 |
| Пенсионерлар | 364 326 | 387 278 | 409 690 | 434 190 |
| Ялгыз пенсионерлар | 29 | 23 | 22 | 20 |
| Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затлар | 1 337 | 1 697 | 2 231 | 2 650 |

## II. Ярдәмче программаның төп максаты, бурычлары һәм көтелә торган соңгы нәтиҗәләре тасвирнамәсе, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Ярдәмче программаның максаты - өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

өлкән яшьтәге гражданнарның социаль яклнышын ныгыту чараларын тормышка ашыру;

өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтүнең адреслылыгын көчәйтү.

Өлкән яшьтәге гражданнарның социаль якланышын ныгыту чараларын тормышка ашыру бурычларын үтәү кысаларында түбәндәге чараларның үтәлешен тәэмин итәргә кирәк:

хезмәт ветераннарына, тыл хезмәтчәннәренә, акланган затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга, пенсионерларга (шул исәптән ялгыз пенсионерларга), Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү (шул исәптән теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау чыгымнары өлешендә);

тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясен һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләренә пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләүне, шулай ук Татарстан Республикасы алдында аерым казанышлары булган

гражданнар пенсиясенә өстәмә түләүләрне, ашыгыч медицина ярдәме станцияләре хезмәткәрләренә вакытыннан алда пенсияләрен түләү.

Өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтүнең адреслылыгын ныгыту бурычын тормышка ашыру кысаларында түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чараларын үтәүне тәэмин итәргә кирәк.

Максат, бурычлар һәм чаралар яктылыгында Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары турындагы мәгълүматлар Ярдәмче программага теркәлгән кушымтада китерелә.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары: 2014 – 2020 еллар.

## III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 50 122 937,7 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: 2014 елда – 6 618 740,1 мең сум; 2015 елда – 6 643 647,5 мең сум; 2016 елда – 6 900 204,4 мең сум; 2017 елда – 7 047 723,3 мең сум; 2018 елда – 7 346 453,9 мең сум; 2019 елда – 7 643 538,1 мең сум; 2020 елда – 7 922 630,4 мең сум.

## IV. Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы

Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысы – Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы.

Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары - Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды.

Дәүләт заказчылары һәм Ярдәмче программа чараларын үтәүчеләр түбәндәгеләрне башкара:

чараларны үтәү барышын тикшерүдә тотуны;

үтәүчеләрнең бүлеп бирелә торган финанс чараларыннан рациональ файдалануын тикшерүдә тотуны;

Ярдәмче программа чаралары яктылыгында узган чор (квартал, ел) өчен Ярдәмче программаны үтәү турында хисаплар төзүне;

Ярдәмче программаны тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган финанс чараларын исәпкә алып, Ярдәмче программа чаралары буенча максатчан күрсәткечләрне һәм чыгымнарны, Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмын һәм аны үтәүчеләр составын ачыклауны.

Финанслау тәртибе, шулай ук Ярдәмче программада каралган чараларны тормышка ашыру механизмы федераль һәм республика законнары белән билгеләнгән.

Дәүләт заказчылары квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 енә кадәр, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Ярдәмче программаны тормышка ашыру, шулай

ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә (алга таба – Тәртип) теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форманы тутырып, финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында статистика, белешмә һәм аналитик мәгълүмат кертә.

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 25 енә кадәр, Тәртиптә теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форманы тутырып, 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы составындагы Ярдәмче программаны тормышка ашыру һәм финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына җыелма статистика, белешмә һәм аналитик мәгълүмат кертә.

## V. Ярдәмче программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Ярдәмче программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр белән бәяләнә:

өлкән яшьтәге 700 меңнән артык гражданның матди иминлеге дәрәҗәсе социаль ярдәм чараларын күрсәтү хисабына 2014 елдагы 6,7 проценттан 2020 елга 7,9 процентка кадәр артачак,

түләүсез теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтүдән файдалануга хокуклары булган һәм бу хезмәтләрдән файдаланган өлкән яшьтәге гражданнарны җәлеп итү 2014 елдагы 95,4 проценттан 2020 елга 96,6 процентка кадәр артачак,

түләүсез юридик ярдәм алуга хокукларын тормышка ашырган гражданнар өлеше 100 процент дәрәҗәсендә сакланачак.

2014 – 2020 елларга «Өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү» ярдәмче программасына кушымта

## 2014 – 2020 елларга «Өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү» ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Ярдәмче программа чараларын финанслау

| Төп чаралар исеме | Үтәүчеләр | Төп чараларны үтәү вакытлары | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Еллар буенча индикаторларның мәгънәләре | | | | | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау, мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| Максатның исеме: Өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Бурычның исеме: 1. Өлкән яшьтәге гражданнарның социаль якланышын ныгыту чараларын тормышка ашыру | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Ялгыз пенсионерларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 – 2020 еллар | Социаль ярдәм чараларын алу хисабына өлкән яшьтәге гражданнарның керемнәре арту (2030 елга кадәр Россия Федерациясен озак вакытлы социаль-икътисадый үстерү фаразы инфляциясе индексыннан түбән итмичә), % | 6,5 | 6,7 | 6,7 | 7,0 | 7,2 | 7,4 | 7,7 | 7,9 | 271,6 ТРБ | 285,1 ТРБ | 297,9 ТРБ | 310,7 ТРБ | 324,1 ТРБ | 337,4 ТРБ | 349,9 ТРБ |
| Хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын күрсәтү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 – 2020 еллар | | | | | | | | | | 3 633 273,9 ТРБ | 3 546 204,6 ТРБ | 3 669 702,8 ТРБ | 3 790 401,4 ТРБ | 3 953 388,7 ТРБ | 4 115 477,6 ТРБ | 4 267 750,3 ТРБ |
| Тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын күрсәтү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 – 2020 еллар | | | | | | | | | | 32 498,6 ТРБ | 29 778,3 ТРБ | 31 118,3 ТРБ | 32 456,4 ТРБ | 33 852,0 ТРБ | 35 239,9 ТРБ | 36 543,8 ТРБ |
| Акланган затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип табылган затларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 2020 еллар | | | | | | | | | | 38 901,3 ТРБ | 40 153,3 ТРБ | 41 960,2 ТРБ | 43 764,6 ТРБ | 45 646,5 ТРБ | 47 518,0 ТРБ | 49 276,2 ТРБ |
| Пенсионерларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү | ТР ХХЭб ТИһ СЯМ | 2014 2020 еллар | | | | | | | | | | 2 201 695,1 ТРБ | 2 279 107,1 ТРБ | 2 374 926,6 ТРБ | 2 364 450,7 ТРБ | 2 466 122,1 ТРБ | 2 567 233,1 ТРБ | 2 662 220,7 ТРБ |
| Татарстан Республикасының | ТР ХХЭб | 2014 – 2020 | | | | | | | | | | 43 324,8 ТРБ | 45 461,6 ТРБ | 47 994,4 ТРБ | 50 634,2 ТРБ | 52 811,5 ТРБ | 54 976,8 ТРБ | 57 010,9 ТРБ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү | ТИһ СЯМ | еллар | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чаралары күрсәтү (теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау чыгымнары өлешендә) | ТР ММИТФ, ТР ФМ | 2014 – 2020 еллар | Теш протезлары һәм (яки) колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтүдән файдаланган гражданнар өлеше, % | 95 | 95,4 | 95,6 | 95,8 | 95,9 | 96 | 96,4 | 96,6 | 89 825,0 ТРБ | 93 856,0 ТРБ | 98 079,5 ТРБ | 102 296,9 ТРБ | 106 695,7 ТРБ | 111 070,2 ТРБ | 115 179,8 ТРБ |
| Тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын күрсәтү (теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау чыгымнары өлешендә) | ТР ММИТФ, ТР ФМ | 2014 2020 еллар | | | | | | | | | | 325,0 ТРБ | 366,7 ТРБ | 383,2 ТРБ | 399,6 ТРБ | 416,8 ТРБ | 433,9 ТРБ | 449,9 ТРБ |
| Акланган затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга социаль ярдәм чаралары күрсәтү (теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау чыгымнары өлешендә) | ТР ММИТФ, ТР ФМ | 2014 – 2020 еллар | | | | | | | | | | 964,1 ТРБ | 1 019,7 ТРБ | 1 065,6 ТРБ | 1 111,5 ТРБ | 1 159,3 ТРБ | 1 206,8 ТРБ | 1 251,5 ТРБ |
| Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга социаль ярдәм чаралары күрсәтү (теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау чыгымнары өлешендә) | ТР ММИТФ, ТР ФМ | 2014 2020 еллар | | | | | | | | | | 607,6 ТРБ | 1 065,4 ТРБ | 1 113,4 ТРБ | 1 161,3 ТРБ | 1 211,2 ТРБ | 1 260,9 ТРБ | 1 307,5 ТРБ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, муниципаль хезмәткәрләргә тиешле елларны эшләгән өчен пенсияләр һәм Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) вазыйфаларын биләгән затларга тиешле елларны эшләгән өчен пенсияләргә өстәмә түләүләр бирү | ТР ХХӘб ТИһ СЯМ | 2014 2020 еллар | Хокуклары булган һәм алуга гариза биргәннәр саныннан тиешле елларны эшләгән өчен пенсияләр һәм пенсиягә өстәмә түләүләр алуга хокукын тормышка ашырган дәүләт граждан (муниципаль) хезмәткәрләре өлеше,% | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 461 745,2 ТРБ | 494 365,9 ТРБ | 521 967,2 ТРБ | 548 661,3 ТРБ | 572 253,7 ТРБ | 595 716,1 ТРБ | 617 757,6 ТРБ |
| Татарстан Республикасы алдында аерым казанышлары булган гражданнарга дәүләт пенсиясенә өстәмә түләүләр бирү | ТР ХХӘб ТИһ СЯМ | 2014 – 2020 еллар | Хокуклары булган һәм алуга гариза биргәннәр саныннан дәүләт пенсиясенә өстәмәләр алу хокукын тормышка ашырган Татарстан Республикасы алдында аерым казанышлары булган гражданнар өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 5 501,6 ТРБ | 1 187,2 ТРБ | 335,4 ТРБ | 352,1 ТРБ | 367,2 ТРБ | 382,3 ТРБ | 396,4 ТРБ |
| Дәүләт хезмәткәре тиешле елларны эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне бирү | ТР ФМ | 2014 – 2020 еллар | Хокуклары булган һәм алуга гариза биргәннәр саныннан тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү алган дәүләт граждан (муниципаль) хезмәткәрләре өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 000,0 ТРБ | 100 000,0 ТРБ | 100 000,0 ТРБ | 100 000,0 ТРБ | 100 000,0 ТРБ | 100 000,0 ТРБ | 100 000,0 ТРБ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына гомерлек айлык тулы keремен, эштән киткәндә бирелә торган пособиене түләү, шулай ук матди һәм социаль тәэмин итүнең башка чараларын бирү | ТР Конституция суды | 2014 – 2020 еллар | Гомерлек айлык тулы керемен, эштән чыкканда бирелә торган пособие, шулай ук матди һәм социаль тәэмин итүнең башка чараларын алган граждannar өлеше, аларны алырга хокуклары булган затлар саныннан, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 4 727,6 ТРБ | 4 964,0 ТРБ | 5 187,4 ТРБ | 5 410,5 ТРБ | 5 643,15 ТРБ | 5 874,5 ТРБ | 6 091,9 ТРБ |
| Ашыгыч медицина ярдәме станцияләре хезмәткәрләренә вакытыннан алда пенсияләрен түләү | ТР ХХЭбТИһСЯМ | 2014 – 2020 еллар | Хокуклары булган һәм алуга гариза биргәннәр санынnan вакытыннан алда пенсияләр алу хокукларын тормышка ашырган ашыгыч медицина ярдәме станцияләре хезмәткәрләре өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 1 556,1 ТРБ | 1 633,9 ТРБ | 1 707,4 ТРБ | 1 780,8 ТРБ | 1 857,4 ТРБ | 1 933,6 ТРБ | 2 005,1 ТРБ |
| Бурычның исеме: 2. Өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтүнең адреслылыгын көчәйтү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү | ТР ФМ, ТР ЮМ | 2014 – 2020 еллар | Хокуклары булган һәм алуга гариза биргәннәр саныннан түләүсез юридик ярдәм алуга хокукларын тормышка ашырган гражданнар өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 3 522,6 ТРБ | 3 698,7 ТРБ | 3 865,1 ТРБ | 4 031,3 ТРБ | 4 204,6 ТРБ | 4 377,0 ТРБ | 4 538,9 ТРБ |
| Башка бюджет ассигнованиеләре (суд карарлары буенча түләү) | ТР ХХЭбТИһСЯМ | 2015 – 2020 еллар | | | | | | | | | | - | 500,0 ТРБ | 500,0 ТРБ | 500,0 ТРБ | 500,0 ТРБ | 500,0 БРТ | 500,0 ТРБ |
| Ярдәмче программа буенча барлыгы | | | | | | | | | | | | 6 618 740,1 | 6 643 647,5 | 6 900 204,4 | 7 047 723,3 | 7 346 453,9 | 7 643 538,1 | 7 922 630,4 |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

ТР ХХЭбТИһСЯМ – Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

ТР ФМ – Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы;

ТР ЮМ – Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы;

ТР ММИТФ – Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды;

ТРБ – Татарстан Республикасы бюджеты.

# 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасы

## Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| Программаның төп эшләүчесе | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| Ярдәмче программаның максаты | Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү |
| Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Гражданнарга дәүләт социаль хезмәтләрен күрсәтү сыйфатын һәм дәрәҗәсен күтәрүне тәэмин итү;<br>2. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләткә карамаган секторны үстерү;<br>3. Хезмәт өчен түләү системасын камилләштерү һәм тармак хезмәткәрләренең эш хакын арттыру;<br>4. Халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының матди-техник базасын ныгыту |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2020 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 28 450 417,625 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 28 436 545,725 мең сум, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия – 13 871,9 мең сум.<br>(мең сум) |

| Ел | Социаль хезмәт күрсәтүгә акча күләме, барлыгы | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия |
| 2014 | 3 187 086,525 | 3 173 214,625 | 13 871,9 |
| 2015 | 3 408 478,7 | 3 408 478,7 | - |
| 2016 | 3 700 135,7 | 3 700 135,7 | - |
| 2017 | 4 266 980,1 | 4 266 980,1 | - |
| 2018 | 4 450 460,2 | 4 450 460,2 | - |
| 2019 | 4 632 929,0 | 4 632 929,0 | - |
| 2020 | 4 804 347,4 | 4 804 347,4 | - |
| Барлыгы | 28 450 417,625 | 28 436 545,725 | 13 871,9 |

| | |
|---|---|
| | Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш |
| Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | Ярдәмче программаны тормышка ашыру 2020 елга түбәндәгеләргә ирешергә ярдәм итәчәк:<br>социаль хезмәт күрсәтүдән файдалануга хокуклары булган һәм алардан файдалану өчен социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларына мөрәҗәгать иткән гражданнарның гомуми санында социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларында социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланган гражданнар өлешен 100 процентка кадәр арттыруга;<br>эшчәнлекләре билгеләнгән критерийларга (стандартларга) туры килми торган халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары булмауны тәэмин итүгә, 0 процент;<br>барлык милек рәвешендәге социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында хезмәт күрсәтүләрдән файдаланган өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның (өлкәннәр һәм балалар) гомуми санында дәүләткә карамаган социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында хезмәт күрсәтүләрдән файдаланган өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның (өлкәннәр һәм балалар) чагыштырма авырлыгын 5 процентка кадәр арттыруга<br>барлык милек рәвешендәге оешмаларның гомуми саныннан социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләткә карамаган оешмаларның чагыштырма авырлыгын 1,4 процентка кадәр арттыруга;<br>Россия Федерациясе субъектының икътисад буенча уртача эш хакы белән социаль хезмәткәрләрнең уртача эш хакы чагыштырмасын 100 процентка кадәр тәэмин итүгә;<br>Татарстан Республикасында балаларның гомуми санында күзәтүчесез балаларның чагыштырма авырлыгын 0,38 процентка кадәр киметүгә;<br>социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының гомуми санында СанПиН нормаларына туры килә торган социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары чагыштырма авырлыгын 95 процентка кадәр җиткерүгә;<br>картларга кичектергесез социаль һәм медицина-социаль хезмәтләр күрсәтү буенча мобиль бригадалар эшчәнлеген тәэмин итү өчен яңа автотранспорт белән җиһазландырылган социаль хезмәт күрсәтүче территориаль комплекслы үзәкләрнең чагыштырма авырлыгын 46,6 процентка кадәр җиткерергә |

I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсе тасвирламасы. Ул хәл итәргә йөз тоткан проблемалар

Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү системасын модернизацияләү буенча системалы эш 2006 елдан гамәлгә ашырыла.

Социаль хезмәт күрсәтү системасын модернизацияләүнең һәм үстерүнең төп юнәлешләре түбәндәгеләргә юнәлдерелгән:

халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә норматив хокукый җайга салуны камилләштерүгә;

халыкның кимсетелгән категорияләренең индивидуаль ихтыяҗларыннан һәм мохтаҗлыгыннан чыгып, социаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм шартларын үзгәртүгә;

социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләт стандартларын эшләүгә һәм кертүгә;

социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре структурасын нәтиҗәсез хезмәтләрне бетерүне һәм таләп ителәә торган учреждениеләрне оештыруны күздә тотып үзгәртеп коруга;

учреждениеләрне карап тотуны смета буенча финанслаудан хезмәт күрсәтүләрнең норматив-җан башы исәбеннән чыгып финанслауга күчүгә;

хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт йөкләмәсе һәм дәүләт заказы механизмын кертүгә.

Халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салу максатларында социаль хезмәт күрсәтү белән идарә итүгә мөнәсәбәтләрне билгеләгән, социаль хезмәт күрсәтү формаларын һәм төрләрен; дәүләт стандартлары составын; социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт секторында учреждениеләр типларының тулы исемлеген билгеләгән; социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләт заказы принцибын урнаштырган «Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү турында» 2006 ел, 13 ноябрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә 7 стандарт расланды, шул исәптән:

дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар күрсәтелүче һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финансланучы дәүләт хезмәтләре исемлеге;

дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартлары;

социаль нормалар һәм социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт секторы учреждениеләрендә халыкның социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителеше нормативлары;

социаль нормативлар һәм социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт секторы учреждениеләре эшчәнлеге тәэмин ителешенең натураль нормалары;

нормативлар һәм дәүләт тарафыннан гарантияләнгән социаль хезмәт күрсәтүләргә тарифлар.

2007 елдан республикада өлкән яшьтәге гражданның һәм инвалидның социаль хезмәт күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗын бәяләү нигезендә һәм якын туганнарының социаль хезмәт күрсәткән өчен түләүдә катнашуын исәпкә алып (тәгаен гражданга кайсы учреждениедә һәм нинди хезмәтләр күрсәтелүе түләүгә бәйле), өлкән яшьтәге

гражданнарга һәм инвалидларга стационар социаль хезмәт күрсәтү һәм өйдә социаль хезмәт күрсәтү механизмы кертелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Олы яшьтәге гражданның һәм инвалидның халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекләрендә һәм Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү системасы интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүгә шәхси ихтыяҗларын бәяләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 ел, 12 февраль, 41 нче карары белән өйдә күрсәтелә торган дәүләт тарафыннан гарантияләнгән социаль хезмәтләрнең дүрт исемлеге (җыелмасы) кертелде, аларның составы хезмәт күрсәтүләр төрләре һәм күләме буенча клиентның үз-үзенә хезмәт күрсәтү һәм көндәлек тормышта гражданның активлылык дәрәҗәсенә интенсив йогынты ясый торган һәм (яки) мөстәкыйль хәрәкәтләнү сәләтләрен югалту дәрәҗәсенә карап төзелә.

Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт стандартлары халыкка социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатына куя торган таләпләр теләсә кайсы милек рәвешендәге социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре тарафыннан куллану өчен мәҗбүри.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартының нигезен тәшкил итә торган өлеше булып күрсәтелә торган дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләргә мөмкинлек бирә торган критерийлар тора.

Татарстан Республикасының гамәлдәге норматив хокукый базасы фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты билгеләнгән сыйфат стандартына туры килү-килмәүне бәяләүне оештырырга, шулай ук билгеләнгән критерийлар нигезендә социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген бәяләүне мониторингларга мөмкинлек бирә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары белән фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү үткәрү тәртибе расланды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 3 июль, 335 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү системасын модернизацияләү һәм үстерү концепциясен тормышка ашыру кысаларында халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре инфраструктурасын оптимальләштерү үткәрелде.

Халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре түбәндәге юллар белән үзгәртеп оештырылды:

өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекләрен хезмәтләрнең ике төрен бергә кушып эреләндерү: өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекләрен һәм өйдә социаль-медицина хезмәтләре күрсәтүче махсуслаштырылган бүлекләрне өйдә социаль хезмәт күрсәтүнең бер төренә;

эшчәнлекләре профилактика һәм тернәкләндерү характерында булмаган нәтиҗәләре аз булган бүлекләрне (вакытлы социаль хезмәт күрсәтү, социаль-

хокукый яклау, көндезге һәм вакытлыча булу бүлекләрен, социаль кибетләрне, социаль кунакханәләрне һ.б.) бетерү.

Хәзерге вакытта халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге структурасы өч бүлекне үз эченә ала: өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлеген, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлеген, социаль-тернәкләндерү бүлеген (республиканың 18 муниципаль берәмлегендә).

Нәтиҗәсез һәм нормативтан артып киткән социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең юнәлешләре үзгәртелде, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә һәм санитария-эпидемиология нормаларына җавап бирми торган учреждениеләр бетерелде.

Социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең күп өлеше эксплуатация һәм техник характеристикаларын СанПиН нормаларына туры китерүне таләп итә торган биналарда һәм бүлмәләрдә урнашкан булуны да билгеләп үтәргә кирәк.

Биналарның һәм корылмаларның бер өлеше балanska бюджет өлкәсенең башка тармакларыннан (нигездә «Сәламәтлек саклау» һәм «Мәгариф» тармакларыннан) алынган. Төп фондларның уртача тузу күрсәткече уртача 60 – 70 процент тәшкил итә.

Бу проблеманы хәл итү өчен ведомство буйсынуындагы учреждениеләргә капиталь ремонт үткәрү һәм аларны җиһазландыру максатка ярашлы булып күренә.

Социаль-савыктыру үзәкләре һәм ялгыз картлар өчен махсус торак йортлары муниципаль дәрәҗәгә тапшырылды.

Социаль ашханәләр дәүләткә карамаган секторга күчерелде.

Оптимальләштерү чараларын үткәрү нәтиҗәсендә социаль хезмәтләр саны – 40 процентка, социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре саны 16,4 процентка кыскартылды.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы халкының картлар һәм инвалидлар өчен интернат йортларда, акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар йортлары-интернатларда, балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә, халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәкләрендә, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешенең социаль гарантияләре дәрәҗәсе – 100 процент, психоневрология интернатларында – 88 процент, билгеле тору урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә – 71 процент, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә – 41 процент, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә 92 процент тәшкил итә.

Инфраструктураны һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре штат санын оптимальләштерү хисабына социаль хезмәткәрләрнең эш хакын арттыру мөмкин булмауны да билгеләп үтәргә кирәк, чөнки ул Татарстан Республикасы халкының социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешенең социаль гарантияләре дәрәҗәсе кимүгә китерәчәк.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында түбәндәгеләр эшләп тора:

2 казна учреждениесе (Кадрлар әзерләү һәм тармакны үстерү комплекслы үзәге, Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге);

12 типтагы 132 халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт учреждениесе.

Ел саен социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасының тормыш хәле авыр булган 600 меңнән артык гражданына хезмәтләр күрсәтелә.

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү системасында эшләп торучы учреждениеләр тормыш хәле авыр булган гражданнар ихтыяҗларын нигездә канәгатьләндерә, моңа өлкән яшьтәге инвалидлар өчен тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүгә һәм психоневрология интернатлары күрсәтә торган хезмәтләргә булган ихтыяҗлар керми. Моңа бәйле рәвештә, хәзерге вакытта игътибар учреждениеләр санын арттыруга түгел, ә тормыш хәле авыр булган гражданнарга күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфатын күтәрүгә бирелергә тиеш.

Социаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын күтәрү бурычы, беренче чиратта, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләнгән һәм расланган дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартлары нигезендә хәл ителә. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты билгеләнгән стандартларга туры килү-килмәүне бәяләү турында тармакта мәгълүмат җыю, аны системалаштыру, эшкәртү эше оештырылган. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийларына ирешү нәтиҗәләре (шул исәптән фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартларына туры килү-килмәү) буенча ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең рейтингы гамәлгә ашырыла.

Тармакта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфатын күтәрү максатларында учреждениеләр эшчәнлегенә тормыш хәле авыр булган гражданнарның төрле категорияләре белән социаль эшнең инновацион формаларын кертү буенча актив эш алып барыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең яңа системаларын кертү турында» 2008 ел, 18 август, 592 нче карары нигезендә бюджет өлкәсе хезмәткәрләре өчен хезмәт өчен түләүнең яңа системаларын этаплап кертү гамәлгә ашырылды.

2012 елның 1 августыннан Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы буйсынуындагы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре хезмәт өчен түләүнең яңа системасына күчү гамәлгә ашырылды.

Хезмәт түләү буенча яңа системаның бердәм тариф челтәре буенча хезмәт өчен түләү системасыннан шактый зур аермасы хезмәткәрнең эш хакы аның белеме дәрәҗәсенә һәм үзенең вазыйфаи бурычларын сыйфатлы үтәвенә турыдан-туры бәйле булуда.

Хезмәт өчен түләүнең яңа системасында башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләргә аерым игътибар бирелә, чөнки аларны куллану хезмәткәрләрнең хезмәтләре нәтиҗәләре хезмәт өчен түләү күләмнәренә бәйлелеген көчәйтүгә юнәлдерелгән. Бу түләүләрне хисаплап чыгару өчен социаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм белгечләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары эшләнде. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр

күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының чик мәгънәләренә ирешү тора.

Социаль хезмәт күрсәтү системасы белән идарә итүнең финанс механизмын камилләштерү, бюджет акчасыннан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Россия Федерациясе төбәкләреннән беренчеләрдән булып социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрен норматив-җан башы исәбеннән финанслау принцибын кертте.

Социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә дәүләткә карамаган секторны үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләткә карамаган оешмалары һәм шәхси эшмәкәрләре тарафыннан Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт заказын формалаштыру тәртибен раслау турында» 2010 ел, 12 март, 126 нчы карары белән Татарстан Республикасының дәүләткә карамаган оешмалары һәм шәхси эшмәкәрләре тарафыннан Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт заказын формалаштыру тәртибе расланды.

Татарстан Республикасында аутсорсинг шартларында тернәкләндерү хезмәтләре 2010 елдан сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга һәм яшүсмерләргә (инвалид балаларга) – Түбән Кама шәһәре территориясендә, 2012 елдан тернәкләндерү хезмәтләре – Яр Чаллы шәһәре территориясендә өлкән яшьтәге гражданнарга (шул исәптән өлкән яшьтәге инвалидларга), 2013 елдан тернәкләндерү хезмәтләре Казан шәһәре территориясендә өлкән яшьтәге гражданнарга (шул исәптән өлкән яшьтәге инвалидларга) күрсәтелә.

Социаль хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт заказы технологиясе инде кертелде дип әйтергә мөмкин, ләкин социаль хезмәтләр күрсәтүгә гариза биргән оешмалар һәм индивидуаль эшмәкәрләр саны җитәрлек түгел.

Ярдәмче программа чаралары исемлегенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү (2013 – 2018 еллар)» чаралар планын («юл картасын») раслау турында» 2013 ел, 29 май, 359 нчы карары белән расланган чаралар планыннан («юл картасыннан») аерым чаралар керде.

## II. Ярдәмче программаның төп максатлары, бурычлары һәм көтелә торган соңгы нәтиҗәләре тасвирнамәсе, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Ярдәмче программаның максаты – Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү.

Ярдәмче программаның бурычлары:

гражданнарга дәүләт социаль хезмәтләрен күрсәтү сыйфатын һәм дәрәҗәсен күтәрүне тәэмин итү;

халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге дәүләткә карамаган секторны үстерү;

тармак хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү системасын камилләштерү һәм эш хакын арттыру;

халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының матди-техник базасын ныгыту.

Гражданнарга дәүләт социаль хезмәтләрен күрсәтү дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү бурычын тормышка ашыру кысаларында халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары эшчәнлеген тәэмин итү чараларын үткәрергә кирәк.

Халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләткә карамаган секторны үстерү бурычын тормышка ашыру кысаларында дәүләткә карамаган учреждениеләрдә дәүләт социаль хезмәтләрен күрсәтүгә дәүләт заказын урнаштыру чарасын үткәрергә кирәк.

Тармак хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү системасын камилләштерү һәм эш хакын арттыру бурычын тормышка ашыру кысаларында социаль хезмәткәрләрнең хезмәтен оештыруны камилләштерү һәм эш хакы дәрәҗәсен арттыру чараларын үткәрергә кирәк.

Халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының матди-техник базасын ныгыту бурычын тормышка ашыру кысаларында матди-техник базаны камилләштерү (шул исәптән капиталь ремонт үткәрү) өчен социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларына субсидияләр бирү чараларын үткәрергә кирәк.

Максат, бурычлар һәм чаралар яктылыгында Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары турындагы мәгълүматлар Ярдәмче программага теркәлгән кушымтада китерелә.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары: 2014 – 2020 еллар.

## III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 28 450 417,625 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 28 436 545,725 мең сум, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия – 13 871,9 мең сум.

(мең сум)

| Ел | Социаль хезмәт күрсәтүгә акча күләме, барлыгы | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия |
| 2014 | 3 187 086,525 | 3 173 214,625 | 13 871,9 |
| 2015 | 3 408 478,7 | 3 408 478,7 | - |
| 2016 | 3 700 135,7 | 3 700 135,7 | - |
| 2017 | 4 266 980,1 | 4 266 980,1 | - |
| 2018 | 4 450 460,2 | 4 450 460,2 | - |
| 2019 | 4 632 929,0 | 4 632 929,0 | - |
| 2020 | 4 804 347,4 | 4 804 347,4 | - |
| Барлыгы | 28 450 417,625 | 28 436 545,725 | 13 871,9 |

Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

IV. Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы

Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыруда Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм ведомство буйсынуындагы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре катнаша.

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы түбәндәгеләрне башкара:

чараларны үтәү барышын тикшерүдә тотуны;

үтәүчеләр эшчәнлеген аларның килешеп эшләвен тәэмин итү өчен периодик хисаплылык нигезендә яраштыруны;

үтәүчеләрнең бүлеп бирелә торган финанс чараларыннан рациональ файдалануын тикшерүдә тотуны;

Ярдәмче программа чаралары яктылыгында узган чор (квартал, ел) өчен Ярдәмче программаны үтәү турында хисаплар төзүне;

Ярдәмче программаны тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган финанс чараларын исәпкә алып, Ярдәмче программа чаралары буенча максатчан күрсәткечләрне һәм чыгымнарны, Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмын һәм аны үтәүчеләр составын тәгаенләүне;

билгеләнгән тәртиптә чираттагы финанс елына Ярдәмче программа чараларын финанслауга җыелма бюджет гаризасын әзерләүне һәм кертүне.

Финанслау тәртибе, шулай ук Ярдәмче программада каралган чараларны тормышка ашыру механизмы федераль һәм республика законнары белән билгеләнгән.

Ярдәмче программаны тормышка ашыруда катнашучы ведомство буйсынуындагы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 енә кадәр, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Ярдәмче программаны тормышка ашыру, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә (алга таба – Тәртип) теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форманы тутырып, финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында статистика, белешмә һәм аналитик мәгълүмат кертә.

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 25 енә кадәр, Тәртиптә теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форманы тутырып,

2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы составындагы Ярдәмче программаны тормышка ашыру һәм финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәләлеге турында Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына җыелма статистика, белешмә һәм аналитик мәгълүмат кертә.

## V. Ярдәмче программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Ярдәмче программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр белән бәяләнә:

гражданнарга дәүләт социаль хезмәтләрен күрсәтү дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрүне тәэмин итү;

халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге дәүләткә карамаган секторны үстерү;

тармак хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү системасын камилләштерү һәм эш хакын арттыру;

халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының матди-техник базасын ныгыту.

2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасына кушымта

## 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Ярдәмче программа чараларын финанслау

| Чаралар исеме | Үтәүчеләр | Чараларны үтәү вакытлары | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Еллар буенча индикаторларның мәгънәләре | | | | | | | | Еллар буенча финанслау, мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| **Максатның исеме: Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү** | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 нче бурычның исеме: Гражданнарга дәүләт социаль хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен күтәрүне тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү | ТР ХХЭбТИ һСЯМ | 2014 – 2020 еллар | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдалануга хокуклары булган һәм аннан файдалану өчен социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына мөрәҗәгать иткән гражданнарның гомуми санында социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларында социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланган гражданнар өлеше | 95,6 | 95,6 | 96,0 | 98,7 | 99,0 | 100 | 100 | 100 | 1 988 819,425 ТРБ | 2 482 496,09 ТРБ | 2 567 217,6 ТРБ | 2 750 425,1 ТРБ | 2 868 693,4 ТРБ | 2 986 309,8 ТРБ | 3 096 803,3 ТРБ |
| | ТР ХХЭбТИ һСЯМ | 2014 2020 еллар | Татарстан Татарстан Республикасы балаларының гомуми санында күзәтүчесез балаларның чагыштырма авырлыгы, % | 0,41 | 0,40 | 0,39 | 0,39 | 0,39 | 0,38 | 0,38 | 0,38 | | | | | | | |
| | ТР ХХЭбТИ һСЯМ | 2014 – 2020 еллар | Эшчәнлекләре билгеләнгән критерийларга (стандартларга) туры килми торган халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары өлеше, % | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 нче бурычның исеме: Халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге дәүләткә карамаган секторны үстерү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Дәүләткә карамаган учреждениеләрдә дәүләт социаль хезмәтләрен күрсәтүгә дәүләт заказын урнаштыру | ТР ХХЭбТИ һСЯМ | 2014 2020 еллар | Барлык милек рәвешендәге социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында хезмәт күрсәтүләрдән файдаланган олкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның (өлкәннәрнең һәм балаларның) гомуми санында социаль хезмәт күрсәтүче дәүләткә карамаган оешмаларда хезмәт күрсәтүләрдән файдаланган олкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның (өлкәннәрнең һәм балаларның) чагыштырма авырлыгы, % | 4,5 | 4,5 | 4,6 | 4,7 | 4,8 | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 75 737,4 ТРБ | 80 040,41 ТРБ | 86 443,6 ТРБ | 96 384,6 ТРБ | 100 529,1 ТРБ | 104 650,8 ТРБ | 108 522,9 ТРБ |
| | ТР ХХЭбТИ һСЯМ | 2014 – 2020 еллар | Барлык милек рәвешендәге оешмаларның гомуми саныннан социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләткә карамаган оешмаларның чагыштырма авырлыгы, % | 0,7 | 0,7 | 0,7 | 1,4 | 1,4 | 1,4 | 1,4 | 1,4 | | | | | | | |
| 3 нче бурычның исеме: Хезмәт өчен түләү системасын камилләштерү һәм тармак хезмәткәрләренең эш хакын арттыру | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Социаль хезмәткәрләр хезмәтен оештыруны камилләштерү һәм аларның хезмәте өчен түләү дәрәҗәсен күтәрү * | ТР ХХЭбТИ һСЯМ | 2014 – 2020 еллар | Татарстан Республикасында фаразлана торган уртача эш хакы белән социаль хезмәткәрләрнең уртача эш хакы чагыштырмасы, % | 56 | 56 | 68,5 | 79 | 100 | 100 | 100 | 100 | 1 032 360,2 ТРБ | 782 816,5 ТРБ | 984 048,8 ТРБ | 1 357 744,7 ТРБ | 1 416 127,7 ТРБ | 1 474 188,9 ТРБ | 1 528 733,9 ТРБ |
| 4 нче бурычның исеме: Халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының матди-техник базасын ныгыту | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт учреждениеләренә матди-техник базаны камилләштерүгә (шул исәптән капиталь | ТР ХХЭбТИ һСЯМ | 2014 – 2020 еллар | Социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының гомуми санында СанПиН нормаларына кадәр җиткерелгән социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының чагыштырма авырлыгы, % | 50,0 | 50,5 | 59,7 | 70,1 | 80,4 | 94,2 | 95,0 | 95,0 | 62 425,7 ТРБ | 63 125,7 ТРБ | 62 425,7 ТРБ | 62 425,7 ТРБ | 65 110,0 ТРБ | 67 779,5 ТРБ | 70 287,3 ТРБ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ремонт үткәрүгә) субсидияләр бирү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Өлкәннәргә кичектергесез социаль һәм медицина-социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мобиль нигездә социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең мобиль бригадалары өчен автомобиль транспорты сатып алу | ТР ХХЭбТИ hСЯМ | 2014 ел | Өлкәннәргә кичектергесез социаль һәм медицина-социаль хезмәтләр күрсәтү буенча мобиль бригадалар эшчәнлеген тәэмин итү өчен яңа автотранспорт белән җиһазландырылган социаль хезмәт күрсәтүче территориаль комплекслы үзәкләрнең чагыштырма авырлыгы, % | 11,1 | 46,6 | - | - | - | - | - | - | 13 871,9 ТРБ | - | - | - | - | - | - |
| | | | | | | | | | | | | 13 871,9 ПФБ | - | - | - | - | - | - |
| Ярдәмче программа буенча барлыгы, шул исәптән: | | | | | | | | | | | | 3 187 086,525 | 3 408 478,7 | 3 700 135,7 | 4 266 980,1 | 4 450 460,2 | 4 632 929,0 | 4 804 347,4 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | | | | | | | | | | | | 3 173 214,625 | 3 408 478,7 | 3 700 135,7 | 4 266 980,1 | 4 450 460,2 | 4 632 929,0 | 4 804 347,4 |
| Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджеты | | | | | | | | | | | | 13 871,9 | | | | | | |

*Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен тормышка ашыру чаралары турында» 2012 ел. 7 май. 597 нче Указы нигезендә социаль хезмәткәрләр хезмәте өчен түләүне арттыруга бюджет ассигнованиеләре күрсәтелгән.

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

ТР ХХЭбТИhСЯМ – Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;
ТРБ – Татарстан Республикасы бюджеты;
ПФБ – Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджеты.

«2014 елга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору системасын формалаштыру комплекслы программасы» ярдәмче программасы

Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | 2014 елга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору системасын формалаштыру комплекслы программасы (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысы | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы |
| Ярдәмче программаның максаты | Үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне тәэмин итеп тору буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү механизмын булдыру |
| Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Ведомствоара хезмәттәшлек итү нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә яшәү урыны буенча үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны өзлексез тернәкләндерү һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү системасын оештыру;<br>2. Яшьли диагностикалауның, 0 яшьтән 4 яшькә кадәрге балаларда балалар инвалидлыгына китерә торган авыруларны дәвалауның, мөмкинлекләре чикләнгән бала һәм аның ата-анасы белән мөмкин кадәр иртәрәк коррекцияләү һәм тернәкләндерү эшенең камилләштерелгән методларын һәм формаларын кертеп тәэмин итeлә торган яшьтән үк чара күрү хезмәтенең өч дәрәҗәле системасын үстерү;<br>3. Үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне өйдә тәэмин итеп тору буенча мобиль күчмә патронаж хезмәтләре эшен оештыру;<br>4. Үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору хезмәтен булдыру; |

| | |
|---|---|
| | 5. Үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны һәм аларның гаилә әгъзаларын җәмгыятькә адаптацияләү һәм интеграцияләү программаларын тормышка ашыру;<br>6. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләр каршында үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган бала тәрбияләүче гаилә проблемаларын хәл итү буенча җәмгыять ресурсларын активлаштыру өчен ихтыярый затлар отрядларын җәлеп итү |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 ел |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 14 457,612 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 12 803,075 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән – 1 654,537 мең сум (2013 елда Тормыш хәле авыр булган балаларга ярдәм фондыннан алынган тотылмый калган акча) |
| Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | Ярдәмче программаны тормышка ашыру түбәндәгеләргә ирешергә ярдәм итәчәк:<br>сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 4 яшькә кадәрге балаларның гомуми санында яшьтән үк чара күрү кабинетларында тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүдән файдаланган сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 4 яшькә кадәрге балаларның чагыштырма авырлыгын 2014 елда 11,0 процентка кадәр җиткерүгә;<br>2014 ел эчендә Ведомствоара патронажлык итеп тору хезмәте тарафыннан ачыкланганнар һәм исәпкә куелганнар арасыннан үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны ведомствоара патронажлык итеп торуга 100 процент күләмендә тартуны тәэмин итүгә;<br>Ведомствоара патронажлык итеп тору хезмәте тарафыннан хезмәт күрсәтелә торган гаиләләрнең гомуми санынннан социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең көндез була торган бүлекләрендә социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланган (баланың авыруы дәрәҗәсе нинди булуын исәпкә алып) үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрнең чагыштырма авырлыгын 2014 елда 90 процентка кадәр җиткерүгә |

## I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсе тасвирламасы. Ярдәмче программа хәл итәргә йөз токкан проблемалар

2020 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча стратегик юнәлешләрнең берсе булып тормыш хәле авыр булган гражданнарның, шул исәптән сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән бала тәрбияләүче гаиләләрнең тереклек эшчәнлегендәге тискәре тенденцияләрне киметү тора.

2013 елда Татарстан Республикасында мөмкинлекләре чикләнгән балаларның барлык саны 14 225 кеше иде, бу 2012 ел белән чагыштырганда 1,7 процентка артыграк.

Соңгы өч ел эчендә Татарстан Республикасында беренче тапкыр инвалид дип танылган балалар яшендәге затларның абсолют саны киму күзәтелми.

Татарстан Республикасының Баш медицина-социаль экспертиза бюросы мәгълүматлары буенча, 2013 елда тикшерелгән балаларның гомуми санынннан 1 947 се инвалид дип танылган, бу 2009 ел белән чагыштырганда 12 процентка күбрәк (2009 елда – 1 732 бала иде).

2013 елда кабат инвалид дип танылган балалар саны 5 969 кеше, ягъни «инвалид бала» категориясен билгеләү өчен кабат тикшерелгәннәр санынннан 86,7 процент тәшкил итә.

Якынча 3000 баланың (Татарстан Республикасындагы барлык инвалид балаларның 20 проценты) үсешендә һәм сәламәтлегендә күп төрле җитешсезлекләр бар, шул исәптән 700 бала – Казан шәһәренеке, шулардан якынча тиешенчә 340 һәм 80 бала сирәк очрый торган генетик авырулар белән авырый.

Инвалид бала статусы булган балалардан тыш, тагын 7 - 8 процент укырга сәләтсез балаларны, үз-үзләрен тота алмауда һәм үсешләрендәге башка кимчелекләрдә чагыла торган чикле мөмкинлекләргә ия булган балаларны исәпкә алсак, республикада барлык балаларның якынча 10 проценты диярлек комплекслы социаль-медицина тернәкләндерүенә мохтаҗ булу ачык күренә һәм моның өчен инвалидлаштыру хәлләрен профилактикалау чараларын формалаштыру таләп ителә.

Инвалид баланы тернәкләндерү чараларын тормышка ашыру буенча дәүләт гарантиясен тәэмин итүдә төп инструмент булып тернәкләндерүнең шәхси программасы тора.

Тернәкләндерү чаралары медицина учреждениеләре һәм социаль хезмәтләр арасында өзлексез тормышка ашырыла. Балалар дәвалану-профилактика учреждениеләре, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләре базасында тернәкләндерүнең төп курсын үткәннән соң республиканың 25 муниципаль берәмлегендә халыкка социаль хезмәт күрсәтүче комплекслы үзәкләр каршында эшләп торучы социаль-тернәкләндерү бүлекләренә

җибәреләә.

Яшьтән үк чара күрү проблемасын хәл итү буенча нәтиҗәле ведомствоара хезмәттәшлек итү мәсьәләләре республикада элеккечә актуаль булып кала. Балалар инвалидлыгы проблемаларының медицинага һәм социаль өлкәгә караган өлешләре аеруча әһәмиятле. Моның белән бергә, инвалид балаларга һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән сабый балаларга системалы ярдәм күрсәтүнең, реабилитацияләүнең һәм тернәкләндерүнең, аларны җәмгыятькә интеграцияләүнең максаты булып балалар потенциалын (хәрәкәтләнү, коммуникация, танып-белү мөмкинлекләрен, көндәлек тормышта һәм үзара социаль хезмәттәшлек итү күнекмәләрен) мөмкин булган кадәр үстерү тора.

2012 – 2013 елларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2012-2014 елларга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронаж тәэмин итү системасын формалаштыру комплекслы программасы» озак вакытлы максатчан программасын раслау турында» 2012 ел, 16 ноябрь, 991 нче карары нигезендә Фондның финанс (грант) ярдәме белән республикада «2012 - 2014 елларга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору системасын формалаштыру комплекслы программасы» озак вакытлы максатчан программасын (алга таба – Комплекслы программа) тормышка ашыру буенча актив эш башкарылды.

Аны тормышка ашыруда республиканың 8 муниципаль берәмлеге: «Казан шәһәре» һәм «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округлары, Чистай, Зәй, Бөгелмә, Түбән Кама, Алабуга һәм Менделеевск муниципаль районнары катнашты.

Бу карар белән экспертиментать мәйданчыклар - республиканың сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре билгеләнде, алар базасында этаплап программа чаралары үткәрелде.

2012 – 2014 елларда Комплекслы программаны тормышка ашыруда республиканың 19 учреждениесе: 11 сәламәтлек саклау учреждениесе һәм 8 социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе катнашты.

Ике ел эчендә үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору буенча өч дәрәҗәле система сынап каралды:

тәэмин итеп торуның беренче баскычы – сәламәтлек саклау учреждениеләре тарафыннан яшьтән үк чара күрү хезмәте технологиясен куллану;

йөкле хатыннар өчен бала тудыруга кадәрге патронажны, бала тугач 0 яшьтән 2 яшькә кадәрге бала патронажын: бала тудыру йорты – балалар поликлиникасы – тернәкләндерү үзәге комплексы базасында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре

чикләнгән балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм тәэмин итеп торуны оештыру;

икенче баскыч – яшьтән үк чара күрү хезмәте һәм өйгә килеп ярдәм күрсәтү хезмәте белгечләре тарафыннан бергәләп гаиләләргә патронажлык итүне гамәлгә ашыру;

2 яшьтән алып 3 яшь 11 айга кадәрге баланы һәм аның гаиләсе әгъзаларын яшьтән үк чара күрү һәм өйгә килеп ярдәм күрсәтү хезмәте белгечләре тарафыннан бергәләп тәэмин итү;

өченче баскыч – социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре тарафыннан өйгә килеп ярдәм күрсәтү хезмәте технологиясен куллану.

Балага 4 яшь тулганнан соң, баланың функциональ кимчелекләре булса, яшьтән үк чара күрү хезмәте гаиләне тәэмин итеп торуны өйгә килеп ярдәм күрсәтү хезмәтенә тапшыра.

Барлык баскычларда эш күчмә һәм ярымстационар формада алып барыла.

Комплекслы программа кысаларында 2012 - 2013 елларда кертелгән үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны тәэмин итеп торуның ведомствоара системасы нәтиҗәлелеге база мәйданчыклары эшчәнлеге нәтиҗәләре белән раслана.

Республиканың 8 муниципаль районында ведомствоара тәэмин итеп торуга мохтаҗ булган сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларның ведомствоара мәгълүматлар банкы төзелде; 6 муниципаль районда эшләре сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалы гаиләләргә ярдәм күрсәтү программасын адреслы гамәлгә ашыруда булышкан җирле тернәкләндерү комитетлары төзелде һәм актив эшли; яшьли диагностикалауның, 0 яшьтән 4 яшькә кадәрге балалар авыруларын дәвалауның камилләштерелгән методларыннан һәм формаларыннан файдаланып, яшьтән үк чара күрү хезмәтенең өч дәрәҗәле системасы эшли; республиканың сәламәтлек саклау учреждениеләре базасында 9 яшьтән үк чара күрү кабинеты эше оештырылган (шул исәптән 3 се яңа ачылган). «Сонатал» программасы кысаларында сәламәтлек саклау учреждениеләре тарафыннан бала яралгысында тумыштан килә торган авыруларны диагностикалау һәм 5 643 йөкле хатын-кызны бала табуга әзерләү; тиешенчә яңа туган 71 600 һәм 71 393 балага неонаталь һәм аудилогик скрининг үткәрелгән.

2012 – 2013 елларда Комплекслы программаны тормышка ашыру кысаларында республикадагы 8 муниципаль районның 6 сында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләрне яшьтән үк чара күрү хезмәте һәм өйгә килеп ярдәм күрсәтү хезмәте белгечләре тарафыннан бергәләп тәэмин итү оештырылды.

Социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре базасында яңа хезмәтләр һәм кабинетлар булдырылды, аларның белгечләре сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләр белән уңышлы эшләп тора.

Шулай итеп, 2012 елда белем бирү учреждениеләренә йөрми торган сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән, үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә күп төрле җитешсезлекләр булган балалы (алга таба – максатчан төркемдәге балалар) 70 гаиләләргә патронажлык иткән өйдә килеп ярдәм күрсәтү хезмәтләре оештырылды, 2013 елда максатчан төркемдәге балалы 99 гаиләнең 30 проценты сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсе белгечләре тарафыннан бергәләп тәэмин итеп торылды. Комплекслы программа тормышка ашырылган ике ел эчендә 2 465 тапкыр өйгә килеп ярдәм күрсәтү оештырылды.

Мобиль бригадалар төзелде, алар максатчан төркемдәге балалы гаиләләргә 570 тапкыр барды, шулай ук инвалидка әйләнү куркынычы югары булган балалар (алга таба – үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә җитешсезлекләр булган балалар) һәм инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләрнең өйләренә барып 153 тапкыр ярдәм күрсәтелде.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче ата-аналар өчен 8 консультация-өйрәтү бүлмәләре эшли; ике ел эчендә максатчан төркемдәге балалы 138 гаилә һәм үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә җитешсезлекләр булган балалар тәрбияли торган 565 гаилә хезмәт күрсәтүдән файдаланды.

Лекотекалар оештырылды, аларда 1 809 дәрес оештырылды, аларга максатчан төркемдәге 101 бала, үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә җитешсезлекләр булган 613 бала тартылды.

Көндез була торган бүлекләр ачылды. 2013 елда көндез була торган бүлекләрдә максатчан төркемдәге 160 бала һәм үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә җитезсезлекләр булган 757 бала катнашында 1441 дәрес үткәрелде.

8 территориаль эш белән тәэмин итү үзәгенә сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән ата-аналар исемлекләре җибәрелде. Ике ел эчендә сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән бала тәрбияләүче 178 ата-анага һөнәри консультация бирелде, 18 ата-ана эшкә урнаштырылды.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә 8 ихтыярый отрядтан 140 тан артык волонтер актив ярдәм итә. Алар анимация чаралары үткәрә, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә түземле һәм дустанә мөнәсәбәт булдыру тәҗрибәсен тарата, хәйрия акцияләре үткәрә.

Авыр, ләкин нәтиҗәле эш йомгаклары үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә җитешсезлекләр булган балаларны тәэмин итеп тору буенча эш системасы дөрес сайлану һәм бу тәҗрибәне республикада таратырга кирәк булу турында сөйли.

2012 – 2013 елларда комплекслы программа чараларын тормышка ашыруга Фонд 27 700,0 мең сум күләмендә акча бүлеп бирде. Бу акча тернәкләндерү җиһазлары һәм автомобильләр сатып алуга, белгечләрне өйрәтүгә түләүгә, җәлеп ителгән белгечләр (логопед, табиб-невролог, дәвалау-физик культура инструкторы) күрсәтә торган хезмәтләргә түләү өчен тотылды.

Татарстан Республикасында Комплекслы программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга ярдәм күрсәткәндә беренче тапкыр нәтиҗәсе индикаторларның мәгънәләре, Комплекслы программа кысаларында белгечләр күрсәтә торган хезмәтләргә ихтыяҗның зур булуы белән раслана торган ведомствоара хезмәттәшлек механизмы булдырылды, сәламәтлек саклау һәм социаль яклау системасында балаларның реаль инклюзиясе өчен шартлар тудырылды. Сәламәтлек саклау һәм социаль яклау өлкәсе белгечләре хәзер заманча, шул исәптән төбәк шартларына җайлаштырылган уникаль чит ил технологияләре буенча эшли, шуна күрә алар күрсәтелә торган ярдәмне тагын да адреслырак һәм нәтиҗәлерәк итә ала.

Максатчан төркемдәге балалар тәрбияләүче гаиләләр арасындагы киеренкелекнең сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә заманча тернәкләндерү җиһазлары ярдәмендә социаль хезмәтләр күрсәтү, алардан файдалана алу дәрәҗәсен күтәрү аркасында күзгә күренеп кимүе Комплекслы программаның зур уңышы булып тора.

Фонд тарафыннан Комплекслы программага финанс ярдәме күрсәтү нәтиҗәсендә эксперименталь база мәйданчыкларының матди-техник базасы шактый яхшыртылды, моның өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акча бүлеп бирү дә таләп ителмәде.

Шулай да, «Бюджет процессы камилләштерелүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел, 7 май, ФЗ-104 нче Федераль закон үз көченә керү белән 2014 елдан федераль һәм төбәк дәрәҗәләрендә дәүләт программаларын формалаштыруның һәм тормышка ашыруның хокукый нигезләре кертелү белән бер үк вакытта озак вакытлы максатчан программалар формалаштыруның һәм тормышка ашыруның хокукый нигезләре төшереп калдырылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы (алга таба – Программа) кабул ителү белән Комплекслы программа үз көчен югалтты.

Комплекслы программаның 2014 елда үткәрергә планлаштырылган, шул исәптән 1 654,537 мең сум күләмендә Фонд исәбеннән финанслана торган чаралар үткәрелми калды.

«Халыкка социаль-психологик ярдәм күрсәтү буенча «Зеркало» республика үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә Комплекслы программаны кертүне оештыру-методик яктан тәэмин итү функцияләре беркетелгән, шул исәптән:

семинарлар (оештыру, проектлы, өйрәткеч) һәм киңәшмәләр оештыру;

методик фонд төзү; сайтка мәгълүмати һәм техник ярдәм күрсәтү;

сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче ата-аналар өчен консультатив-өйрәтү бүлмәләрендә һәм лекотекада эш оештыру;

программа чараларын тормышка ашыручы белгечләргә супервизор ярдәме күрсәтүне оештыру;

Казан шәһәрендә волонтерлар отрядын төзү.

Комплекслы программа чараларын тормышка ашыруда сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләгә сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә карата түземле һәм дустанә мөнәсәбәтне үстерүдә, социаль-мәдәни анимация рәвешендә иҗади тернәкләндерүнең төрле формаларын (бәйрәмнәр, фестивальләр, форумнар, акцияләр һ.б.) үткәрүдә волонтерлар, шул исәптән баланың ассистенты буларак, саллы ярдәм күрсәтте.

2014 елда Комплекслы программа белән күздә тотылган чараларны тормышка ашыруны тәгәлләү, көтелә торган соңгы нәтиҗәләргә ирешү, максатчан төркемдәге балалар тәрбияләүче гаиләләрне тәэмин итеп торуның ведомствоара хезмәттәшлек механизмын булдыру буенча уңай тәҗрибә тарату, 2014 елда Фондтан грант рәвешендә 5 487,032 сумлык финанслашу алу максатыннан чыгып, Программа составында «2014 елга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне яшәү урыны буенча ведомствоара патронаж тәэмин итеп тору системасын формалаштыру комплексы программасы» дигән аерым ярдәмче программа (алга таба – Ярдәмче программа) эшләнде.

## II. Ярдәмче программаның максаты, бурычлары, программа чаралары, көтелә торган соңгы нәтиҗәләрне тасвирлау, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Ярдәмче программаның максаты – үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне тәэмин итеп тору буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү механизмын булдыру.

Ярдәмче программаның бурычлары:

ведомствоара хезмәттәшлек нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә яшәү урыны буенча үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны өзлексез тернәкләндерү системасын һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтүне оештыру;

яшьли диагностикалауның, 0 яшьтән 4 яшькә кадәрге балаларда балалар инвалидлыгына китерә торган авыруларны дәвалауның, мөмкинлекләре чикләнгән бала һәм аның ата-анасы белән мөмкин кадәр иртәрәк коррекцияләү һәм тернәкләндерү эшенең камилләштерелгән методларын һәм формаларын кертеп тәэмин ителә торган яшьтән үк чара күрү хезмәтенең өч дәрәҗәле системасын үстерү;

үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә мобиль күчмә патронаж хезмәтләре эшен оештыру;

үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору хезмәтен булдыру;

үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны һәм аларның гаиләләре әгъзаларын җәмгыятькә адаптацияләү һәм интеграцияләү программаларын тормышка ашыру;

халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре каршында үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган бала тәрбияләүче гаилә проблемаларын хәл итү буенча җәмгыять ресурсларын активлаштыру өчен ихтыярый затлар отрядларын җәлеп итү.

Ярдәмче программа кысаларында түбәндәге чаралар гамәлгә ашырыла:

1. Ведомствоара хезмәттәшлек нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны өзлексез тернәкләндерү һәм аларның гаиләләренә яшәү урыны буенча ярдәм күрсәтү системасын оештыру.

1.1. Ярдәмче программаны тормышка ашыру буенча эшче төркемнең еллык ачык киңәшмәсен үткәрү;

1.2. Яңа кертелә торган хезмәтләргә тикшерү максатында бару;

1.3. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә ведомствоара патронажлык итеп тору хезмәтләре эшчәнлеген оештыру максатларында ведомство норматив актларын кабул итү;

2. Яшьли диагностикалауның, 0 яшьтән 4 яшькә кадәрге балаларда балалар инвалидлыгына китерә торган авыруларны дәвалауның, мөмкинлекләре чикләнгән бала һәм аның ата-анасы белән мөмкин кадәр иртәрәк коррекцияләү һәм тернәкләндерү эшенең камилләштерелгән методларын һәм формаларын кертеп

тәэмин ителә торган яшьтән үк чара күрү хезмәтенең өч дәрәҗәле системасын үстерү.

2.1. Хатын-кызлар консультациясе – бала тудыру йорты – балалар хастаханәсе – балалар поликлиникасы – тернәкләндерү үзәге – шифаханә комплексы базасында яшьтән үк чара күрү хезмәтен алга таба үстерү;

2.1.1. «Сонатал» программасы – бала тапканга кадәрге диагностика;

2.1.2. Бала яралгысының тумыштан килә торган авыруларына пренаталь (бала тапканга кадәр) диагностика үткәрү һәм йөкле хатынны бала тудыруга әзерләү;

2.1.3. Балаларның яши башлаган беренче көннәрендә тумыштан килә торган авыруларын ачыклау максатыннан тикшерү;

2.1.3.1. Аудиологик скрининг;

2.1.3.2. Неонаталь скрининг;

2.1.4. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Казан шәһәре) базасында, яшьтән үк чара күрү технологиясен кулланып, үсешләрендә тайпылышлар булган балаларны комплекслы тернәкләндерү;

2.1.5. «8 нче балалар шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Казан шәһәре), «Кама балалар медицина үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Яр Чаллы шәһәре) базасында, яшьтән үк чара күрү технологиясен кулланып, үсешләрендә тайпылышлар булган балаларны комплекслы тернәкләндерү;

2.1.6. Яшьтән үк чара күрү хезмәтен алга таба үстерү, камилләштерү һәм киңәйтү;

2.1.6.1. «Республика балалар психоневрология шифаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Казан шәһәре) базасында, яшьтән үк чара күрү технологиясен кулланып, үсешләрендә тайпылышлар булган балаларны комплекслы тернәкләндерү;

2.1.6.2. Республика балалар амбулатория-поликлиника учреждениеләре базасында, яшьтән үк чара күрү технологиясен кулланып, үсешләрендә тайпылышлар булган балаларны диагностикалау һәм комплекслы тернәкләндерү: яшьтән үк чара күрү хезмәтен алга таба үстерү;

2.1.6.3. Яңа яшьтән үк чара күрү (яшьтән үк чара күрү технологиясен кулланып, үсешләрендә тайпылышлар булган балаларны диагностикалау һәм комплекслы тернәкләндерү) кабинетларын ачу һәм аларның эшен оештыру;

2.1.7. «Республика сабыйлар йорты, махсуслаштырылган» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында, яшьтән үк чара күрү технологиясен кулланып, үсешләрендә тайпылышлар булган, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны комплекслы тернәкләндерү.

3. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләрне өйдә мобиль күчмә тәэмин итеп тору хезмәтләре эшен оештыру;

3.1. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә өйдә патронаж хезмәте күрсәтү хезмәтләре эшчәнлеген оештыру;

3.2. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча патронажлык итеп тору технологиясе буенча белгечләр өчен база белем бирү курсларын үткәрү;

3.3. Өйгә килеп ярдәм күрсәтү хезмәте белгечләре тарафыннан максатчан төркемдәге балалар тәрбияләүче гаиләләргә патронажлык итү;

3.4. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче ата-аналар өчен консультация-өйрәтү кабинетлары эшчәнлеген оештыру;

3.5. «Халыкка социаль-психологик ярдәм күрсәтү буенча «Зеркало» республика үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе каршындагы Ведомствоара супервизорлык хезмәтен төзү аша супервизорлык ярдәме күрсәтүнең өч дәрәҗәле системасын оештыру;

3.6. Республикада технологияне кертүдә катнашучы белгечләр өчен (тормышка ашырыла торган бөтен чор эчендә) сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору хезмәте сайтына мәгълүмати һәм техник ярдәм күрсәтү;

3.7. Үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору республика хезмәте белгечләре өчен методик, фәнни әдәбият һәм өйрәткеч видеодәресләр фондын актуальләштерү;

4. Үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору хезмәтен булдыру.

4.1. Ярдәмче программаны социаль хезмәт күрсәтү һәм сәламәтлек саклау учреждениеләре эшчәнлегенә кертү буенча еллык республика оештыру семинарын үткәрү;

4.2. Ярдәмче программаны тормышка ашыруны оештыру ягыннан тәэмин итү буенча проект семинарларын үткәрү;

4.3. Бергәләп патронажлык итү мәсьәләләрен хәл итү буенча яшьтән үк чара күрү һәм өйгә килеп ярдәм күрсәтү хезмәтләренең ведомствоара киңәшмәләрен үткәрү;

4.4. Яшьтән үк чара күрү, өйгә килеп ярдәм күрсәтү хезмәтләренең һәм башка ведомстволар белгечләренең тәэмин итеп торуына мохтаҗ булган сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларның ведомствоара мәгълүматлар банкын булдыру;

4.5. Муниципаль берәмлекләрдә җирле тернәкләндерү комитетлары эшен оештыру;

4.6. Супервизорлар һәм методистлар өчен оештыру һәм методик супервизияләр үткәрү;

4.7. Экспериментал мәйданчыклар эшчәнлеге турында мәгълүматлар җыю, аларны кулланышка кертү нәтиҗәләрен күзәтеп тору, нәтиҗәлелеген мониторинглау һәм бәяләү, хисаплар (шул исәптән финанс хисапларын) әзерләү, алар белән идарә итү механизмнары һәм аларны норматив-хокукый тәэмин итү буенча тәкъдимнамәләр, белгечләрнең эш регламентын (Ярдәмче программа тормышка ашырылган бөтен чор эчендә) әзерләү.

5. Үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны һәм аларның гаилә әгъзаларын җәмгыятькә адаптацияләү һәм интеграцияләү программаларын тормышка ашыру.

5.1. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча территориаль комплекслы үзәкләр базасында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар, шул исәптән максатчан төркемдәге балалар өчен көндез була торган бүлекләр эшчәнлеген оештыру;

5.2. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән эшләүдә инновацион социаль технологияләрдән файдалану буенча социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре белгечләре өчен өйрәтү семинары үткәрү;

5.3. Үстерү һәм тернәкләндерү җиһазларыннан, лекотекадан файдаланып, социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре базасында, шул исәптән көндез була торган бүлекләрдә, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән дәресләр оештыру;

5.4. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче ата-аналарга ярдәм күрсәтү программаларын тормышка ашыру;

5.4.1. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче ата-аналарның үзара ярдәмләшү клублары эшчәнлеген оештыру;

5.5. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә һөнәри консультацияләр бирүне оештыру.

6. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча территориаль комплекслы үзәкләр каршында үсешендә һәм сәламәтлегендә тайпылышлар булган бала тәрбияләүче гаилә проблемаларын хәл итү буенча җәмгыять ресурсларын активлаштыру өчен ихтыярый затлар отрядларын җәлеп итү.

6.1. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә анимация чараларын оештыру һәм үткәрү, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә карата түземле һәм дустанә мөнәсәбәтләр

булдыру тәҗрибәсен тиражлау өчен студентлар һәм мәктәп укучылары (80 кеше) арасыннан ихтыярый затларның 8 отряды эшен оештыру;

6.2. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларны интеграцияләү һәм адаптацияләү программаларын тормышка ашыруга волонтерлар җәлеп итү;

6.3. Волонтерлар катнашында белем бирү оешмаларында, югары белем бирүче мәгариф учреждениеләрендә, һөнәр белеме бирү учреждениеләрендә «Толерантлык дәресләре. Дусларыбыз – мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм сәламәтлекләре какшаган балалар» чарасын, шулай ук бу категория белән эшләүче белгечләрдә (табибларда, педагогларда, психологларда, социаль хезмәткәрләрдә) түземле һәм дустанә мөнәсәбәт формалаштыру буенча махсус дәресләр үткәрү.

Максат, бурычлар һәм чаралар яктылыгында Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары турындагы мәгълүматлар Ярдәмче программага теркәлгән кушымтада китерелә.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты – 2014 ел.

## III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 14 457,612 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 12 803,075 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән – 1 654,537 мең сум (2013 елда Тормыш хәле авыр булган балаларга ярдәм фондыннан алынган тотылмый калган акча)

## IV. Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы

Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысы – Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы.

Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары - Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – ТР ХХЭбТИһСЯМ) һәм Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы (алга таба – ТР ССМ).

Ярдәмче программаны үтәүчеләр – ТР ХХЭбТИһСЯМ һәм ТР ССМ ведомство буйсынуындагы учреждениеләр, «Татарстан Республикасы психологлары ассоциациясе» коммерциягә карамаган партнерлыгы (алга таба - Татарстан Республикасы психологлары ассоциациясе).

ТР ССМ квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 енә кадәр, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Ярдәмче программаны тормышка ашыру, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә (алга таба – Тәртип) теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форманы тутырып, финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында статистика, белешмә һәм аналитик мәгълүмат кертә.ТР ХХЭбТИһСЯМ квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 25 енә кадәр, Тәртиптә теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форманы тутырып, 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы составындагы Ярдәмче программаны тормышка ашыру һәм финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына җыелма статистика, белешмә һәм аналитик мәгълүмат кертә.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру кысаларында үтәүчеләрнең түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыруы күздә тотыла:

Ярдәмче программаны яраштыру түбәндәгеләргә йөкләнә:

республика дәрәҗәсендә – Ярдәмче программаны тормышка ашыру буенча эшче төркемгә;

муниципаль берәмлекләр дәрәҗәсендә – җирле тернәкләндерү комитетларына;

хезмәтләрне оештыру-методик һәм белем бирү ягыннан тәэмин итеп тору, җыелма хисаплылыкны формалаштыру компетенция буенча «Халыкка социаль-психологик ярдәм күрсәтү буенча «Зеркало» республика үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә һәм ТР ССМ йөкләнә;

хезмәтләрне матди-техник җиһазландыру Татарстан Республикасы психологлары ассоциациясенә йөкләнә;

Ярдәмче программаны тормышка ашыру буенча ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген тикшерүдә тоту түбәндәгеләргә йөкләнә:

социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре өлешендә – «Халыкка социаль-психологик ярдәм күрсәтү буенча «Зеркало» республика үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә һәм Татарстан Республикасы психологлары ассоциациясенә;

сәламәтлек саклау учреждениеләре өлешендә – ТР ССМ на.

## V. Ярдәмче программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Ярдәмче программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр белән бәяләнә:

ведомствоара хезмәттәшлек нигезендә Татарстан Республикасының 8 муниципаль районында яшәү урыны буенча үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларга һәркем алырлык һәм нәтиҗәле медицина һәм социаль тернәкләндерүен һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларның сәламәтлекләре торышын яхшырту, аларның тернәкләнү потенциалын максималь дәрәҗәдә үстерү, социаль статусларын күтәрү;

республиканың дәүләт сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре матди-техник базасын ныгыту;

учреждениеләр белгечләренең квалификациясен күтәрү;

сәламәт булмаган бала тәрбияләүче гаиләгә ярдәмгә ассистентлар буларак волонтерлар җәлеп итү;

хәйрия акцияләре үткәрү.

«2014 елга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлары булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне яшәү урыны буенча ведомствоара хезмәттәшлекне тәэмин итү системасын төзүнең комплекслы программасы» ярдәмче программасына кушымта

«2014 елга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне яшәү урыннары буенча ведомствоара патронаж тәэмин итеп тору системасын формалаштыру комплекслы программасы» ярдәмче программасы максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм ярдәмче программа чараларын финанслау

| Чаралар исеме | Үтәүчеләр | Чара-ларны башкару вакыт-лары | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторлар мәгънәсе | | Финанслау, мең сум | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2014 г. | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | бюджеттан тыш чыганаклар |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| **Максатның исеме:** Үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне тәэмин итеп тору буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү механизмын булдыру | | | | | | | |
| **1 нче бурычның исеме**: Ведомствоара хезмәттәшлек нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны өзлексез тернәкләндерү һәм аларның гаиләләренә яшәү урыны буенча ярдәм күрсәтү системасын оештыру | | | | | | | |
| 1.1. Ярдәмче программаны тормышка ашыру буенча эшче төркемнең еллык ачык киңәшмәсен үткәрү | ТР ХХЭбТИһСЯМ | 2014 ел | эшче төркем үткәргән киңәшмәләр саны, елга бер тапкыр | 1 | 1 | - | - |
| 1.2. Яңа кертелә торган хезмәтләргә тикшерү максатында бару | ХСПЯК «Зеркало» РУ ДАСХКУ | 2014 ел эчендә | Татарстан Республикасы муниципаль районнары – Программаны тормышка ашыруда катнашучыларның төзелгән социаль паспортлары саны, данә | 12 | 41 | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.3. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә ведомствоара патронаж тәэмин итеп тору хезмәтләре эшчәнлеген оештыру максатларында ведомство норматив актларын кабул итү | ТР ХХЭбТИһСЯМ, ТР ССМ | 2014 ел | Татарстан Республикасы муниципаль районнарында үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне ведомствоара патронаж тәэмин итеп тору хезмәте турындагы нигезләмәне раслау, әйе (юк) | да | да | - | - |
| **2 нче бурычның исеме**: Яшьли диагностикалауның, 0 яшьтән 4 яшькә кадәрге балаларда балалар инвалидлыгына китерә торган авыруларны дәвалауның, мөмкинлекләре чикләнгән бала һәм аның ата-анасы белән мөмкин кадәр иртәрәк коррекцияләү һәм тернәкләндерү эшенең камилләштерелгән методларын һәм формаларын кертеп тәэмин итәлә торган яшьтән үк чара күрү хезмәтенең өч дәрәҗәле системасын үстерү | | | | | | | |
| 2.1. Хатын-кызлар консультациясе – бала тудыру йорты – балалар хастаханәсе – балалар поликлиникасы – тернәкләндерү үзәге – шифаханә комплексы базасында яшьтән үк чара күрү хезмәтен алга таба үстерү | ТР ССМ | ел эчендә | | | | | |
| 2.1.1. «Сонатал» программасы – бала тапканга кадәрге диагностика | ТР ССМ | ел эчендә | гаиләләрне «Сонатал» программасы буенча бала табуга әзерләү һәм бала тудырганга кадәр диагностикалауга тарту, гаиләләр саны | 5 493 | 150 | - | - |
| 2.1.2. Бала яралгысының тумыштан килә торган авыруларына пренаталь (бала тапканга кадәр) диагностика үткәрү һәм йөкле хатынны бала тудыруга әзерләү. «Сонатал» программасы – бала тапканга кадәрге диагностика | ТР ССМ | ел эчендә | йөкле хатын-кызларны «Сонатал» программасы буенча яралгыда тумыштан килә торган авыруларны ачыклау буенча бала тудырганга кадәр диагностикалауга тарту, кеше | 43 075 | 60 | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.1.3. Балаларның яши башлаган беренче көннәрендә тумыштан килә торган авыруларын ачыклау максатыннан тикшерү | ТР ССМ | ел эчендә | | | | | |
| 2.1.3.1. Аудиологик скрининг | «ТР ССМ БРКХ» ДАССУ (Казан шәһәре) | ел эчендә | тумыштан килә торган авыруларны ачыклау максатында яңа туган балаларны аудиологик скринингка тарту, кеше | 55 393 | 16 000 | - | - |
| 2.1.3.2. Неонаталь скрининг | «ТР ССМ БРКХ» ДАССУ (Казан шәһәре) | ел эчендә | тумыштан килә торган авыруларны ачыклау максатында яңа туган балаларны неонаталь скринингка тарту, кеше | 55 600 | 16 000 | - | - |
| 2.1.4. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Казан шәһәре) базасында, яшьтән үк чара күрү технологиясен кулланып, үсешләрендә тайпылышлар булган балаларны комплексны тернәкләндерү | «ТР ССМ БРКХ» ДАССУ (Казан шәһәре) | ел эчендә | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» ДАССУ (Казан шәһәре) базасында үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны махсуслаштырылган тернәкләндерү ярдәме күрсәтүгә тарту, кеше | 220 | 300 | - | 556,917* |
| 2.1.5. «8 нче балалар шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Казан шәһәре), «Кама балалар медицина үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Яр Чаллы шәһәре) базасында, яшьтән үк чара күрү технологиясен кулланып, үсешләрендә | «8 нче БШХ» ДАССУ (Казан шәһәре); «Кама балалар медицина үзәге» ДАССУ (Яр Чаллы шәһәре) | ел эчендә | 8 нче балалар шәһәр хастаханәсе» ДАССУ (Казан шәһәре) һәм «Кама балалар медицина үзәге» ДАССУ (Яр Чаллы шәһәре) базасында үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны махсуслаштырылган тернәкләндерү | 844 | 300 | - | 400,0* |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| тайпылышлар булган балаларны комплексы тернәкләндерү | | | ярдәме күрсәтүгә тарту, кеше | | | | |
| 2.1.6. Яшьтән үк чара күрү хезмәтен алга таба үстерү, камилләштерү һәм киңәйтү | ТР ССМ | ел эчендә | | | | | |
| 2.1.6.1. «Республика балалар психоневрология шифаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Казан шәһәре) базасында, яшьтән үк чара күрү технологиясен кулланып, үсешләрендә тайпылышлар булган балаларны комплексы тернәкләндерү | «РБПШ» ДАССУ (Казан шәһәре) | ел эчендә | «Республика балалар психоневрология шифаханәсе» ДАССУ (Казан шәһәре) базасында үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны махсуслаштырылган тернәкләндерү ярдәме күрсәтүгә тарту, кеше | 945 | 200 | - | - |
| 2.1.6.2. Республика балалар амбулатория-поликлиника учреждениеләре базасында, яшьтән үк чара күрү технологиясен кулланып, үсешләрендә тайпылышлар булган балаларны диагностикалау һәм комплексы тернәкләндерү: яшьтән үк чара күрү хезмәтен алга таба үстерү | «Чистай ҮРХ» ДАССУ»; «9 нчы БШП» ДАССУ (Казан шәһәре); «2 нче БШП» ДАССУ (Яр Чаллы шәһәре) | ел эчендә | республика балалар амбулатория-поликлиника учреждениеләре базасында үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны комплексы махсуслаштырылган тернәкләндерү ярдәме күрсәтүгә тарту: яшьтән үк чара күрү хезмәтен алга таба үстерү, кеше | 467 | 300 | - | - |
| 2.1.6.3. Яңа яшьтән үк чара күрү (яшьтән үк чара күрү технологиясен кулланып, үсешләрендә тайпылышлар булган балаларны диагностикалау һәм комплексы тернәкләндерү) кабинетларын ачу һәм аларның эшен | «Перинаталь үзәк белән БШХ» ДАССУ (Түбән Кама шәһәре); «ТР ССМ БРКХ» ДАССУ (Казан шәһәре) | ел эчендә | сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән мохтаж балаларның гомуми саныннан диагностика һәм тернәкләндерү ярдәменә тартылган сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар- | 100 | 98 | - | 400,0* |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| оештыру | | | ның чагыштырма авырлыгы, процент | | | | |
| 2.1.7. Республика сабыйлар йорты, махсуслаштырылган» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Казан шәһәре) базасында, яшьтән үк чара күрү технологиясен кулланып, үсешләрендә тайпылышлар булган, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны комплексы тернәкләндерү | «РСЙМ» ДАССУ (Казан шәһәре) | ел эчендә | «Республика сабыйлар йорты, махсуслаштырылган» ДАССУ базасында үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны комплексы махсуслаштырылган тернәкләндерү ярдәменә тарту, кеше | 283 | 120 | - | - |
| **3 нче бурычның иseме:** Үсешләрендә һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләрне өйдә мобиль күчмә тәэмин итеп тору хезмәтләре эшен оештыру | | | | | | | |
| 3.1. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә өйдә патронаж хезмәте күрсәтү хезмәтләре эшчәнлеген оештыру | ТР ХХЭбТИһСЯМ, 45 ХСХККҮ | ел эчендә | сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә ярдәм күрсәтү хезмәтләре саны, берәмлек | 8 | 45 | 12 503,075 | - |
| 3.2. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча патронажлык итеп тору технологиясе буенча белгечләр өчен база белем бирү курсларын үткәрү | ТР ХХЭбТИһСЯМ, ХСПЯК «Зеркало» РҮ ДАСХКУ, КП «ТР ПА» | IV квартал | белгечләрне сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләрне яшәү урыны буенча патронажлык итеп тору технологиясе буенча база белем бирү курсларында өйрәтүгә тарту, кеше | 40 | 40 | - | - |
| 3.3. Өйгә килеп ярдәм күрсәтү хезмәте белгечләре тарафыннан максатчан төркемдәге балалар тәрбияләүче гаиләләргә патронажлык итү | ТР ХХЭбТИһСЯМ база мәйданчыклары | ел эчендә | максатчан төркемдәге балалар тәрбияләүче ата-аналарны өйдә патронаж тәэмин итеп торуга тарту, кеше | 99 | 80 | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.4. Сәламәтлекләренең мөмкин-лекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче ата-аналар өчен консультация-өйрәтү кабинетлары эшчәнлеген оештыру | ТР ХХЭбТИһСЯМ база мәйданчыклары | ел эчендә | сәламәтлекләренең мөмкин-лекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче ата-аналарны өйрәтүгә тарту, кеше | 587 | 180 | - | 210,0* |
| 3.5. Халыкка социаль-психологик ярдәм күрсәтү буенча «Зеркало» республика үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреж-дениесе каршындагы Ведомство-ара супервизорлык хезмәтен төзү аша супервизорлык ярдәме күрсәтүнең өч дәрәҗәле систе-масын оештыру | ХСПЯК «Зеркало» РҮ ДАСХКУ | ел эчендә | белгечләрне өч дәрәҗәле супервизорлык ярдәме күр-сәтүгә тарту, Ведомствоара супервизорлык хезмәте супервизорларын әзерләү | 60 | 16 | - | - |
| 3.6. Республикада технологияне кертүдә катнашучы белгечләр өчен (тормышка ашырыла торган бөтен чор эчендә) сәламәтлек-ләренең мөмкинлекләре чик-ләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләрне яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору хезмәте сайтына мәгълүмати һәм техник ярдәм күрсәтү | ХСПЯК «Зеркало» РҮ ДАСХКУ | ел эчендә | сәламәтлекләренең мөмкин-лекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләрне һәм белгечләрне Үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тай-пылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору хезмәте сайты күрсәтә торган мәгълүмати хезмәтләр белән тәэмин итүгә тарту, кеше | 374 | 200 | 100,0 | - |
| 3.7. Үсешләрендә һәм сәла-мәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп итеп тору республика хезмәте | ХСПЯК «Зеркало» РҮ ДАСХКУ | ел эчендә | учреждениеләр – Ярдәмче программаны тормышка ашыруда катнашучыларның методик һәм фәнни әдәбият фонды күрсәтә торган хезмәтләрдән файдаланган | 60 | 100 | 100,0 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| белгечләре өчен методик, фәнни әдәбият һәм өйрәткеч видео-дәресләр фондын актуальләштерү | | | белгечләре саны, кеше | | | | |
| **4 нче бурычның исеме:** Үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору хезмәтен булдыру | | | | | | | |
| 4.1. Ярдәмче программаны социаль хезмәт күрсәтү һәм сәламәтлек саклау учреждениеләре эшчәнлегенә кертү буенча еллык республика оештыру семинарын үткәрү | ТР ХХЭбТИһСЯМ, ТР ССМ, ХСПЯК «Зеркало» РҮ ДАСХКУ | икенче ярты еллык | еллык республика оештыру семинарында катнашучылар саны, кеше | 27 | 16 | - | - |
| 4.2. Ярдәмче программаны тормышка ашыруны оештыру ягыннан тәэмин итү буенча проект семинарларын үткәрү | ТР ХХЭбТИһСЯМ, ТР ССМ, ХСПЯК «Зеркало» РҮ ДАСХКУ | икенче ярты еллык | сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтү белгечләрен проект семинарларында өйрәтүгә тарту, кеше | 40 | 25 | - | - |
| 4.3. Патронаж мәсьәләләрен хәл итү буенча яшьтән үк чара күрү һәм өйгә килеп ярдәм күрсәтү хезмәтләренең бергәләп ведомствоара киңәшмәләр үткәрүе | ТР ХХЭТИһСЯМ, ТР ССМ, ГАУСО РЦСППН «Зеркало» | квартал саен | квартал саен үткәрелә торган ведомствоара киңәшмәләр саны, тапкыр | 4 | 4 | - | - |
| 4.4. Яшьтән үк чара күрү, өйгә килеп ярдәм күрсәтү хезмәтләренең һәм башка ведомстволар белгечләренең тәэмин итеп торуына мохтаҗ булган сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларның ведомствоара мәгълүматлар банкын булдыру | ТР ХХЭбТИһСЯМ, ХСПЯК «Зеркало» РҮ ДАСХКУ | ел эчендә | сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар турындагы ведомствоара мәгълүматлар банкын булдыру, әйе (юк) | да | да | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.5. Муниципаль берәмлекләрдә җирле тернәкләндерү комитетлары эшен оештыру | ТР ХХЭТИhСЯМ, ГАУСО РЦСППН «Зеркало» | ел эчендә | муниципаль тернәкләндерү комитетларын төзү һәм аларның эшчәнлеге, әйе (юк) | да | да | - | - |
| 4.6. Супервизорлар һәм методистлар өчен оештыру һәм методик супервизияләр үткәрү | ХСПЯК «Зеркало» РҮ ДАСХКУ | ел эчендә | супервизорлар һәм методистлар өчен оештыру һәм методик супервизияләр саны, тапкыр | 616 | 25 | - | - |
| 4.7. Эксперименталь мәйданчыклар эшчәнлеге турында мәгълүматлар җыю, аларны кулланышка кертү нәтиҗәләрен күзәтеп тору, нәтиҗәлелеген мониторинглау һәм бәяләү, хисаплар (шул исәптән финанс хисапларын) әзерләү, алар белән идарә итү механизмнары һәм аларны норматив-хокукый тәэмин итү буенча тәкъдимнамәләр, белгечләрнең эш регламентын әзерләү | ХСПЯК «Зеркало» РҮ ДАСХКУ, ТР ССМ | ел эчендә | Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү һәм мониторингын алып бару, хисаплар әзерләү, әйе (юк) | да | да | - | - |
| **5 нче бурычның исеме:** Үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балаларны җәмгыятькә адаптацияләү һәм интеграцияләү программаларын тормышка ашыру | | | | | | | |
| 5.1. Территориаль социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре базасында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар, шул исәптән максатчан төркемдәге балалар өчен көндез була торган бүлекләр эшчәнлеген оештыру | ТР ХХЭбТИhСЯМ база мәйданчыклары | ел эчендә | | | | | - |
| 5.1.1. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән | ХСПЯК «Зеркало» РҮ | ел эчендә | белем бирү семинарларында социаль хезмәт күрсәтү | 62 | 100 | 100,0 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| эшләүдә инновацион социаль технологияләрдән файдалану буенча социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре белгечләре өчен өйрәтү семинары үткәрү | ДАСХКУ | | учреждениеләре белгечләрен өйрәтүгә тарту, кеше | | | | |
| 5.1.2. Үстерү һәм тернәкләндерү җиһазларыннан, лекотекадан файдаланып, социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре базасында, шул исәптән көндез була торган бүлекләрдә, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән дәресләр оештыру | ТР ХХЭбТИhСЯМ база мәйданчыклары | ел эчендә | сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларны һәм аларның ата-аналарын көндез була торган бүлекләрдә үткәрелүче дәресләргә тарту, кеше | 971 | 320 | - | 87,62* |
| 5.2. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче ата-аналарга ярдәм күрсәтү программаларын тормышка ашыру | ТР ХХЭбТИhСЯМ база мәйданчыклары | ел эчендә | сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче ата-аналарга булышлык күрсәтү программалары булу, әйе (юк) | да | да | - | - |
| 5.3. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче ата-аналарның үзара ярдәмләшү клублары эшчәнлеген оештыру | ХСПЯК «Зеркало» РҮ ДАСХКУ, ТР ХХЭбТИhСЯМ база мәйданчыклары | ел эчендә | сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче ата-аналарны ата-аналарның үзара ярдәмләшү клубларына тарту, кеше | 653 | 320 | - | - |
| 5.4. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә һөнәри консультацияләр бирүне оештыру | ТР ХХЭбТИhСЯМ база мәйданчыклары | ел эчендә | сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләрне һөнәри консультация хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итүгә тарту, гаиләләр саны | 164 | 25 | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **6 нчы бурычның исеме:** Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре каршында үсешендә һәм сәламәтлегендә тайпылышлар булган бала тәрбияләүче гаилә проблемаларын хәл итү буенча җәмгыять ресурсларын активлаштыру өчен ихтыярый затлар берләшмәләрен җәлеп итү | | | | | | | |
| 6.1. Сәламәтлекләренең мөмкин-лекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә анимация чараларын оештыру һәм үткәрү, сәламәтлекләренең мөмкинлек-ләре чикләнгән кешеләргә карата түземле һәм дустанә мөнәсәбәтләр булдыру тәҗрибәсен тиражлау өчен студентлар һәм мәктәп укучылары (80 кеше) арасыннан ихтыярый затларның 8 отряды эшен оештыру | ТР ХХЭбТИһСЯМ база мәйданчыклары | ел эчендә | сәламәтлекләренең мөмкин-лекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә ярдәм күрсәтү өчен ихтыярый затлар отрядларындагы волонтерлар саны, кеше | 141 | 80 | - | - |
| 6.2. Сәламәтлекләренең мөмкин-лекләре чикләнгән балаларны интеграцияләү һәм адаптацияләү программаларын тормышка ашы-руга волонтерлар җәлеп итү | ТР ХХЭбТИһСЯМ база мәйданчыклары | ел эчендә | сәламәтлекләренең мөмкин-лекләре чикләнгән балаларны интеграцияләү һәм адапта-цияләү программаларын тормышка ашыру буенча волонтерлар саны, кеше | 141 | 80 | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.3. Волонтерлар катнашында белем бирү оешмаларында, югары белем бирүче белем бирү оешмаларында, һөнәр белеме бирүче оешмаларда «Толерантлык дәресләре. Дусларыбыз – мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм сәламәтлекләре какшаган балалар» чарасын, шулай ук бу категория белән эшләүче белгечләрдә (табибларда, педагогларда, психологларда, социаль хезмәткәрләрдә) түземле һәм дустанә мөнәсәбәт формалаштыру буенча махсус дәресләр үткәрү | ТР ХХЭбТИһСЯМ база мәйданчыклары | ел әчендә | белем бирү оешмаларында, югары белем бирүче белем бирү оешмаларында, һөнәр белеме бирүче оешмаларда «Толерантлык дәресләре. Безнең дуслар – мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм сәламәтлекләре какшаган балалар» дигән темага үткәрелгән чаралар саны, тапкыр | 114 | 15 | - | - |
| Ярдәмче программа буенча БАРЛЫГЫ | | | | | | 12 803,075 | 1 654,537* |

* 2013 елда Тормыш хәле авыр булган балаларга ярдәм фондыннан алынган тотылмый калган акча.

**Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:**

ТР ХХЭбТИһСЯМ – Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;
ТР ССМ – Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы;
ХСПЯК «Зеркало» РҮ ДАСХКУ – халыкка социаль-психологик ярдәм күрсәтү буенча «Зеркало» республика үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе
«ТР ССМ БРКХ» ДАССУ – «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Казан шәһәре);
«8 нче БШХ» ДАССУ (Казан шәһәре) – «8 нче балалар шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Казан шәһәре);

«Кама балалар медицина үзәге» ДАССУ (Яр Чаллы шәһәре) – «Кама балалар медицина үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Яр Чаллы шәһәре);
«РБПШ» ДАССУ (Казан шәһәре) – «Республика балалар психоневрология шифаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Казан шәһәре);
«Чистай ҮРХ» ДАССУ – «Чистай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;
«9 нчы БШП» ДАССУ (Казан шәһәре) – «9 нчы балалар шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Казан шәһәре);
«2 нче БШП» ДАССУ (Яр Чаллы шәһәре) – «2 нче балалар шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Яр Чаллы шәһәре)»;
«Перинаталь үзәге булган БШХ» ДАССУ (Түбән Кама шәһәре) – «Перинаталь үзәге булган балалар шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (Түбән Кама шәһәре);
«РМСЙ» ДАССУ (Казан шәһәре) – «Республика махсуслаштырылган сабыйлар йорты» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;
«ТР ПА» КкП – «Татарстан Республикасы психологлары ассоциациясе» коммерциягә карамаган партнерлыгы;
ХСХККҮ – халыкка социаль хезмәт күрсәтүче комплекслы үзәкләр.

2015 – 2020 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту» ярдәмче программасы

Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | 2015 – 2020 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту» (алга таба – Ярдәмче программа)) |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысы | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе |
| Ярдәмче программаның максаты | Гаиләгә һәм гаилә тормышы кыйммәтләренә булышлык күрсәтү, аларны ныгыту һәм яклау, гаиләләрнең тормыш сыйфатын күтәрү |
| Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү чаралары системасын үстерү;<br>2. Табиблар рецептлары буенча өч яшькә кадәрге балаларны туклану өчен махсус продуктлар белән тәэмин итүне оештыру өчен шартлар тудыру;<br>3. Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру өчен уңай шартлар тудыру;<br>4. Гаилә тормыш рәвеше кыйммәтен һәм аның иҗтимагый абруен күтәрү, җаваплы ата һәм ана булуны пропагандалау;<br>5. Гаиләнең уңышсызлыгын, балаларның күзәтүчесез һәм караучысыз калуын профилактикалау |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2015 – 2020 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәм- | Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 39 946 703,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан |

<table>
<tr>
<td>че программаны финанслау күләмнәре</td>
<td>
Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 39 735 513,1 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 211 189,9 мең сум<br><br>
(мең сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Еллар</th><th rowspan="2">Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшыртуга акча күләме</th><th colspan="2">Шул исәптән</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>федераль бюджет акчасы</th></tr>
<tr><td>2015</td><td>5 989 802,6</td><td>5 949 257,1</td><td>40 545,5</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>6 258 785,8</td><td>6 214 827,3</td><td>43 958,5</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>6 510 005,4</td><td>6 480 229,9</td><td>29 775,5</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>6 789 935,5</td><td>6 758 879,7</td><td>31 055,8</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>7 068 322,9</td><td>7 035 993,7</td><td>32 329,2</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>7 329 850,8</td><td>7 296 325,4</td><td>33 525,4</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>39 946 703,0</td><td>39 735 513,1</td><td>211 189,9</td></tr>
</table>
<br>
Табиблар рецептлары буенча өч яшькә кадәрге балаларны түләүсез нигездә туклану өчен махсус сөт продуктлары белән тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативлары ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.<br>
Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш
</td>
</tr>
<tr>
<td>Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)</td>
<td>
Ярдәмче программаны тормышка ашыру 2020 ел ахырына түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>
түбәндәгеләрне тулы күләмдә бирүне тәэмин итүгә:<br>
хәрби хезмәткәрләрнең йөкле хатыннарына бер тапкыр бирелә торган пособиеләрне һәм хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр балаларына айлык пособиеләрне;<br>
балага айлык пособиене;<br>
авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә субсидия-ташламаларны;<br>
берьюлы туган өч яки аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә пособиеләрне;<br>
даими рәвештә кеше каравына мохтаҗ инвалид балаларга айлык акчалата түләүне;
</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсацияне;<br>дәүләт һөнәр белеме бирүче мәгариф оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга социаль түләүләрне;<br>«Ата-ана даны» ордены белән бүләкләнгән ана-аналарга (уллыкка (кызлыкка) алучыларга), «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән аналарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне;<br>ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруның барлык формаларында бер тапкыр бирелә торган пособиене;<br>опекага алынган балаларны карап торуга тәрбиягә бала алган гаиләгә бүләкләүне;<br>опекага алынган балаларны карап торуга тәрбиягә бала алган гаиләгә түләүне;<br>опекага алынган балаларны карап тотуга опекага алган гаиләләргә түләүне;<br>Татарстан Республикасында гаиләләрнең гомуми санында торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә торак субсидияләре алган гаиләләр өлешен 8,1 процентка кадәр киметүгә;<br>ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән затларны, таныклык биреп, 80 сәгатьлек программа буенча вәкаләтле оешмаларда өйрәтүгә;<br>гражданнар гаиләләрендә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өлешен 98,8 процентка кадәр арттыруга;<br>түләүсез нигездә махсус балалар туклануы продуктларын алган, җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган гаиләләрдән өч яшькә кадәрге балаларның чагыштырма авырлыгын 100 процент дәрәҗәсендә саклауга;<br>түләүсез нигездә табиблар рецептлары буенча махсус балалар туклануы продуктларын алган хроник авырулары булган өч яшькә кадәрге балаларның чагыштырма авырлыгын 100 процент дәрәҗәсендә саклауга;<br>балалар туклануын җитештерү өчен файдаланыла торган сөткә базар бәясе һәм теркәлгән бәяләр арасындагы |

| | |
|---|---|
| | аерманы тулы күләмдә каплауны 100 процент дәрәҗәсендә тәэмин итүгә;<br>Татарстан Республикасы балаларының гомуми санында күзәтүчесез балаларның чагыштырма авырлыгын 0,38 процентка кадәр киметүгә;<br>тернәкләндерү вакытларын арттырмыйча уңай нәтиҗәләр белән ведомствоара тәэмин итүдән алынган балалы гаиләләр өлешен 81,1 процентка кадәр арттыруга. |

## I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсе тасвирламасы. Ул хәл итәргә йөз тоткан проблемалар

Ярдәмче программа гаиләне Россия җәмгыятенең фундаменталь нигезе буларак ныгытуга һәм яклауга, җәмгыять тормышында гаиләнең ролен күтәрүгә, гаиләнең уңышсызлыгын профилактикалауга һәм җиңеп чыгуга, гаиләләрнең тормыш сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән.

2013 ел эчендә Татарстан Республикасында 33 580 пар никахларын имза белән беркетте, бу 2012 елга караганда 408 парга күбрәк (1,2 процент). 2013 елның тиешле чоры белән чагыштырганда 2014 елның 9 аенда республикада никахларны теркәү саны 3, 2 процентка киму күзәтелә.

2013 ел йомгаклары буенча никахларны бозуларны теркәү саны 1,5 процентка артты һәм 15 696 акт тәшкил итте. Бу соңгы өч елдагы гомуми тенденция, әмма агымдагы елда никах бозуларны теркәү саны 0,9 процентка киму билгеләп үтелә.

Татарстан Республикасында соңгы 7 ел эчендә теркәлә торган никахлар һәм никахларны бозулар саны чагыштырмасы яхшыра (2006 елда 1000 никахлашуга 545 никах бозулар, 2013 елда – 467 никах бозулар туры килгән иде). 2014 елның 9 аенда 1000 никахлашуга 433 никах бозу очрагы тәшкил итте.

2013 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында 57 214 туу турында акт теркәлгән. Туучыларны теркәүдә ирешелгән дәрәҗә 2012 ел дәрәҗәсеннән 2,2 процентка югарырак, ә 1999 ел белән чагыштырганда үсеш 62 процент тәшкил итте. Яңа туучыларның гомуми саныннан 29 408 малай (51,4 процент) һәм 27 806 кыз (48,6 процент) теркәлгән.

2014 елның 9 ае йомгаклары буенча республикада туу турында 43 149 акт теркәлгән, бу узган елның шундый чоры белән чагыштырганда 1 процентка күбрәк.

Туу турындагы актларны теркәү динамикасы




Гаиләдә икенче һәм аннан соңгы балалар туу гаиләнең социаль тормышы күрсәткече булып тора, бу җәмгыятькә һәм дәүләткә халык санының тотрыклылыгын һәм алга таба үсеш перспективаларын бирә.

2006 елдан башлап, дәүләт тарафыннан балалар туу күрсәткечен арттыруга юнәлдерелгән чаралар күрелә: яшь гаиләләргә булышлык күрсәтү буенча төрле программалар кертелә, икенче, өченче һәм аннан да күбрәк бала туган очракта ана (гаилә) капиталы программасы тормышка ашырыла.

2013 ел йомгаклары буенча республикада 26 424 бала (46 процент) – беренче бала булып, 22 842 бала (40 процент) – икенче бала булып, 6 308 бала (11 процент) – өченче бала булып, 1 640 (3 процент) дүртенче һәм аннан соңгы бала булып дөньяга килде.

Балаларның гомуми саныннан туулары 2014 елның 9 ае эчендә теркәлгән 19 299 бала (44,7 процент) – беренче бала, 17 512 (40,6 процент) – икенче бала, 4 996 (11,6 процент) – өченче бала, 1 342 (3,1 процент) дүртенче һәм аннан соңгы бала булып тора.

Соңгы елларда икенче һәм аннан соңгы балалар туу саны арту күзәтелүен дә билгеләп үтәргә кирәк.

| Чор | Туу турындагы барлыгы актлар | Балалар туу чираты | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 нче | 2 нче | 3 нче | 4 нче һәм аннан соңгы |
| 2009 ел | 47 143 | 53,6% | 35,4% | 8,5% | 2,5% |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2010 ел | 49 512 | 50% | 38% | 9,3% | 2,7% |
| 2011 ел | 51 391 | 48,7% | 39% | 9,7% | 2,6% |
| 2012 ел | 56 005 | 47% | 40% | 10% | 3% |
| 2013 ел | 57 214 | 46% | 40% | 11% | 3% |
| 2014 елнын 9 ае | 43 149 | 44,7% | 40,6% | 11,6% | 3,1% |

2013 елда туучыларның гомуми санында теркәлмәгән никахлардан туган балалар өлеше кимү күзәтелә. 2013 елда тулы булмаган гаиләләрдә туган балалар саны 10 496, яки яңа туучыларның гомуми санынннан - 18 процент, 2014 елның 9 аенда 7 443 бала, яки яңа туучыларның гомуми санынннан 17 процент тәшкил итте.

Татарстан Республикасында балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары федераль һәм республика законнары нигезендә күрсәтелә. «Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» Федераль закон нигезендә социаль яклау органнары тарафыннан вакытлыча эшкә яраксыз булу очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерелергә тиеш булмаган затларга түбәндәгеләр түләнә:

бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособие;

хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие;

хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәр баласына айлык пособие;

бала карау буенча айлык пособие.

2014 елның 1 сентябре хәленә карата эшләмәүче ата-ана 5 297 бала туганга бер тапкыр бирелә торган пособие алды, бер тапкыр бирелә торган пособие хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең 32 йөкле хатыннарына түләнде, эшләмәүче 19 848 зат бала карау буенча пособие ала, хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең 100 баласына айлык пособие түләнә.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон нигезендә түбәндәгеләргә ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация түләнә:

беренче балага – мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыручы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләве уртача күләменең 20 проценты күләмендә;

икенче балага – әлеге түләү күләменең 50 проценты күләмендә;

өченче балага һәм аннан соңгы балаларга – әлеге түләү күләменең 70 проценты күләмендә.

2014 елның 1 сентябре хәленә карата компенсация 108 117 балага түләнә.

2014 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр дәрәҗәсендә мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыручы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация билгеләнде. Өстәмә компенсация җан башына уртача керемнәре бер айга 20 мең сумнан артмаган гражданнарга бирелә. 2014 елның 1 сентябре хәленә карата өстәмә компенсация 52 334 балага билгеләнде.

18 яшькә кадәр балалары булган гражданнарга республика социаль ярдәм чаралары «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм чаралары турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә күрсәтелә. Аларга түбәндәгеләр керә:

республика сәламәтлек саклау учреждениеләрендә яшәү урыны буенча амбулатор исәптә торучы, җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган гаиләләрдән өч яшькә кадәрге балаларны һәм ясалма һәм катнаш тукланучы хроник авырулары булган балаларны түләүсез нигездә табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итү;

исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган өч яшькә кадәрге балаларны дару чаралары белән түләүсез тәэмин итү;

лагерьларда, шифаханәләрдә, шифаханә-профилакторийларда балаларны савыктыруга юлламалар бирү. 2014 елда тормыш хәле авыр булган 9 390 бала төрле типтагы савыктыру оешмаларына юллама алды;

гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәр белеме бирү оешмаларында белем алучыларны уку чорында бер укучыга көнгә 5,8 сум исәбеннән чыгып туклану белән тәэмин итү.

Татарстан Республикасында билгеләнгән җан башына уртача керемнәре яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган балалы гаиләләргә 16 яшькә кадәрге балага айлык пособие түләнә (гомуми белем бирү учреждениесендә укучыга – укып бетергәнче, әмма 18 яшькә җиткәннән соң түгел).

2014 елда балага айлык пособие алучы гаиләләрдә яшәүче мәктәп яшендәге балалар саны 35 520 бала тәшкил итте (2013 елда – 46 215 бала).

2014 елның 1 гыйнварыннан балага айлык пособие күләме – 249 сум; ялгыз ана баласына – 662 сум, хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр баласына һәм ата-аналары алимент түләүдән баш тарткан балага 374 сум тәшкил итә. 83 560 бала айлык пособие алучы булып тора.

18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган (тәрбиягә алганнарны да кертеп) гаиләләргә түбәндәгеләр өстәмә түләү бирелә:

6 яшькә кадәрге бала өчен дару чаралары сатып алуга 101 сум күләмендә субсидия (2014 елның 1 гыйнварыннан);

торак мәйданның Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән социаль нормасы чикләрендә торак өчен түләү чыгымнарының 30 проценты күләмендә субсидия;

халык өчен хезмәт күрсәтүләрдән файдалануның билгеләнгән нормативлары чикләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләү чыгымнарының 30 проценты күләмендә субсидия, ә үзәкләштереп җылытылмый торган йортларда яшәүче гаиләләр өчен халыкка сату өчен билгеләнгән нормалар чикләрендә сатып алына торган ягулык кыйммәтеннән;

гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга һәм һөнәр белеме бирү оешмалары студентларына, алар укып бетергәнче, әмма 18 яшькә җиткәннән соң түгел, транспортта йөрүгә 229 сум күләмендә айлык субсидия. Субсидия алучылар

шәһәр җәмәгать транспортының барлык төрләрендә һәм шәһәр яны элемтәсе автомобиль транспортында йөрү өчен бердәй айлык балалар социаль юл йөрү билетын алырга мөмкин.

2014 елның 1 сентябре хәленә карата 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләрдән 65 142 бала социаль ярдәмнең өстәмә чараларыннан файдаланучы булып тора.

Транспортта йөрүгә субсидия шулай ук белем бирү оешмаларында белем алучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга бирелә. 2014 елның 1 сентябре хәленә карата әлеге субсидияне алучылар булып 3 641 кеше тора.

Татарстан Республикасы Президентының «Берьюлы өч һәм аннан да күбрәк бала туу белән бәйле рәвештә балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» 2008 ел, 20 август, ПУ-397 нче Указы нигезендә түбәндәгеләр түләнә:

берьюлы өч һәм аннан да күбрәк бала туганда һәр балага 10 ар мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие;

берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә һәр балага яшь ярымга җиткәнгә кадәр 1000 әр сум күләмендә айлык пособие. Бер тапкыр бирелә торган пособие 6 балага түләнде, айлык пособие 12 балага түләнә.

Тормыш хәле авыр булган балалы һәм дәүләт тарафыннан социаль ярдәмгә мохтаҗ гаиләләргә социаль ярдәм чараларын күрсәтү системасының иң мөһим өлешләреннән берсе булып эзлекле рәвештә тормышка ашырыла торган халыкка дәүләт социаль ярдәме күрсәтү программасы тора.

Дәүләт социаль ярдәмен алучылар арасында күпчелек өлешне керемнәре дәрәҗәсе түбән булуга бәйле рәвештә үзләренең тормыш проблемаларын мөстәкыйль рәвештә хәл итәргә реаль мөмкинлекләре булмаган гражданнар тәшкил итә. Бу, беренче чиратта, инвалид балалы гаиләләр, тулы булмаган һәм күпбалалы гаиләләр.

2014 елда дәүләт социаль ярдәменә каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасының барлык күләме 56,495 млн. сум тәшкил итте.

Татарстан Республикасында үз составында эшкә яраклы эшләми торган гражданнар булган гаиләләргә дәүләт социаль ярдәмен социаль контракт нигезендә күрсәтү эше дәвам итә. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү технологиясен кертүнең максаты булып, адаптив мөмкинлекләрен активлаштыру юлы белән аз керемле гаиләләрнең тормыш сыйфатын күтәрү тора.

Акчалата түләүләрдән тыш, гражданнарга эшкә урнашуда, гражданлыкларын рәсмиләштерүдә, яшәү урыны буенча теркәлүдә, документларын рәсмиләштерүдә, дәвалануда һ.б. ярдәм күрсәтелә.

2014 елның 1 октябренә барлыгы 1 153 социаль контракт төзелде. 2014 елда 260 социаль контракт төзелде, алар буенча 50 кеше эшкә урнаштырылды, 66 кеше халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә исәпкә куелды, 2 кеше халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре аша һөнәр белеме алды, 28 кеше үз эшен оештырды, 11 кеше шәхси ярдәмче хуҗалык алып бара.

Өч яшькә кадәрге балаларны тулы кыйммәтле туклану белән тәэмин итү Россия Федерациясенең гражданнар сәламәтлеген саклау турындагы законнар нигезләре, «Гражданнар сәламәтлеген саклау турында» 1998 ел, 18 июнь, 1659 нчы; «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче; «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 ел, 16 март, ТРЗ-19 нчы Татарстан Республикасы законнары белән регламентланган.

Югарыда әйтеп кителгән Татарстан Республикасы законнарын Россия Федерациясе законнары нигезләренә туры китерү өчен «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 ел, 22 декабрь, ТРЗ-67 нче Татарстан Республикасы Законы кабул ителде.

Өч яшькә кадәрге балаларны тулы кыйммәтле туклану белән түләүсез тәэмин итү өчен балаларның ике категориясе сайлап алынды. Беренче категория – җан башына уртача кереме Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән яшәү минимумыннан артмаган гаиләләрдәге өч яшькә кадәрге балалар. Икенче категория – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетынын «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карары белән расланган исемлеккә кертелгән хроник авырулардан интегүче һәм дәвалау туклануына мохтаҗ балалар.

Югарыда әйтеп кителгән категорияләрдән табиблар рецептлары буенча махсус туклану белән ясалма һәм катнаш тукланучы, Татарстан Республикасында даими яшәүче, республика сәламәтлек саклау учреждениеләрендә яшәү урыны буенча амбулатор исәптә торучы балалар тәэмин ителә.

2014 елның 1 гыйнварына опека һәм попечительлек органнары исәбендә ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган 11 973 бала тора, шуларның 91,6 проценты республика гражданнары гаиләләрендә яши.

Гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар саны

| | 2010 ел, 1 гыйнвар | 2011 ел, 1 гыйнвар | 2012 ел, 1 гыйнвар | 2013 ел, 1 гыйнвар | 2014 ел, 1 гыйнвар |
|---|---|---|---|---|---|
| Гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар саны, шул исәптән: | 10 828 | 10 999 | 11 102 | 11 005 | 10 991 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| уллыкка (кызлыкка) алынган | 2 805 | 2 857 | 2 892 | 2 897 | 2 787 |
| опекага (попечительлеккә) алынган | 5 952 | 5 959 | 5 896 | 5 697 | 5 625 |
| тәрбиягә алган гаиләләрдә | 2 071 | 2 183 | 2 314 | 2 411 | 2 579 |

Республикабызда ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруда дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары, ведомствоара хезмәттәшлек итү, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм халык белән бергәләп эшләү нәтиҗәсендә республикада соңгы елларда ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны (алга таба – ятим балалар) гаиләгә урнаштыру буенча кайбер уңай тенденцияләр билгеләнде.

Республикада соңгы биш ел эчендә:

бер ел эчендә ачыклана торган ятим балалар саны 36 процентка кимеде;

ятим балалар өчен дәүләт учреждениеләре саны 14 процентка кимеде;

әлеге учреждениеләрдәге балалар саны 54 процентка кимеде.

Тормышларын җайга салуга мохтаҗ балалар саны кимеде (2009 елда – 1 363 кеше, 2010 елда – 1 344 кеше, 2011 елда – 1 218 кеше, 2012 елда – 1 116 кеше, 2013 елда 1 002 кеше мәгълүматларның төбәк банкында исәптә торды).

2013 елда 1 150 ятим бала гражданнар гаиләләренә бирелде, шулардан опекага (попечительлеккә) – 709 бала, тәрбиягә алган гаиләләргә – 264 бала, уллыкка (кызлыкка) – 177 бала, шул исәптән 34 инвалид бала. 2014 елның 9 аенда гражданнар гаиләләренә 830 ятим бала бирелде.

Татарстан Республикасында бүгенге көндә, түбәндәгеләрне кертеп, интернат учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәле системасын булдыру буенча уңай тәҗрибә бар:

уллыкка (кызлыкка) алучыларны һәм опекуннарны әзерләүне (2012 елның 1 сентябреннән 10 вәкаләтле оешма әзерлекне гамәлгә ашыра). 2014 елның 9 аенда вәкаләтле оешмаларда 517 гаилә әзерлек алды;

уку йортын тәмамлап чыгучыларны интернаттан соң тәэмин итү хезмәтләре эшен (2009 елдан 14 хезмәт эшләп тора);

тәрбиягә бала алган гаиләләрне тәэмин итү хезмәтләре (4 хезмәт) эшен.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен кайбер учреждениеләрне реструктурлаштыру турында» 2014 ел, 19 март, 170 нче карары нигезендә 2014 елның апрелендә ике балалар йортын бетерү процедурасы башлап җибәрелде. Алар базасында ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруда булышлык күрсәтү, алмаштыручы гаиләләрне әзерләү һәм тәэмин итү зона үзәкләре (алга таба – Үзәкләр) оештырыла. Үзәкләр эше Татарстан Республикасында гаиләләрнең уңышсызлыгын профилактикалау системасын үстерү буенча нәтиҗәле эшчәнлек тәэмин итәргә һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны тәрбиягә алучы гаиләләрне әзерләү һәм комплекслы тәэмин итү, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар учреждениеләрен

тәмамлап чыгучыларны һәм алар арасындагы затларны интернаттан соң тәэмин итү һәм аларны җәмгыятьтә социальләштерү өчен уңай шартлар тудыруда ярдәм итәчәк.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган, опекага (попечительлеккә), тәрбиягә алучы гаиләләргә бирелгән балаларга айлык акчалата түләү бирелә. Югарыда күрсәтелгән законның 3 статьясындагы 3 нче пункт нигезендә айлык акчалата түләү күләмнәре, инфляция дәрәҗәсен исәпкә алып, ел саен индексацияләнә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Айлык акчалата түләүләрне һәм түләүләрнең башка төрләрен индексацияләү турында» 2013 ел, 11 октябрь, 745 нче карары нигезендә 2014 елның 1 гыйнварыннан инвалид балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган, опекага (попечительлеккә), тәрбиягә алган гаиләләргә бирелгән балаларга айлык акчалата түләү күләмнәрен индексацияләү үткәрелде, ул түбәндәгеләрне тәшкил итте:

мәктәпкәчә яшьтәге балага – 6 777 сум;

мәктәп баласына – 7 817 сум.

Россия Федерациясе Президентының «Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру буенча кайбер чаралар турында» 2012 ел, 28 декабрь, 1688 нче Указын үтәү максатларында, «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясына үзгәреш кертү турында» 2013 ел, 13 июль, ТРЗ-60 нчы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде, аның нигезендә вазыйфаларын түләүсез башкаручы опекуннарга яки попечительләргә бирелергә тиешле бүләкләү 2013 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасында опекага алынган һәр зат өчен 3 мең сум күләмендә билгеләнә.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Гаилә кодексы белән вазыйфаларын түләүле шартларда башкаручы опекуннарга (попечительләргә) (шул исәптән тәрбиягә бала алган ата-аналарга) түбәндәге өстәмә түләүләр билгеләнгән:

педагогик яки медицина белеме булган тәрбиягә балалар алган ата-аналарга федераль закон белән билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең минималь күләменнән 50 процент күләмендә;

3 яшькә кадәрге тәрбиягә алынган баланы йә инвалид баланы яисә психик һәм физик үсешендә кимчелекләре булган баланы йә девиант тәртипле баланы тәрбияләгән өчен билгеләнгән акчалата бүләкләү күләменнән 30 процент күләмендә.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законы белән 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган (тәрбиягә алганнарын да кертеп) гаиләләргә түбәндәге социаль ярдәм чаралары билгеләнгән:

6 яшькә кадәрге бала өчен дару чаралары сатып алуга 101 сум күләмендә субсидия;

халык өчен хезмәт күрсәтүләрдән файдалануның билгеләнгән нормативлары чикләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләү чыгымнарының 30 проценты күләмендә, ә үзәкләштереп җылытылмый торган йортларда яшәүче

гаиләләргә халыкка сату өчен билгеләнгән нормалар чикләрендә сатып алына торган ягулык кыйммәтеннән субсидия;

торак мәйданының Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән социаль нормасы чикләрендә торакка түләү чыгымнарының 30 проценты күләмендә субсидия;

гомуми белем бирү учреждениеләрендә һәм башлангыч һәм урта һөнәр белеме бирү учреждениеләрендә укучыларга алар укуын тәмамлаганга кадәр, ләкин 18 яшькә җиткәннән соң түгел, транспортта йөрүгә 229 сум күләмендә айлык субсидия.

Суворов хәрби училищеларында (Казан, Алабуга, Екатеринбург, Кемерово, Оренбург шәһәрләре) белем алучы 108 ятим балага һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга опека (попечительлек) рәсмиләштерелгән. Ял көннәрендә һәм каникуллар вакытында суворовчыларны карауны гамәлгә ашыручы опекуннарга (попечительләргә) республикада 3 мең сум күләмендә айлык акчалата бүләкләү түләнә.

Төбәктә тулаем алганда ятим балаларны яшәү өчен гаиләләргә урнаштыруга карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру буенча бердәм мәгълүмат киңлеген булдыруга зур игътибар бирелә: законнар-нормативлар базасы булдырылды, 2002 елдан Уллыкка (кызлыкка) алу, опека һәм попечительлек республика үзәге эшләп тора, тәрбиягә бала алган гаиләләр клублары эшли, ятим балаларны тәрбияләүнең гаилә формаларын пропагандалау һәм ятим балаларны тәрбиягә алган гаиләләргә ярдәм итү буенча төрле чаралар үткәрелә.

Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары О.Ю.Голодец 2013 елның 7 ноябрендә йөкләгән ОГ-П8-266пр эшен үтәү максатларында ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруны тәэмин итү, алмаштыручы гаиләләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмалары структурасын үзгәртү һәм реформалаштыру максатларында, 2014 елда Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы 2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруны тәэмин итү чараларының республика планы эшләнде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 1 март, б-403 нче боерыгы белән расланды.

2014 елда түбәндәгеләр булдырылды:

бала алырга теләге булган һәм бала алган гражданнарга дүрт балалар йорты базасында опекага алынган затларны тәрбияләү һәм үстерү мәсьәләләре буенча ярдәм күрсәтүче зона консультатив төркемнәре (тәрбиягә алынган балаларны тәрбияләүче гаиләләргә һәм тәрбиягә бала алырга теләге булган гражданнарга консультатив ярдәм күрсәтү өчен һәм «Тәрбиягә бала алган ата-аналар форумы. Гаиләгә!» сайтында Татарстан Республикасының тәрбиягә бала алган ата-аналарының аралашуы өчен республика тармагы, «Формалашкан гаиләләр. Файдалы тәҗрибә. Татарстанда алмаштыручы гаиләне тәэмин итү хезмәте» рубрикасы булдырылды, алмаштыручы ата-аналарга гаилә тәрбиясе бирү проблемалары буенча Skype аша дистанцион консультация бирү оештырылды);

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы каршында «Татарстанның тәрбиягә бала алган ата-аналары ассоциациясе» иҗтимагый советы.

2014 елның июнендә Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы балаларның тәрбиягә алган гаиләләрдә яшәве уңайлы булу-булмауны мониторинглау буенча анализ ясады («Тәрбиягә бала алган гаилә. Тәрбиягә алынган бала» дигән анкета тутыру нәтиҗәләре буенча – 5). Нәтиҗәләре буенча анализ ясалган анкета тутыруда Татарстан Республикасының 45 муниципаль берәмлегеннән 2 425 тәрбиягә алынган бала (шулардан 2 341 е – балигъ булмаганнар (ягъни ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы 84 тәрбияләнүче тәрбиягә бала алган ата-аналар гаиләләрендә яшәвен дәвам итә) тәрбияләнә торган 1 296 тәрбиягә бала алган гаилә катнашты.

2014 елның беренче ярты еллыгында гаиләгә бала алырга теләк белдергән гражданнарны әзерләү кысаларында түбәндәге темаларга 5 зона семинары үткәрелде:

«Имгәнү алган балаларга психологик-педагогик ярдәм күрсәтү: эчтәлеге, формалары, тәҗрибә»;

«Гаиләдә тәрбиягә алынган бала. Тәрбияләү барышында барлыкка килгән мәсьәләләрне хәл итү юллары»;

«Балигъ булмаганнарга карата көчләүләрне (кыерсытуларны) профилактикалау. Балалар алырга теләге булган һәм алган гражданнарга опекага алынганнарны тәрбияләү һәм үстерү мәсьәләләре буенча ярдәм күрсәтү буенча консультатив төркемнәр оештыру («Фатыйма» хатын-кызлар кризис үзәге белән берлектә);

«Татарстан Республикасының тәрбиягә бала алган ата-аналар мәктәбе тәҗрибәсе. Гаиләләргә урнаштыру системасында тәрбиягә балалар алучы ата-аналар булырга кандидатлар белән эшләү үзенчәлекләре»;

«Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмалары базасында консультатив төркемнәр булдыру».

Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары эшчәнлеге гаилә уңышсызлыгын кисәтү, күзәтүчесез һәм караучысыз калуны профилактикалау, балигъ булмаганнарны адаптацияләү һәм тернәкләндерү, социаль ярдәм күрсәтүне адреслы итү максатларында, балалы гаиләләргә булышлык күрсәтү буенча закон актларын һәм максатчан программаларны үз вакытында һәм тулысынча тормышка ашыруга юнәлдерелгән.

Гаиләгә һәм балаларга социаль хезмәт күрсәтү системасы Татарстан Республикасында түбәндәге оешмалардан тора:

| Оешмалар исеме | Оешмалар саны | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел (2014 елның 1 октябре хәленә карата) |
| Балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют | 24 | 21 | 21 | 21 | 21 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәге | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар йорты-интернат | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәге | 13 | 13 | 13 | 13 | 13 |
| Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча территориаль үзәк | 4 | 4 | 3 | 3 | 3 |
| Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкнең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлеге | 48 | 48 | 42 | 42 | 42 |
| Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча «Гаилә» республика мәгълүмат-методик үзәге | - | - | 1 | 1 | 1 |

Балигъ булмаганнарны социаль яклау стратегиясенең мөһим элементы булып гаиләләргә һәм балаларга үз вакытында кирәкле социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәтләр күрсәтү учреждениеләре челтәрләрен алга таба үстерү һәм оптимальләштерү кала.

Гаиләгә һәм балаларга социаль хезмәт күрсәтү оешмалары балалар һәм ата-аналарның үзара мөнәсәбәтләрендә проблемалар булган, балаларын карап тору һәм тәрбияләү буенча үз вазыйфаларын тиешенчә үтәмәүче ата-аналар йә балалар үз-үзләрен асоциаль тота торган гаиләләр белән эшли. Оешмалар эшчәнлеге балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесез калуны профилактикалауга, тормыш хәле авыр булган гаиләләргә һәм балаларга социаль адаптация һәм тернәкләндерү үткәрүгә, кичектергесез социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән.

2013 ел йомгаклары буенча тормыш хәле авыр булган һәм гаиләгә һәм балаларга социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт учреждениеләрендә социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланган гражданнар саны 460 758 кеше, шул исәптән 228 427 балигъ булмаган бала (хезмәт күрсәтелгәннәрнең гомуми санынннан 50,4 процент) тәшкил итте. Барлыгы 136 966 балалы гаиләгә, шул исәптән 19 331 күпбалалы гаиләгә, 35 784 тулы булмаган гаиләгә, 67 716 аз тәэмин ителгән гаиләгә, 14 068 инвалид балалы гаиләгә, 10 качаклар һәм мәҗбүри күчеп килүчеләр гаиләсенә хезмәт күрсәтелгән.

| | 2009 ел | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Ресубликасында халык саны | 3 768 580 | 3 780 600 | 3 786 358 | 3 786 358 | 3 786 358 |
| Шулардан: | | | | | |
| Өлкәннәр | 2 978 330 | 3 059 093 | 3 062 407 | 3 062 407 | 3 062 407 |
| Балигъ булмаганнар | 790 250 | 721 507 | 723 951 | 723 951 | 723 951 |
| Гаиләгә һәм балаларга социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында хезмәт күрсәтелгәннәр саны (барлыгы) | 400 750 | 449735 | 484604 | 542 651 | 460 758 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Хатын-кызлар | 147 494 | 165 907 | 165 036 | 178 837 | 151 985 |
| Ир-атлар | 72 270 | 80 268 | 76 799 | 92 357 | 80 346 |
| Балигъ булмаганнар | 180 986 | 203 560 | 242 769 | 271 457 | 228 427 |
| Шул исәптән инвалид балалар | 13 898 | 18 616 | 16 022 | 15 606 | 14 887 |
| Балигъ булмаган балалары булган хезмәт күрсәтелгән гаиләләр саны | 99 192 | 108 947 | 124 706 | 156 163 | 136 966 |
| Шул исәптән: | | | | | |
| Күпбалалы гаиләләр | 13 694 | 16 218 | 18 485 | 22 344 | 19 331 |
| Инвалид балалы гаиләләр | 13 140 | 15 066 | 14 877 | 13 992 | 14 068 |
| Тулы булмаган | 23 160 | 26 038 | 34 034 | 36 061 | 35 784 |
| Аз тәэмин ителгән | 48 911 | 51 599 | 57 262 | 83 382 | 67 716 |
| Качаклар һәм мәҗбүри күчеп килүчеләр | 68 | 25 | 13 | 15 | 10 |

2013 елда гаиләгә һәм балаларга социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан 3 716 809 социаль хезмәт, 2012 елда – 3 865 784 хезмәт, 2011 елда – 5 534 814 хезмәт, 2010 елда – 4 057 944 хезмәт, 2009 елда 4 063 363 хезмәт күрсәтелде.

Татарстан Республикасында гаиләнең уңышсызлыгын алдан ачыкларга һәм аларга үз вакытында ярдәм күрсәтергә участок социаль эше мөмкинлек бирә. Муниципаль берәмлек территориясе гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәге яки бүлеге белгечләре арасыннан куратор беркетелә торган социаль участокларга бүленә. Беркетелгән территориядә кураторлар социаль мониторинг гамәлгә ашыра, социаль паспорт төзи, эчке эшләр органнары, сәламәтлек саклау, җирле үзидарә органнарының участок белгечләре белән берлектә, профилактика эшен оештыра.

Республиканың 45 муниципаль берәмлегендә 338 социаль участок эшләп тора. Һәр участокта консультатив пунктлар ачылды. Муниципаль берәмлекләрдә участок принцибы буенча «Гаилә консультанты» хезмәте эше алып барыла (консультатив пунктлар территориясе халыкка якын урнашкан җирдә була). Ата-аналарга үз вакытында булышлык күрсәтү, консультация бирү, «ата-аналар мәктәпләре», «яшь ана мәктәпләре», үз-үзенә ярдәм күрсәтү төркемнәре оештыру участок социаль хезмәтенең төп чаралар даирәсенә керә һәм балага һәм аның гаиләсенә якын урнашкан территориядә гамәлгә ашырыла.

Ата-аналарның психологик һәм юридик белемен, балалар тәрбияләү мәсьәләләрендә аларның педагогик белдеклелеген күтәрү максатыннан чыгып, гаиләләргә һәм балаларга социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә «Ата-аналар университеты» клубы эшли, аның кысаларында ата-аналар өчен балигъ булмаганнарга карата көч куллануны һәм рәхимсез мөнәсәбәтне профилактикалауга юнәлдерелгән дәресләр үткәрелә.

Кайбер районнарда составларына профилактика субъектлары белгечләре керә торган ведомствоара күчмә бригадалар төзелде. Бригадаларның барулары графиклар (атнага 1 тапкыр, айга 1 тапкыр, айга 2 тапкыр) һәм кичектергесез хәбәрләр буенча гамәлгә ашырыла. Мондый бригадаларның эш практикасы Татарстан Республикасының 18 муниципаль берәмлегендә (Әгерҗе, Азнакай, Әлки, Әлмәт, Апас, Балтач, Югары Ослан, Мамадыш, Менделеевск, Түбән Кама, Яңа Чишмә,

Питрәч, Балык Бистәсе, Сарман, Теләче, Чирмешән муниципаль районнары һәм «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округы) бар.

12 муниципаль берәмлектә (Актаныш, Алексеевск, Балтач, Бөгелмә, Чүпрәле, Алабуга, Зәй, Зеленодольск, Кукмара, Минзәлә, Мөслим, Чистай муниципаль районнары) максаты социаль хәле куркыныч булган һәм тормышта авыр хәлгә юлыккан гаиләләргә һәм балаларга кичектергесез һәм планлы ярдәм күрсәтү аша социаль ятимлекне профилактикалау булган мобиль бригадалар эше оештырылган. Мобиль бригадалар составына гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләре һәм бүлекләре белгечләре керә, кирәк булганда башка ведомстволар белгечләре җәлеп ителә.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау проблемасы аеруча актуаль булып тора, бу проблеманы хәл итүгә профилактикалау системасының барлык субъектлары кертелгән.

Җәмгыятьнең тормышта авыр хәлдә калган балаларга һәм яшүсмерләргә социаль ярдәм күрсәтү чараларын тәэмин итә торган иң мөһим социаль институтларның берсе булып килеп чыккан вәзгыятькә тиз җавап бирү механизмы ролен уйнарга тиеш булган балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләр тора.

Приютларның төп бурычы булып тормышта авыр хәлдә калган балигъ булмаганнарга учреждение уставы, законнар һәм нормативлар базасы: Россия Федерациясе Конституциясе; Бала хокуклары турында конвенция; «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесез калуын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 ел, 24 июль, ФЗ-120 нче; «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 ел, 24 июль, ФЗ-124 нче; «Ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 ел, 21 декабрь, ФЗ-159 нчы федераль законнар; «Балаларга социаль хезмәтләр күрсәтү» ГОСТ Р 52888; «Балаларга социаль хезмәт күрсәтү сыйфатын тикшерүдә тоту» ГОСТ Р 53061; «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 2008 ел, 13 октябрь, ТРЗ-105 нче Татарстан Республикасы Законы; еллык перспектив план, шулай ук кайбер республика максатчан программалары нигезендә гамәлгә ашырылучы кичектергесез социаль ярдәм күрсәтү тора

Тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләр балигъ булмаганнарның күзәтүчесез, караучысыз калуын профилактикалау субъектларының берсе булып тора. 2013 елның 1 октябренә Татарстан Республикасында 20 шундый учреждение эшләп тора, шуларның 18 е - 505 балигъ булмаган бала яши торган социаль приют, 2 се – социаль-тернәкләндерү үзәге.

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль үсеш министрлыгының «Социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләр эшчәнлеген оештыру буенча тәкъдимнамәләр раслау турында» 2002 ел, 29 март, 25 нче карары нигезендә учреждениеләр эшчәнлегенең төп юнәлешләре булып түбәндәгеләр тора:

тормышта авыр хәлдә калган балигъ булмаганнарны кабул итүне гамәлгә ашыру, аларга кичектергесез ярдәм күрсәтү, кирәк булганда табибка кадәр карау үткәрү һәм медицина тикшерүен оештыру;

социаль тернәкләндерүнең индивидуаль һәм төркем өчен күздә тотылган программаларын алга таба эшләү максатларыннан чыгып, социаль диагностикалау үткәрү, аларның тормышка ашырылуын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру, балигъ булмаганнарның хокукларын яклау һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү;

балигъ булмаганнарны социаль тернәкләндерү программаларын тормышка ашыруны тәэмин итү.

2013 елда балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләр тарафыннан 2 294 балигъ булмаган балага хезмәт күрсәтелде, бу 2012 ел белән чагыштырганда - 1,8 процентка (2 337), 2011 ел белән чагыштырганда - 14 процентка (2 680), 2010 ел белән чагыштырганда - 20 процентка (2 864) һәм 2009 ел белән чагыштырганда 15 процентка (2 718) кимрәк; 2014 елның 9 аенда 1 825 тәрбияләнүчегә хезмәт күрсәтелде.




**Балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтелгән балалар динамикасы (2009 ел – 2014 елның 9 ае)**

2014 елның 9 ае йомгаклары буенча республиканың махсуслаштырылган учреждениеләренә 1 282 балигъ булмаган зат керде.

Республиканың бу учреждениеләре балигъ булмаганнарның күзәтүчесез калуын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының барлык субъектлары белән үзара актив хезмәттәшлек итә.

2014 елның 9 маенда махсуслаштырылган учреждениеләргә балалар нигездә түбәндәгечә керде: халыкны социаль яклау органнары юлламасы буенча – 294 кеше, балигъ булмаганнарның ата-аналары яки законлы вәкилләре гаризасы буенча 229 кеше, опека һәм попечительлек органнары юлламасы буенча 201 кеше.

(балалар)

| Балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләргә балалар керү нигезләре | 2009 ел | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 елның 9 ае |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Халыкны социаль яклау органнары юлламасы буенча | 313 | 296 | 315 | 212 | 290 | 294 |
| Эшче эшләр органнары рапорты буенча | 560 | 573 | 566 | 402 | 470 | 189 |
| Белем бирү органнары үтенечнамәсе буенча | 27 | 83 | 30 | 26 | 23 | 8 |
| Сәламәтлек саклау органнары үтенеч-намәсе буенча | 7 | 2 | 5 | - | - | - |
| Опека һәм попечительлек органнары үтенечнамәсе буенча | 203 | 189 | 216 | 216 | 217 | 201 |
| Балигъ булмаганның шәхси мөрәҗәгате буенча | 102 | 140 | 125 | 98 | 132 | 105 |
| Балигъ булмаганнарның ата-аналары яки законлы вәкилләре гаризасы буенча | 220 | 326 | 235 | 248 | 110 | 229 |
| Башка сәбәпләр | 440 | 441 | 414 | 372 | 365 | 256 |

Балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләргә урнаштырылган балаларның төп контингентын түбәндәгеләр тәшкил итә:

(балалар)

| Балаларны балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләргә урнаштыру сәбәпләре | 2009 ел | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 елның 9 ае |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Ата-аналар яки аларның законлы вәкилләре кайгыртуыннан мәхрүм калган | 149 | 129 | 133 | 98 | 96 | 102 |
| Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдә яшәүче | 1 165 | 1 190 | 1 105 | 914 | 951 | 568 |
| Адашканнар яки ташлап калдырылганнар | 21 | 3 | 7 | 4 | 6 | 16 |
| Гаиләне рөхсәтсез ташлап китүчеләр | 43 | 61 | 56 | 29 | 76 | 35 |
| Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен белем бирү учреждениеләреннән рөхсәтсез китүчеләр | 5 | 7 | 3 | 1 | 1 | 1 |
| Яшәү урыны, тору урыны һәм (яки) яшәүгә акчасы булмаган | 57 | 52 | 68 | 48 | 36 | 10 |
| Көчләү корбаны булганнар | | 13 | 10 | 8 | 19 | 11 |
| Тормышта башка авыр хәлдә калганнар | 432 | 595 | 524 | 472 | 422 | 539 |
| **Барлыгы** | **1 872** | **2 050** | **1 906** | **1 574** | **1 607** | **1 282** |

Социаль тернәкләндерүнең төп бурычы – бала өчен гаиләне саклап калу. Соңгы 2 ел эчендә гаиләләрдән алынган һәм балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләргә урнаштырылган махсуслаштырылган учреждениеләрдә тәрбияләнүчеләрнең уртача 70 процентыннан артыгы гаиләләр

һәм балалар белән тернәкләндерү эше нәтиҗәсендә үзләренең тернәкләндерелгән туган гаиләләренә кайта.

2014 елның 9 ае эчендә тернәкләндерү чаралары барышында 801 балигъ булмаган зат үз гаиләсенә кире кайтарылды, 135 бала опекага бирелде, 58 бала ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен белем бирү учреждениеләренә җибәрелде, 98 бала тәрбиягә бала алучы гаиләләргә урнаштырылды, башкасы – 228.

2014 елның 9 ае эчендә киткән балигъ булманнарның 78,5 проценты тормышларын җайга салуның гаиләгә урнаштыру формасыннан китеп барды. 2013 елның 12 ае эчендә балигъ булмаганнарның 88,5 проценты тормышларын җайга салуның гаиләгә урнаштыру формасыннан китте, 2012 елның 12 аенда бу күрсәткеч - 90 процент, 2011 елның 12 аенда - 89 процент, 2010 елның 12 аенда 87 процент тәшкил итте.

балалар)

| Балаларны урнаштыру төрләре | 2009 ел | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 елның 9 ае |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Үзләренең туган гаиләләренә кире кайтарылган | 1 292 | 1 542 | 1 401 | 1 260 | 1 293 | 801 |
| Опекага (попечительлеккә) тапшырылган | 147 | 172 | 212 | 146 | 164 | 135 |
| Уллыкка (кызлыкка) тапшырылган | 2 | 3 | 3 | 1 | | 2 |
| Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен белем бирү учреждениеләренә җибәрелгән | 193 | 149 | 125 | 124 | 98 | 58 |
| Тәрбиягә алучы гаиләләргә җибәрелгән | 170 | 101 | 85 | 80 | 94 | 98 |
| Тормышларын җайга салуның башка формалары | 100 | 123 | 91 | 39 | 102 | 226 |
| Барлыгы | 1 904 | 2 090 | 1 917 | 1 650 | 1 751 | 1 320 |

Баланың иң беренче һәм мөһим хокукларыннан берсе – гаиләгә хокук. Нәкъ менә гаилә мохите балага шәхес буларак формалашырга һәм җәмгыятьтә яшәүгә әзер булырга мөмкинлек бирә. Шуңа күрә балачакны саклауның иң мөһим бурычы – бала өчен аның биологик гаиләсен саклап калу, аны тернәкләндерү, әгәр дә ул бала тәрбияләү өчен шартлар тудыра алмаслык хәлдә булса, гаиләне тергезү.

Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдә калган балигъ булмаганнарны һәм аларның гаиләләрен ачыклау буенча ведомствоара системаның нәтиҗәле эшләве өчен шартлар тудырылган. Мондый эш максатчан рәвештә алып барыла һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең һәм Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең нык игътибар үзәгендә тора.

Гаиләнең уңышсызлыгын иртә ачыклау гаиләне тергезү һәм бала хокукларын саклау өчен кирәкле чыгымнарны һәм белгечләр тырышлыгын минимальләштерергә, ата-аналарны нормаль яшәү рәвешенә кире кайтаруга

юнәлдерелгән чаралар комплексын үткәрү өчен кирәкле ата-ана хокукларын чикләү практикасын ешрак кулланырга булыша, ул ата-ана хокукларыннан мәхрүм итүләр санын киметергә һәм балаларга үзләренең биологик гаиләләрен саклап калырга ярдәм итәчәк.

Социаль хәле куркыныч булган балигъ булмаганнарны һәм аларның гаиләләрен ачыклау, аларны исәпкә алу һәм алар белән индивидуаль тернәкләндерү эшенең ведомствоара тәртибе Социаль хәле куркыныч булган балигъ булмаганнарга һәм аларның гаиләләренә социаль патронажлык итеп тору буенча ведомствоара муниципаль система турындагы нигезләмәгә (Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең 2007 елның 5 ноябрендәге 12-07 нче карары белән расланган), шулай ук Социаль хәле куркыныч булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турындагы бердәм мәгълүматлар банкын формалаштыру буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү турындагы нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 22 апрель, 294 нче карары белән расланды) таянып төзелде.

Әлеге система кысаларында норматив хокукый база, документлар әйләнешенең бердәйләштерелгән бердәм пакеты эшләнде.

Һәр муниципаль районда муниципаль районнарның башкарма комитетлары каршындагы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре карарлары белән ведомствоара системаның эшче органы – муниципаль социаль-тернәкләндерү консилиумы булдырылды һәм эшләп тора.

Әлеге консилиум составына профилактикалау субъектлары учреждениеләре (гаилә һәм балалар, мәгариф, сәламәтлек саклау социаль яклау учреждениеләре, опека һәм попечительлек бүлекләре, муниципаль районнарның башкарма комитетлары каршындагы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләренең җаваплы сәркатипләре, хокук саклау структуралары: балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләр, полициянең участок вәкаләтле вәкилләре, җәзалар үтәтү инспекциясе, яшьләр бүлеге) белгечләре керә. Консилиумны балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссия карары белән билгеләнгән һәм расланган рәис җитәкли.

Статистика мәгълүматларына караганда, 2014 елның 1 октябре хәленә карата Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә ведомствоара патронажлык итүдә 2 025 гаиләдән максатчан төркемгә керә торган 3 539 балигъ булмаган зат тора (барлыгы 3 825 балигъ булмаган бала).




**Ведомствоара патронажда торучы гаиләләр һәм балигъ булмаганнар саны (2009 ел – 2014 елның сентябре)**

Социаль хәле куркыныч булган гаиләләр (балалар) саны кимү тенденциясе күзәтелә. Әгәр 2009 елда ведомствоара патронажда торучы гаиләләр саны уртача 2 700 дән 2 900 га кадәр, балалар саны 5 300 дән 5 700 гә кадәр булса (тиешенчә, ел башына һәм азагына), 2014 елның 1 октябренә саннар 2 025 (гаилә), 3 539 (балигъ булмаганнарның максатчан төркеме) тәшкил итте һәм ведомствоара патронажда торучы балалар/гаиләләр саны кимү тенденциясе дәвам итә.




**Балаларны һәм гаиләләрне ведомствоара патронажга кую (2009 ел – 2014 елның сентябре)**

| Барлыгы ведомствоара исәпкә куелды | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2009 ел | | 2010 ел | | 2011 ел | | 2012 ел | | 2013 ел | | 2014 елның 9 ае | |
| гаиләләр | балалар | гаиләләр | балалар | гаиләләр | балалар | гаиләләр | балалар | гаиләләр | балалар | гаиләләр | балалар |
| 2 820 | 5 180 | 2 005 | 3 704 | 1 711 | 3 226 | 1 845 | 3 323 | 1 752 | 3 397 | 1 187 | 2 213 |

Социаль хәле куркыныч булган гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны ачыклау профилактикалау субъектлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2014 елның 9 ае эчендә 2 213 балигъ булмаган тәрбияләнә торганән 1 187 гаилә исәпкә куелды.

| Профилактикалау субъектлары | | 2009 ел | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 елның 9 ае |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| Опека һәм попечительлек органнары | балалар | 191 | 161 | 116 | 167 | 139 | 60 |
| | гаиләләр | 104 | 82 | 65 | 89 | 68 | 33 |
| Социаль яклау идарәсе органнары | балалар | 2 190 | 1 236 | 1 100 | 1 134 | 1 311 | 785 |
| | гаиләләр | 1 103 | 592 | 521 | 577 | 647 | 387 |
| Эшче эшләр органнары | балалар | 1 217 | 918 | 871 | 1 093 | 1 156 | 823 |
| | гаиләләр | 692 | 547 | 483 | 637 | 626 | 454 |
| Сәламәтлек саклау белән идарә итү органнары | балалар | 437 | 197 | 151 | 162 | 99 | 115 |
| | гаиләләр | 243 | 97 | 83 | 97 | 50 | 71 |
| Мәгариф белән идарә итү органнары | балалар | 408 | 225 | 224 | 274 | 212 | 124 |
| | гаиләләр | 241 | 130 | 129 | 156 | 125 | 69 |
| Яшьләр сәясәте белән идарә итү органнары | балалар | 54 | 24 | 4 | 10 | 7 | - |
| | гаиләләр | 33 | 17 | 4 | 3 | 2 | - |
| Территориаль иҗтимагый үзидарә советлары | балалар | 17 | 9 | 17 | 10 | 8 | 3 |
| | гаиләләр | 12 | 4 | 9 | 6 | 4 | 2 |
| Балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссияләр | балалар | 507 | 713 | 527 | - | | 50 |
| | гаиләләр | 302 | 404 | 284 | - | | 25 |
| Гражданнар инициативасы буенча | балалар | 118 | 0 | 4 | 70 | 83 | 9 |
| | гаиләләр | 67 | 0 | 4 | 44 | 39 | 6 |
| Үзмөрәҗәгать | балалар | 7 | 53 | 43 | 0 | | - |
| | гаиләләр | 4 | 31 | 23 | 0 | | - |
| Җәза-үтәтү инспекциясе | балалар | 34 | 77 | 74 | 144 | 121 | 111 |
| | гаиләләр | 19 | 52 | 59 | 105 | 72 | 77 |
| Авыл жирлеге башкарма комитеты | балалар | 0 | 82 | 95 | 109 | 117 | 33 |
| | гаиләләр | 0 | 43 | 47 | 51 | 56 | 13 |
| Һөнәр лицее администрациясе | балалар | 0 | 5 | 0 | 0 | | - |
| | гаиләләр | 0 | 3 | 0 | 0 | | - |
| Прокуратура | балалар | 0 | 4 | 0 | 0 | | - |
| | гаиләләр | 0 | 3 | 0 | 0 | | - |
| Ведомствоара рейдлар нәтиҗәсендә | балалар | - | - | - | 117 | 92 | 52 |
| | гаиләләр | - | - | - | 61 | 40 | 28 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Социаль хәле куркыныч булган гаилә көчеп килүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының башка муниципаль районының муниципаль социаль-тернәкләндерү консилиумнары | балалар | - | - | - | 33 | 44 | 48 |
| | гаиләләр | - | - | - | 19 | 20 | 22 |
| Россия Федерациясе Наркотиклар әйләнешен тикшерүдә тоту федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенең наркотикларның законсыз әйләнештә йөрүенә каршы көрәш бүлеге | балалар | | | | | 5 | - |
| | гаиләләр | | | | | 2 | - |
| Мәктәпкәчә белем бирү идарәсе | балалар | | | | | 3 | - |
| | гаиләләр | | | | | 1 | - |

Социаль уңышсызлык очраклары ачыклануның иң зур дәрәҗәсе – социаль яклау идарәсе органнарында (ведомствоара патронажга куелган гаиләләрнең гомуми саныннан 32,6 процент) һәм эчке эшләр органнарында (ведомствоара патронажга куелган гаиләләрнең гомуми саныннан 38,2 процент). Социаль уңышсызлык очракларын ачыклауда җәза-үтәтү инспекциясе, авыл җирлекләре башкарма комитетлары, территориаль иҗтимагый үзидарә советлары һәм яшьләр сәясәте белән идарә итү органнары катнашу өлеше түбән булып кала.

Республикада профилактикалауның барлык субъектлары тарафыннан балаларның һәм гаиләләрнең уңышсызлыгын иртә ачыклауны оештыру мәсьәләсе актуаль булып кала.




**Балаларны һәм гаиләләрне ведомствоара патронаждан төшерү динамикасы (2009 ел – 2014 елның сентябре)**

Гаиләне ведомствоара исәпкә куюда һәм аңа социаль патронаж оештыруда өстенлек итүче фактор булып алкогольле эчемлекләр куллануга бәйле рәвештә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) балаларны тәрбияләүдән, аларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклаудан баш тартуы тора. Мондый гаиләләр саны ведомствоара патронажда торучыларның гомуми санынннан 8,4 процент тәшкил итә (2014 елның 1 октябренә 2 652 балигъ булмаган бала тәрбияләнә торган 1 385 гаилә).

Оештырылган ведомствоара эш нәтиҗәсендә 2014 елның 9 аенда балигъ булмаган затлары яши торган уңай тернәкләндерү алган 78,9 процент гаилә патронаждан алынган. Болар - гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр җайга салынган, бала югалткан социаль элемтәләр һәм функцияләр торгызылган, балигъ булмаган зат җәмгыятьтә кабул ителгән нормаларга һәм кагыйдәләргә җайлашкан гаиләләр. Чагыштыру өчен: 2009 елда гаиләләрне уңай тернәкләндерү нәтиҗәсендә ведомствоара исәптән төшерү - 79 процент, 2010 елда – 75 процент, 2011 елда – 75,7 процент, 2012 елда – 81,7 процент, 2013 елда 80,8 процент тәшкил иткән иде.

Хатын-кызны ана буларак җәмәгатьчелек тарафыннан тануны һәм аңа олы ихтирам күрсәтүне тәэмин итү максатларында «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән биш һәм аннан да күбрәк бала тапкан һәм аларга тиешле тәрбия бирүче аналар бүләкләнә торган «Ана даны – Материнская слава» медале булдырылды. Медаль белән бүләкләнгән аналарга бер балага 5 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү түләнә. Гамәлгә куелган вакыттан башлап бүгенге көнгә кадәр медаль белән 1 279 хатын-кыз бүләкләнде.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында «Гаилә белеме» электив курсын кертү турындагы 2013 елның 22 апрелендәге 20491-МР йөкләмәсен һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетының «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 ел, 30 декабрь, ТРЗ-143 нче Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру барышы турында» 2014 ел, 27 май, 93 нче карарының 5 нче пунктын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан «Гаилә белеме» инновацион проектын кертү буенча эш алып барыла.

«Гаилә белеме» фәне буенча программа һәм «Гаилә белеме» электив курсы буенча уку-укыту-методик әсбабы Татарстан Республикасында фамилистика өлкәсендә әйдәп баручы белгечләр – югары һөнәр белеме бирү учреждениеләре укытучылары тарафыннан әзерләнде һәм югары һөнәр белеме бирүче «Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты» федераль дәүләт бюджет белем бирү учреждениесенең Гыйльми советы тарафыннан басмага тәкъдим ителде.

Әзерлек курсларын Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы финанслаганда 2013 елның апреленнән 2014 елның маена кадәр Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты базасында дүрт этапта «Россия гаиләсе» илкүләм иҗтимагый комитетының Татарстан бүлеге белгечләре белем бирү

оешмаларында «Гаилә белеме» проектын кертергә әзер булган 200 дән артык педагог, психолог, гомуми белем бирү оешмалары җитәкчесен әзерләде.

## II. Ярдәмче программаның төп максатлары, бурычлары һәм көтелә торган соңгы нәтиҗәләрне тасвирлау, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Хәзерге этапта дәүләт гаилә сәясәтенең өстенлекләре булып түбәндәгеләр тора:

хезмәт күрсәтүләрнең комплекслылыгы, аларның һәркем файдалана алырлык булуы;

хезмәтләр барлык мөрәҗәгать иткән гражданнарга аларның яшенә, диненә, социаль статусына, яшәү урынына карамастан һәм бары тик ирекле тәртиптә генә күрсәтелә;

консультацияләр клиентлардан алына торган шәхси тормыш турындагы мәгълүматның тулысынча конфеденциаль булуын саклауга нигезләнә;

белгечләрнең профессиональ дәрәҗәсе югары булу;

клиентларның теләге буенча мөрәҗәгать аноним булырга мөмкин;

кешелеклелек, изгелек, игътибар, индивидуаль якын килү.

Ярдәмче программаның максаты – гаиләгә һәм гаилә тормышы кыйммәтенә булышлык күрсәтү, аларны ныгыту һәм яклау, Татарстан Республикасы гаиләләренең тормыш сыйфатын күтәрү.

Ярдәмче программаның бурычлары:

гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү чаралары системасын үстерү;

табиб рецептлары буенча өч яшькә кадәрге балаларны махсус туклану өчен сөт продуктлары белән тәэмин итүне оештыру өчен шартлар тудыру;

ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру өчен унай шартлар тудыру;

гаилә тормыш рәвеше кыйммәтен һәм аның иҗтимагый абруен күтәрү, җаваплы ата һәм ана булуны пропагандалау;

гаиләләрнең уңышсызлыгын, балаларның күзәтүчесез һәм караучысыз калуын профилактикалау.

Максат, бурычлар һәм чаралар яктылыгында Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары турындагы мәгълүматлар Ярдәмче программага теркәлгән кушымтада китерелә.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары: 2015 – 2020 еллар.

## III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 39 946 703,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 39 735 513,1 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 211 189,9 мең сум.

(мең сум)

| Еллар | Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшыртуга акча күләме | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | федераль бюджет акчасы |
| 2015 | 5 989 802,6 | 5 949 257,1 | 40 545,5 |
| 2016 | 6 258 785,8 | 6 214 827,3 | 43 958,5 |
| 2017 | 6 510 005,4 | 6 480 229,9 | 29 775,5 |
| 2018 | 6 789 935,5 | 6 758 879,7 | 31 055,8 |
| 2019 | 7 068 322,9 | 7 035 993,7 | 32 329,2 |
| 2020 | 7 329 850,8 | 7 296 325,4 | 33 525,4 |
| Барлыгы | 39 946 703,0 | 39 735 513,1 | 211 189,9 |

Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

## IV. Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы

Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысы – Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы.

Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары булып Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе тора.

Дәүләт заказчылары һәм Ярдәмче программа чараларын үтәүчеләр түбәндәгеләрне башкара:

чараларны үтәү барышын тикшерүдә тотуны; үтәүчеләрнең бүлеп бирелә торган финанс чараларыннан рациональ файдалануын тикшерүдә тотуны;

Ярдәмче программа чаралары яктылыгында узган чор (квартал, ел) өчен Ярдәмче программаны үтәү турында хисаплар төзүне;

Ярдәмче программаны тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган финанс чараларын исәпкә алып, Ярдәмче программа чаралары буенча максатчан күрсәткечләрне һәм чыгымнарны, Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмын һәм аны үтәүчеләр составын ачыклауны.

Финанслау тәртибе, шулай ук Ярдәмче программада каралган чараларны тормышка ашыру механизмы федераль һәм республика законнары белән билгеләнгән.

Дәүләт заказчылары квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 енә кадәр, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Ярдәмче программаны тормышка ашыру, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә (алга таба – Тәртип) теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форманы тутырып, финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында статистика, белешмә һәм аналитик мәгълүмат кертә.

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 25 енә кадәр, Тәртиптә теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форманы тутырып, 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы составындагы Ярдәмче программаны тормышка ашыру һәм финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына җыелма статистика, белешмә һәм аналитик мәгълүмат кертә.

## V. Ярдәмче программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Гаиләне ныгыту һәм яклау юнәлешләре буенча үткәрелә торган чаралар, Татарстан Республикасының гамәлдәге дәүләт программалары белән күздә тотылган башка чаралар белән берлектә, төп бурычларның берничәсен – гаиләләрнең тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү; гаиләне ныгыту һәм яклау, гаиләнең җәмгыять тормышындагы ролен күтәрү, гаиләнең уңышсызлыгын профилактикалау һәм җиңеп чыгу мәсьәләләрен хәл итәргә ярдәм итәчәк.

2015 – 2020 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту» ярдәмче программасына кушымта

## 2015 – 2020 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту» ярдәмче программасы максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм аның чараларын финанслау

| Төп чаралар исеме | Үтәүчеләр | Төп чараларны үтәү вакытлары | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Еллар буенча индикаторларның мәгънәләре | | | | | | | Еллар буенча финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау, мең сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2014 ел (план) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
| Максатның исеме: Гаиләгә һәм гаилә тормышы кыйммәтләренә булышлык күрсәтү, аларны ныгыту һәм яклау, гаиләләрнең тормыш сыйфатын күтәрү | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 нче бурычның исеме: Гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү чаралары системасын үстерү | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие, шулай ук хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең балаларына айлык пособие бирү | ТР ХХЭбТИһСЯМ | 2015 – 2020 еллар | Хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең йөкле хатыннарына бер тапкыр бирелә торган пособиеләрне һәм хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итү--че хәрби хезмәткәрләрнең балаларына айлык пособиеләрне тулы күләмдә бирү. % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 18071,8 РФБ | 20458,2 РФБ | 21276,9 РФБ | 22191,8 РФБ | 23101,7 РФБ | 23956,5 РФБ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Күпбалалы гаиләләргә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә субсидия-ташламалар бирү | ТР ХХЭбТИhСЯМ | 2015 – 2020 еллар | Социаль яклау органнарына мөрәҗәгать иткән аз керемле граждан-нарның гомуми санында керем-нәре яшәү мини-мумы күләменә кадәр җиткән яки аларга социаль ярдәм итү чараларын күрсәтү хисабына аннан артып киткән гражданнар (шул исәптән күпбалалы гаиләләр) өлеше, % | 25,8 | 25,9 | 26,0 | 26,0 | 26,1 | 26,1 | 26,1 | 441317,6 ТРБ | 461176,9 ТРБ | 481007,6 ТРБ | 501690,9 ТРБ | 522260,2 ТРБ | 541583,8 ТРБ |
| Гражданнарга торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен субсидияләр бирү | ТР ХХЭбТИhСЯМ | 2015 – 2020 еллар | Татарстан Республикасында гаилә-ләрнең гомуми санында торак урын һәм ком-муналь хезмәтләр күрсәткән өчен тү-ләүгә торак субси-дияләре алган гаи-ләләр өлеше, % | 8,3 | 8,3 | 8,2 | 8,2 | 8,2 | 8,1 | 8,1 | 2540624,5 ТРБ | 2654952,6 ТРБ | 2769115,6 ТРБ | 2888187,6 ТРБ | 3006603,3 ТРБ | 3117847,6 ТРБ |
| Балага айлык пособие бирү | ТР ХХЭбТИhСЯМ | 2015 – 2020 еллар | Балага айлык посо-биене тулы күләм-дә бирү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 415309,9 ТРБ | 433998,8 ТРБ | 452660,8 ТРБ | 472125,2 ТРБ | 491482,3 ТРБ | 509667.1 ТРБ |
| Берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә пособиеләр бирү | ТР ХХЭбТИhСЯМ | 2015 – 2020 еллар | Берьюлы туган өч һәм аннан да күб-рәк бала тәрбия-ләүче гаиләләргә пособиеләрне тулы күләмдә бирү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 560,7 ТРБ | 585,9 ТРБ | 611,1 ТРБ | 637,4 ТРБ | 663,5 ТРБ | 688,0 ТРБ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация бирү | ТР ХХӘбТИһСЯМ | 2015 – 2020 еллар | Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 768752,8 ТРБ | 803346,7 ТРБ | 837890,6 ТРБ | 873919,9 ТРБ | 909750,6 ТРБ | 943411,4 ТРБ |
| Дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга социаль түләүләр бирү: дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлап чыкканда өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһазлар белән тәэмин итүгә бер тапкыр бирелә торган пособие; дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлап чыкканда бер тапкыр бирелә торган пособие; өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь сатып алуга еллык | ТР ХХӘбТИһСЯМ | 2015 – 2020 еллар | Дәүләт һөнәр белеме бирүче мәгариф оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга социаль түләүләрне тулы күләмдә бирү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 219322,6 ТРБ | 229192,2 ТРБ | 239047,5 ТРБ | 249326,5 ТРБ | 259548,9 ТРБ | 269152,2 ТРБ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| пособие; уку әдәбияты һәм язу кирәк-яраклары сатып алуга еллык пособие; туклануга айлык пособие; ятим балаларга һәм инвалид балаларга айлык стипендия; транспортта йөрүгә ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга айлык субсидияләр бирү | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2 нче бурычның исеме: Табиблар рецептлары буенча өч яшькә кадәрге балаларны туклану өчен махсус сөт продуктлары белән тәэмин итүне оештыру өчен шартлар тудыру | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган гаиләләрдән ясалма һәм катнаш туклануда булган өч яшькә кадәрге балаларны һәм хроник авырулары булган балаларны махсус балалар туклануы продуктлары белән түләүсез тәэмин итү | ТР ССМ | 2015 – 2020 еллар | Җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган гаиләләрдән түләүсез нигездә махсус балалар туклануы продуктлары алган өч яшькә кадәрге балаларның чагыштырма авырлыгы, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 412492,6 ТРБ | 429403,5 ТРБ | 446592,2 ТРБ | 465795,7 ТРБ | 484893,3 ТРБ | 502834,4 ТРБ |
| | ТР ССМ | 2015 – 2020 еллар | Түләүсез нигездә табиблар рецептлары буенча махсус балалар туклануы продуктларын | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | алган хроник авырулары булган өч яшькә кадәрге балаларның чагыштырма авырлыгы, % | | | | | | | | | | | | | |
| Балалар туклануын житештерү өчен сөт житештерүче авыл хуҗалыгы товар житештерүчеләренә алынып бетмәгән керемнәрен каплау | ТР АХҺАТМ | 2015 – 2020 еллар | Балалар туклануын житештерү өчен файдаланыла торган сөткә базар бәясе һәм теркәлгән бәяләр арасындагы аерманы каплау, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 120374,9 ТРБ | 125250,8 ТРБ | 130119,7 ТРБ | 135714,8 ТРБ | 141279,2 ТРБ | 146506,5 ТРБ |
| 3 нче бурычның исеме: Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру өчен уңай шартлар тудыру | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруның барлык формаларында бер тапкыр бирелә торган пособиене түләү | ТР МҺФМ | 2015 – 2020 еллар | Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруның барлык формаларында бер тапкыр бирелә торган пособиене тулы күләмдә бирү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 22473.7 РФБ | 23500.3 РФБ | 8498,6 РФБ | 8864,0 РФБ | 9227,5 РФБ | 9568.9 РФБ |
| Опекага алынган балаларны карап торуга тәрбиягә алган гаиләгә түләү (тәрбиягә алган ата-ананы бүләкләү) | ТР МҺФМ | 2015 – 2020 еллар | Опекага алынган балаларны карап торуга тәрбиягә бала алган гаиләгә бүләкләүне тулы күләмдә бирү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 158587,1 ТРБ | 165723,5 ТРБ | 172849,6 ТРБ | 180282,1 ТРБ | 187673,7 ТРБ | 194617.6 ТРБ |
| Опекага алынган балаларны карап торуга тәрбиягә алган гаиләгә түләүләр | ТР МҺФМ | 2015 – 2020 еллар | Опекага алынган балаларны карап торуга тәрбиягә бала алган гаиләгә | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 249537,6 ТРБ | 260766,8 ТРБ | 271979,8 ТРБ | 283674,9 ТРБ | 295305,6 ТРБ | 306231.9 ТРБ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | түләүне тулы күләмдә бирү, % | | | | | | | | | | | | | |
| Опекага алынган балаларны карап торуга опекага алган гаиләләргә түләүләр | ТР МһФМ | 2015 – 2020 еллар | Опекага алынган балаларны карап торуга опекуннар гаиләләренә түләүне тулы күләмдә бирү, берәмлек | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 568022,4 ТРБ | 593583,4 ТРБ | 619107,5 ТРБ | 645729,1 ТРБ | 672204,0 ТРБ | 697075.6 ТРБ |
| Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән затларны әзерләү | ТР МһФМ | 2015 – 2020 еллар | Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән затларны, таныклык биреп, 80 сәгатьлек программа буенча вәкаләтле оешмаларда өйрәтү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 6176,0 ТРБ | 6453,9 ТРБ | 6731,4 ТРБ | 7020,9 ТРБ | 7308,7 ТРБ | 7579,1 ТРБ |
| Опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру | ТР ФМ | 2015 – 2020 еллар | Гражданнар гаиләләрендә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өлеше, % | 98,7 | 98,8 | 98,8 | 98,8 | 98,8 | 98,8 | 98,8 | 44468,4 ТРБ | 46515,3 ТРБ | 48472,8 ТРБ | 50557,1 ТРБ | 52629,9 ТРБ | 54577,3 ТРБ |
| 4 нче бурычның исеме: Гаилә тормыш рәвеше кыйммәтен һәм иҗтимагый абруен күтәрү, җаваплы ата һәм ана булуны пропагандалау | | | | | | | | | | | | | | | | |
| «Ата-ана даны» ордены белән бүләкләнгән ана-аналарга (уллыкка (кызлыкка) алучыларга), «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән ана- | ТР ХХӘбТИһСЯМ | 2015 – 2020 еллар | «Ата-ана даны» ордены белән бүләкләнгән ана-аналарга (уллыкка (кызлыкка) алучыларга), «Ана даны – Материнская | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 3710,0 ТРБ | 3877,0 ТРБ | 4043,7 ТРБ | 4217,6 ТРБ | 4390,5 ТРБ | 4552,9 ТРБ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ларга бер тапкыр бирелә торган бүләкләү бирү | | | слава» медале белән бүләкләнгән аналарга бер тапкыр бирелә торган бүләкләүне тулы күләмдә бирү, % | | | | | | | | | | | | | |
| Никахларын дәүләт теркәвенә алу өчен гариза биргән гражданнарга яшь гаилә мәктәбе/клубы дәресләрен үткәрүү | ТР МК ГХАЯ идарәсе, ТР ГХАЯ органнары | 2015 – 2020 еллар | Никахларын дәүләт теркәвенә алу өчен гариза биргән гражданнарны, яшь гаилә мәктәбе/ клубы дәресләренә тарту, % | 15 | 17 | 20 | 23 | 25 | 27 | 30 | | | | | | |
| Гомуми белем бирү мәктәпләренең өлкән сыйныф укучылары өчен гомуми белем бирү мәктәпләрендә «Гаилә белеме» курсы буенча гаилә хокукы һәм гаилә мөнәсәбәтләре буенча дәресләр үткәрү | ТР МһФМ, ТР МК ГХАЯ идарәсе | 2015 – 2020 еллар | Гомуми белем бирү мәктәпләрендә «Гаилә белеме» курсы буенча дәресләр үткәрү | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | | | | | | |
| Татарстанның атказанган гаиләләренә ел саен «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медален тапшыру | ТР МК ГХАЯ идарәсе, ТР ГХАЯ органнары | 2015 – 2020 еллар | Татарстан Республикасы гаиләләренә «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медален тапшыру | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | | | | | | |
| Татарстан Республикасының иң яхшы гаиләләре хөрмәтенә Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов һәм аның хатыны Г.Ә.Миңнеханова исеменнән тан- | ТР МК ГХАЯ идарәсе, ТР ГХАЯ органнары | 2015 – 2020 еллар | Татарстан Республикасының иң яхшы гаиләләре хөрмәтенә Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов һәм аның хатыны Г.Ә.Миң- | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| танлы кабул итү мәҗлесе | | | исханова исемен-нән тантанлы кабул итү мәҗлесе үткәрү | | | | | | | | | | | | | |
| «Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне» бөтен-россия ир белән хатын мәхәббәте һәм гаилә бәхете көнен үткәрү чаралары | ТР МК ГХАЯ идарәсе, ТР ГХАЯ органнары | 2015 – 2020 еллар | «Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне» бөтенроссия ир белән хатын мәхәббәте һәм гаилә бәхете көнен оештыру һәм үткәрү | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | | | | | | |
| Халыкара гаилә көнен бәйрәм итү чаралары | ТР ХХӘбТИһСЯМ, ТР МК ГХАЯ идарәсе, шәһәр округлары, муниципаль районнар җирле үзидарә органнары | 2015 – 2020 еллар | Халыкара гаилә көнен оештыру һәм үткәрү | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | | | | | | |
| Яшь парларга һәм булачак ата-аналарга никахны тантаналы теркәү вакытында тапшыру өчен «Гаилә битләре» белешмә әсба-бын бастыру | ТР МК ГХАЯ идарәсе | 2015 – 2020 еллар | Никахны тантаналы теркәгән вакытта яшь парларга «Гаилә битләре» белешмә әсбабын тапшыру | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | | | | | | |
| 5 нче бурычның исеме: Гаиләләрнең уңышсызлыгын, балаларның күзәтүчесез һәм кайгыртучысыз калуын профилактикалау | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Халыкны тормыш хәле авыр булган гаиләгә һәм балаларга социаль хезмәт күрсәтүләрнең дәүләт тарафыннан гаран- | ТР ХХӘбТИһСЯМ | 2015 – 2020 еллар | Татарстан Республикасы балаларының гомуми санында күзәтүчесез балаларның ча- | 0,40 | 0,39 | 0,39 | 0,39 | 0,38 | 0,38 | 0,38 | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| тиялəнгəн исемлеге белəн массакүлəм мəгълүмат чаралары, учреждениелəрнең мəгълүмат стендлары, реклама полиграфия продукциясе аша таныштыру | | | гыштырма авырлыгы, % | | | | | | | | | | | | | |
| Тормыш хəле авыр булган гаилəлəр һəм балигъ булмаганнар белəн профилактика чараларын үткəргəндə дəүлəт структуралары һəм коммерция оешмалары, иҗтимагый һəм дини оешмалар арасында социаль партнерлык формаларын киңəйтү | ТР ХХЭбТИһСЯМ, ТР ССМ, ТР МһФМ, ТР ЯЭһСМ | 2015 – 2020 еллар | | | | | | | | | | | | | | |
| Территориаль принцип буенча оештырылган участок социаль ярдəм күрсəтү технологиясен тормышка ашыру | ТР ХХЭбТИһСЯМ | 2015 – 2020 еллар | | | | | | | | | | | | | | |
| Тормыш хəле авыр булган гаилəлəргə һəм балигъ булмаганнарга гаилəгə һəм балаларга социаль хезмəт күрсəтү оешмаларында хезмəтлəр күрсəтүгə мониторинг гамəлгə ашыру | ТР ХХЭбТИһСЯМ | 2015 – 2020 еллар | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Социаль хәле куркыныч булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре белән «Ведомствоара социаль патронажлык итү» индивидуаль тернәкләндерү эше технологиясен тормышка ашыру | ТР ХХЭбТИһСЯМ, ТР ССМ, ТР ЯЭһСМ, ТР МһФМ, ТР буенча ЭЭМ | 2015 – 2020 еллар | Тернәкләндерү вакытларын арттырмыйча уңай нәтиҗәләр белән ведомствоара тәэмин итүдән төшерелгән балалы гаиләләр өлеше | 80,8 | 80,9 | 80,9 | 81,0 | 81,0 | 81,1 | 81,1 | | | | | | |
| Эчке гаилә конфликты булган гаилә парларына социаль-психологик ярдәм күрсәтү | ТР ХХЭбТИһСЯМ, ТР МК ГХАЯ идарәсе | 2015 – 2020 еллар | | | | | | | | | | | | | | |
| Тормышта авыр хәлгә юлыккан гражданнарны (гаиләләрне) социаль тәэмин итеп тору буенча Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмалары эш тәҗрибәсен гомумиләштерү | ТР ХХЭбТИһСЯМ | 2015 – 2020 еллар | | | | | | | | | | | | | | |
| Халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмалары базасында социаль хезмәтләр клиентларына ярдәм күрсәтүгә, волонтерлар җәлеп итеп, ихтыярый затлар хәрәкәте отрядларын үстерү | ТР ХХЭбТИһСЯМ | 2015 – 2020 еллар | | | | | | | | | | | | | | |
| Программа буенча барлыгы, шул исәптән: | | | | | | | | | | | 5989802,6 | 6258785,8 | 6510005,4 | 6789935,5 | 7068322,9 | 7329850,8 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | | | | | | | | | | | 5949257,1 | 6214827,3 | 6480229,9 | 6758879,7 | 7035993,7 | 7296325,4 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| федераль бюджет | | | | | | | | | | | 40545,5 | 43958,5 | 29775,5 | 31055,8 | 32329,2 | 33525,4 |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

ТР ХХЭбТИhСЯМ – Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;
ТР ССМ – Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы;
ТР ФМ – Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы;
ТР буенча ЭЭМ – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы;
ТР МhФМ – Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы;
ТР АХhАТМ – Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы;
ТР ЯЭhСМ – Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы;
ТР МК ГХАЯ идарәсе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе;
ТР ГХАЯ органнары – Татарстан Республикасының гражданнар хәле актларын язу органнары;
РФБ – федераль бюджет;
ТРБ – Татарстан Республикасы бюджеты.

F:\KARAR\2015\231-6.doc

2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасы

Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | 2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысы | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары | Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы;<br>Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы;<br>Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы;<br>Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы;<br>Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы;<br>Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы;<br>Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы;<br>Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |
| Ярдәмче программаның төп эшләүчесе | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| Ярдәмче программаның максаты | Татарстан Республикасында инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәренең (мөстәкыйль күчеп йөргәндә хезмәт күрсәтүләрдән файдалануда, кирәкле мәгълүмат алуда авырлыклар кичерүче кешеләр) тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге өстенлекле объектларга тоткарлыксыз керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү |
| Ярдәмче программаның бурычлары | Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге өстенлекле объектларга тоткарлыксыз керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алу дәрәҗәсен күтәрү.<br>Татарстан Республикасында инвалидларны тернәкләндерү һәм социаль интеграцияләү системасын мәгълүмати-методик яктан һәм кадрлар белән тәэмин итү. |

<table>
<tr><td></td><td>Татарстан Республикасында инвалидлар проблемаларына һәм инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен тереклек эшчәнлегенең унай мохитен тәэмин итү проблемасына карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру һәм җәмгыятьтә социаль таркаулыкны бетерү</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары</td><td>2014 – 2015 еллар</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td><td>Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1 052 631,783 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 621 052,766 мең сум; федераль бюджет акчасы исәбеннән – 431 579,017 мең сум.<br>(мең сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Акчаның гомуми күләме</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>федераль бюджет акчасы</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>526 315,883</td><td>310 526,383</td><td>215 789,500</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>526 315,900</td><td>310 526,383</td><td>215 789,517</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>1 052 631,783</td><td>621 052,766</td><td>431 579,017</td></tr>
</table></td></tr>
<tr><td>Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)</td><td>Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2015 ел азагына түбәндәгеләрне арттыруга ярдәм итәчәк:<br>Татарстан Республикасында инвалидларның гомуми санында тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге өстенлекле объектларга тоткарлыксыз керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алу дәрәҗәсен уңай бәяли торган инвалидлар өлешен 55 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасында[1] өстенлекле объектларның гомуми санында социаль, транспорт, инженерлык инфраструктурасының инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре керә ала торган өстенлекле объектлары өлешен 45 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасында хәрәкәт итүче состав паркында халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәрен йөртү өчен җиһазландырылган автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортының хәрәкәт итүче составы паркы өлешен 11,7 процентка кадәр;<br>һөнәр белеме бирү оешмаларының гомуми санында инвалидларның һәм үсешләрендә тайпылышлар булмаган</td></tr>
</table>

[1]Тереклек эшчәнлегенең һәр өстенлекле өлкәсе буенча охшаш күрсәткечләр (индикаторлар) исәпләнергә мөмкин.

| | |
|---|---|
| | затларның бергә укуын тәэмин итәргә булыша торган универсаль киртәсез мохит булдырылган һөнәр белеме бирү оешмалары өлешен 15,4 процентка кадәр; системалы рәвештә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүче сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге инвалидларның бу категориягә керә торган халыкның гомуми санындагы өлешен 15,0 процентка кадәр; Татарстан Республикасында сораштырылган инвалидларның гомуми санында халыкның инвалидлар проблемасына карата мөнәсәбәтен унай бәяли торган инвалидлар өлешен 49,6 процентка кадәр; инвалидларны тернәкләндерү, социаль интеграцияләү мәсьәләләре буенча белем алган һәм квалификациясен күтәргән белгечләрнең бу өлкәдә эшләүче белгечләр гомуми санындагы өлешен 26 процентка кадәр |

## I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсе тасвирламасы, төп проблемалары һәм аларны хәл итү юллары

Татарстан Республикасы халкының социаль-демографик структурасы үзенчәлеге халыкның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәре чагыштырма авырлыгы югары булуда чагыла. Татарстан Республикасы халкы санында инвалидлар өлеше якынча 9 процент тәшкил итә, бу сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның тереклек итүе өчен махсус шартлар булдыру зарурлыгы белән бәйле.

2013 елның 1 гыйнвары хәленә карата Татарстан Республикасында 316,3 мең инвалид теркәлгән, шулардан 14,3 мең кеше – инвалид балалар.

Шуның белән бергә, Татарстан Республикасында 1 068,6 мең пенсионер (халыкның барлык саныннан якынча 28 процент) яши, ил буенча бу күрсәткеч уртача статистика дәрәҗәсеннән артык. Татарстан Республикасы халкы картаю процессы тизләшә бара. Халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәре категориясенә шулай ук хроник авырулар белән интегүче затлар, имгәнүләрдән соң тернәкләнү үтүче кешеләр, йөкле хатыннар һәм балалар коляскаларын тартып йөрүче кешеләр керә.

Бу төркемнәрнең барлык вәкилләре дә социаль хезмәт күрсәтүгә, медицина-социаль патронажга һәм озак вакыт дәвамында тәрбияләп торуга мохтаҗлык кичерә. Өлкән яшьтәге гражданнарның чагыштырма авырлыгы арту тәрбияләп тору хезмәтләре күрсәтүгә (түләүле хезмәт күрсәтүләр сегментын кертеп) сорау артуны билгели.

Шулай итеп, махсус җиһазландырылган объектларга, транспортка һәм хәрәкәт маршрутларына мохтаҗ булган кешеләр саны арта, бу социаль инфраструктураны һәркем файдалана алырлык итү проблемасын хәл итүне Татарстан Республикасы

дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен актуаль бурычлар рәтенә куя.

Шул ук вакытта инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен барлык социаль өлкәләрдә киртәсез мохит булдыру өчен шартлар тудыру Россия Федерациясенең бүгенге көнге дәүләт сәясәтенең төп векторларыннан берсе булып тора. 2006 елның 13 декабрендә Берләшкән Милләтләр Оешмасы Генераль Ассамблеясе кабул иткән Инвалидлар хокуклары турындагы конвенциягә 2008 елда Россия Федерациясе тарафыннан кул кую аның принципларын инвалидларга карата сәясәт тормышка ашырганда куллану өчен база принциплары итеп раслады. Моңа бәйле рәвештә, халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәре өчен киртәсез мохит формалаштыру бурычы халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең формалашкан системасын үстерү өстенлекләренә керә. Россия Федерациясе Президенты Д.А.Медведев тарафыннан «Инвалидлар хокуклары конвенциясен ратификацияләү турында» 2012 ел, 3 май, ФЗ-46 нчы Федераль законга кул куелды.

Шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан өстенлекле юнәлеш итеп нигездә мөмкинлекләре чикләнгән затлар депривациясен формалаштыра һәм аларга социумга тулысынча һәм нәтиҗәле рәвештә кушылып китәргә комачаулый торган «мөнәсәбәт» һәм мохит киртәләрен бетерү мәсьәләләрен беренче чиратта хәл итү зарурлыгы аерып күрсәтелә.

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 ел, 24 ноябрь, ФЗ-181 нче Федераль закон гамәлдә булган чорда Татарстан Республикасында мөмкинлекләре чикләнгән затларга социаль яклау чараларын күрсәтү системасы төгәл итеп төзелде һәм эшләнде.

1999 елдан 2010 елга кадәр инвалидлар проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән 7 республика программасы тормышка ашырылды, шул исәптән инвалидларның мәгълүматтан һәм социаль инфраструктура объектларыннан файдалана алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән 2 программа: 2003 – 2005 елларга инвалидларны тернәкләндерүнең республика комплекслы программасы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2003 – 2005 елларга инвалидларны тернәкләндерүнең республика комплекслы программасын раслау турында» 2003 ел, 18 апрель, 215 нче карары), 1999 – 2002 елларга инвалидларның мәгълүматтан һәм социаль инфраструктура объектларыннан файдалана алуын тәэмин итү чаралары исемлеге (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларның мәгълүматтан һәм социаль инфраструктура объектларыннан файдалана алуын тәэмин итү буенча чаралар исемлеге хакында» 1999 ел, 30 июнь, 406 нчы карары), дүрт «Татарстан балалары» программасы (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «1999 – 2001 елларга «Татарстан балалары» республика программасы турында» 1998 ел, 22 декабрь, 1907 нче карары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2002 – 2004 елларга «Татарстан балалары» республика программасы хакында» 2002 ел, 10 апрель, 195 нче; «2005 – 2007 елларга «Татарстан балалары» республика программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2005 ел, 29 декабрь, 671 нче; «2008 – 2010 елларга «Татарстан балалары» республика программасы хакында» 2007 ел, 24 декабрь, 743 нче карарлары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2010 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге перспективага Татарстан Республикасын демографик үстерү комплекслы

программасын раслау турында» 2009 ел, 12 гыйнвар, 6 нчы карары белән расланган 2010 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге перспективага Татарстан Республикасын демографик үстерү комплекслы программасы.

Инвалид балаларга һәм алар тәрбияләнә торган гаиләләргә тернәкләндерү хезмәтләрен күрсәтүгә яңа мөнәсәбәтләр булдыру максатларында, 2009 – 2011 елларда Тормыш хәле авыр булган балаларга ярдәм фондының финанс ярдәме белән республикада ике озак вакытлы республика максатчан программасы гамәлгә ашырылды. «Инвалид булып яшәү стиле сыйфатын яхшырту һәм аны профилактикалау максатларыннан чыгып, инвалид балаларны һәм аларның гаиләләрен яшәү урыны буенча социаль тормышка актив кертү программасы» кысаларында республиканың 18 муниципаль берәмлегендә инвалид балалар арасындагы аеруча авыр категориягә кертелгәннәргә өйдә социаль хезмәтләр күрсәтүнең яңа төре буларак «Өйгә килеп йөрү хезмәте» технологиясе сынап каралган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика социаль программаларын раслау турында» 2009 ел, 22 июнь, 412 нче карары), «2009 - 2011 елларда Татарстан Республикасында үсешләрендә кимчелекләр булган һәм мөмкинлекләре чикләнгән кече яшьтәге балаларны тәэмин итү буенча алдан чара күрү» программасы кысаларында балаларга этаплап медицина ярдәме күрсәтү шартларында, алдан чара күрү технологиясенә акцент ясап, үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган сабый балаларны тәэмин итү буенча яңа формалар кертелгән һәм мөнәсәбәтләр булдырылган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2009 - 2011 елларда Татарстан Республикасында үсешләрендә кимчелекләр булган һәм мөмкинлекләре чикләнгән сабый балаларны тәэмин итү буенча алдан чара күрү» озак вакытлы максатчан программасын раслау турында» 2009 ел, 22 июнь, 411 нче карары).

2012 елда әлеге юнәлешләр буенча эш шулай ук Тормыш хәле авыр булган балаларга ярдәм фондыннан финанс ярдәме алган «2012 - 2014 елларга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору системасын формалаштыру комплекслы программасы» республика программасы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2012 - 2014 елларга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итү системасын формалаштыру комплекслы программасы» озак вакытлы максатчан программасын раслау турында» 2012 ел, 16 ноябрь, 991 нче карары) кысаларында дәвам иттерелде.

Балаларның инвалид булуын һәм ата-аналарның инвалид балаларын тәрбияләүдән баш тартуын профилактикалау, үсешләре нык бозылган инвалид балаларның һәм аларның гаилә әгъзаларының социаль тормыштан чыгарылып ташлануын (изоляцияләнүен) профилактикалау һәм җиңеп чыгу максатларында Тормыш хәле авыр булган балаларга ярдәм фондының финанс ярдәме белән 2009 - 2011 елларда республикада инвалид булып яшәү стиле сыйфатын яхшырту һәм аны профилактикалау максатларында инвалид балаларны һәм аларның гаиләләрен яшәү урыны буенча социаль тормышка актив кертү программасын (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика социаль программаларын раслау турында» 2009 ел, 22 июнь, 412 нче карары белән расланган) һәм

«Үсешләрендә кимчелекләре булган һәм мөмкинлекләре чикләнгән кече яшьтәге балаларны тәэмин итеп тору буенча алдан медицина катнашуы» озак вакытлы максатчан программасын (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2009 - 2011 елларда Татарстан Республикасында үсешләрендә кимчелекләре булган һәм мөмкинлекләре чикләнгән кече яшьтәге балаларны тәэмин итеп тору буенча алдан медицина катнашуы» озак вакытлы максатчан программасын раслау турында» 2009 ел, 22 июнь, 411 нче карары белән расланган) тормышка ашыру тәмамланды. Инвалид баласы булган гаиләләр проблемаларын хәл итүгә инновацион ведомствоара якын килүне кертү буенча эш Үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору системасын формалаштыру комплекслы программасы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2012 - 2014 елларга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронажлык итеп тору системасын формалаштыру комплекслы программасы» озак вакытлы максатчан программасын раслау турында» 2012 ел, 16 ноябрь, 991 нче карары белән расланды) кысаларында дәвам иттерелде.

Соңгы 5 елда тернәкләндерү үткәрүнең төп шартларыннан берсе тәэмин ителде – дәүләт тернәкләндерү учреждениеләре челтәре төзелде, ул 2013 елның 1 гыйнвары хәленә карата хезмәт күрсәтүләреннән ел саен 15 меңнән артык кеше файдалана торган 20 тернәкләндерү үзәген (шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен 13 тернәкләндерү үзәген һәм 18 яшьтән өлкәнрәк инвалидлар өчен 7 тернәкләндерү үзәген) үз эченә ала. Республикада инвалид балаларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүгә дәүләт заказын дәүләткә карамаган учреждениегә урнаштыру тәҗрибәсе бар. Мәсәлән, 2009 елдан башлап, конкурс буенча сайлап алу йомгаклары буенча Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән тәрбияләнүчеләрне укыту өчен «Түбән Кама махсус (коррекцион) VI төр «Надежда» гомуми белем бирү интернат мәктәбе» муниципаль автоном махсус (коррекцион) белем бирү учреждениесе белән дәүләт контракты төзеде. Тернәкләндерү учреждениеләре эшчәнлеге «Инвалидларга, мөмкинлекләре чикләнгән затларга, социаль хәле куркыныч булган гаиләләргә һәм балаларга, тормышта авыр хәлгә юлыккан һәм социаль хезмәт күрсәтүнең стационар, ярымстационар һәм стационар булмаган формаларында тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүгә мохтаҗ булган башка гражданнарга һөнәри, социаль, психологик тернәкләндерү ярдәмен үз эченә алган тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты нигезендә оештырыла (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларга, мөмкинлекләре чикләнгән затларга, социаль хәле куркыныч булган гаиләләргә һәм балаларга, тормышта авыр хәлгә юлыккан һәм социаль хезмәт күрсәтүнең стационар, ярымстационар һәм стационар булмаган формаларында тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүгә мохтаҗ булган башка гражданнарга һөнәри, социаль, психологик тернәкләндерү ярдәмен үз эченә алган тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2012 ел, 21 ноябрь, 1016 нчы карары белән расланды).

2012 елда әлеге учреждениеләр күрсәтә торган хезмәтләрдән 8 592 инвалид һәм 6 689 инвалид бала файдаланды.

Инвалидлашуны профилактикалау һәм инвалидларны тернәкләндерү мәсьәләләре белән шөгыльләнә торган социаль тармакларның норматив, хокукый, кадрлар, оештыру, фәнни-мәгълүмати, материаль-техник һәм финанс потенциалы тупланды.

Татарстан Республикасында 5 ел эчендә медицина ярдәмен һәркем алырлык булу күрсәткечләре югары булып кала, авыл торак пунктларында сәламәтлек саклау дәрәҗәсе күтәрелде. Кардиохирургия, нейрохирургия, эндопротезлар ясау, онкология кебек махсуслаштырылган һәм югары технологияле юнәлешләр эзлекле рәвештә үсә. Соңгы 3 елда сәламәтлек саклау учреждениеләрен төзүгә, реконструкцияләүгә һәм капиталь ремонтлауга 9,3 млрд. сум акча бүлеп бирелде. 79 хастаханә, 53 амбулатория-поликлиника учреждениесе, 7 диспансер һәм 1 790 фельдшерлык-акушерлык пункты эшләп тора. Инвалидларга махсуслаштырылган медицина ярдәме Татарстан Республикасының һәр муниципаль районында эшли торган шәһәр (район) хастаханәләре тарафыннан күрсәтелә. Өйдә медицина карауларын үткәрү өчен 84 дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе оештырылган, табиб-белгечләрнең 142 комплекслы күчмә бригадасы төзелгән.

2013 елның 9 аенда амбулатория-поликлиника учреждениеләре, поликлиникалар каршындагы көндезге стационарлар һәм өйдәге стационар шартларында дәвалау 87 067 өлкән яшьтәге гражданга, Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәм инвалидларга үткәрелде, аларның 36 проценты (31 668 кеше) табибларның күчмә бригадалары тарафыннан каралды. Өлкәннәр арасындагы инвалидларны медицина ягыннан тернәкләндерүне Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Тергезү дәвалавы республика клиник хастаханәсе», Яр Чаллы шәһәренең «Сугышлар ветераннары госпитале» һәм Казан шәһәренең «Сугышлар ветераннары госпитале» (Тергезү медицинасы һәм тернәкләндерү үзәге) дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләре гамәлгә ашырды. Инвалид балаларны медицина ягыннан тернәкләндерү Инвалид балаларны тергезү дәвалавы үзәге базасында «8 нче Балалар шәһәр хастаханәсе», «Республика балалар психоневрология шифаханәсе» һәм «Республика сабыйлар йорты, махсуслаштырылган» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Республиканың дәүләт стационар учреждениеләрендә сугышлар инвалидлары һәм ветераннары өчен уңайлылыгы югары булган 911 койка-урынлы 420 махсуслаштырылган палата бүлеп бирелде. Инвалидларны тергезү дәвалавына һәм тернәкләндерүгә тарту күрсәткече Татарстан Республикасында – 10 проценттан 18 процентка кадәр, Россия Федерациясендә 20 проценттан 25 процентка кадәр тәшкил итә.

2013 елның 1 гыйнвары хәленә карата өлкәннәрне тулысынча тернәкләндерү күрсәткече 2010 ел белән чагыштырганда 14 процентка артты (2010 елда – 6,7 процент) һәм 7,8 процент тәшкил итте. Өлкәннәрне өлешчә тернәкләндерү күрсәткече шулай ук артты һәм 24 процент тәшкил итте (2010 елда – 18 процент). Өлкәннәрне суммар тернәкләндерү күрсәткече 2010 елның шундый ук күрсәткече белән чагыштырганда 16,2 процентка артты (2010 елда – 15,5 процент) һәм 18,5 процент

тәшкил итте. Инвалид балаларны тулысынча тернәкләндерү күрсәткече 31,5 процентка кимеде һәм 3,7 процент тәшкил итте (226 кеше), 2010 елда – 5,4 процент (347 кеше).

Югары технологияле ярдәмнән файдаланып операцияләр, шулай ук инсульт, баш сөяге, жилкә-баш мие имгәнүләрен һәм төрле генезлы хәрәкәт кытлыгы кичергән пациентларга Казан шәһәренең һәм Яр Чаллы шәһәренең сугышлар ветераннары өчен госпитальләре базасында 2010 елдан Тергезү медицинасы һәм тернәкләндерү үзәге составына керә торган тергезү дәвалавы һәм амбулатория шартларында тернәкләндерү бүлекләре эшли.

2011 елның 1 гыйнвары хәленә карата эшләп торучы белем бирү учреждениеләре инфраструктурасы утыргыч-коляскаларда йөрүче инвалид балаларга гомуми белем бирү мәктәпләре шартларында үз яшьтәшләре белән укырга мөмкинлек бирмәде.

Инвалид балаларның мәктәпкәчә тәрбия алуга хокукларын тормышка ашыру максатыннан чыгып, Татарстан Республикасында 2013 елдан 1 951 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе эшли, шулардан 17 учреждение компенсацияләү тибында, 23 учреждение – карап тору һәм савыктыру тибында, 419 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең үз структурасында компенсацияләү юнәлешендәге төркемнәр, 157 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – карап тору һәм савыктыру төркемнәре бар (компенсацияләү юнәлешендәге төркемнәргә 13 929 бала, савыктыру тибындагы төркемнәргә – 4 586 бала йөри); мәктәп яшендәге мөмкинлекләре чикләнгән балаларның 50,5 проценты гомуми белем бирү (массакүләм) мәктәпләрендә укый. Махсус программалар буенча белем алуга мохтаж балалар өчен Татарстан Республикасында 51 махсус (коррекцион) учреждение оештырылды, аларда укучы балаларның 47,3 проценты мәктәп яшендәге мөмкинлекләре чикләнгән балалалар (5 746 кеше). Белем бирү оешмаларына йөрү мөмкинлеге булмаган авыру балаларга һәм инвалид балаларга белемне өйдә алу гарантияләнгән. Белем алуның мондый формасына 2 016 бала тартылган. Соңгы елларда гомуми белем бирү мәктәпләрендә инвалид балаларга белем бирүнең дистанцион формасы актив үсә.

2011 елдан республикада инклюзив белем бирүне кертүгә игътибар бирелә. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 2011 елда 125 укытучы гомуми белем бирү оешмалары өчен «Тифлопедагогика», «Сурдопедагогика», «Олигофренопедагогика» белгечлекләре буенча яңадан һөнәри әзерлек алды. 2012 елда Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасындагы килешү нигезендә 35 гомуми белем бирү оешмасын адаптацияләү эшләре үткәрелде, алар биналарны (урыннарны) адаптацияләүне һәм аларны махсуслаштырылган җиһазлар белән җиһазландыруны һ.б. үз эченә ала. 2013 елда тагын 15 гомуми белем бирү оешмасын адаптацияләү эшләре үткәрелде.

Татарстан Республикасында ел саен балаларның һәм яшьләрнең җәйге ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне оештыру чаралары күрелә. Әмма инвалид (шул исәптән таяну-хәрәкәтләнү аппараты, күрү һәм ишетү сәләте бозылу сәбәпле тереклек эшчәнлеге шактый чикләнгән) балалар өчен җәйге ялны оештыру проблемалы булып кала.

2013 елның 1 ноябре хәленә карата Татарстан Республикасында 840 инвалид бала укый торган 98 һөнәр белеме бирүче оешма һәм 17 югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмасы (шулардан 3 се – республиканыкы) эшләп килә.

Инвалидларның һөнәри тернәкләндерүгә булган хокукларын тормышка ашыру максатларында халыкны эш белән тәэмин итүче 52 үзәк (филиал) тарафыннан эшсез инвалидларга һөнәри юнәлеш бирү хезмәтләре күрсәтелә, аларны һөнәргә өйрәтү (яңадан өйрәтү) оештырыла, эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтелә. Әмма мөрәҗәгать иткән инвалидларның гомуми саныннан бары тик өчтән бере генә эшкә урнаша. Мәсәлән, 2012 елда эш эзләп халыкны эш белән тәэмин итү органнарына мөрәҗәгать иткән 6 562 инвалидтан бары тик 2 571 кеше генә эшкә урнаша алды.

Татарстан Республикасында Спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше елы дип игълан ителгән 2009 елда спорт инфраструктурасын үстерү буенча актив эш алып барылды. Базасында 2009 елның октябрендә «Россия – спорт державасы» бөтенроссия форумы кысаларында Татарстан Республикасында беренче тапкыр коляскада йөрүче инвалидлар арасында баскетбол буенча Халыкара спорт кубогы үткәрелгән яңа «Олимп» мәдәният-спорт комплексы ачылды. Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы тарафыннан яшәү урыннарында инвалидлар белән эшләү өчен белгеч эшчәнлеге күздә тотылды. Казан шәһәрендә инвалидларның футбол һәм баскетбол командалары төзелде.

Хәзерге вакытта республикада өстенлекле спорт объектлары, шул исәптән Казан шәһәрендә 2013 елгы Бөтендөнья җәйге универсиаданы үткәрү чорында аеруча ихтыяҗ зур булган объектлар адаптацияләнде. Бу объектлар сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар файдалана алырлык булды. Әлеге затлар бу объектларга тамашачы буларак та, ярышларда катнашучы буларак та йөри ала.

Шуның белән бергә, инвалидларны тернәкләндерү һәм социаль интеграцияләү мәсьәләләре Татарстан Республикасында, тулаем Россиядәге кебек үк, элеккечә актуаль булып кала һәм алга таба жиренә җиткереп эшләп бетерүне, системалаштыруны һәм комплекслы хәл итүне таләп итә.

Әлеге проблеманы хәл итү механизмнарының берсе итеп Россия Федерациясе Хөкүмәте программа-максатчан методны сайлап алды һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 ел, 17 март, 175 нче карары белән 2011 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» дәүләт программасы расланды, ул Россия Федерациясенең 3 субъекты (Татарстан Республикасы, Тверь һәм Саратов өлкәләре) катнашында төбәкләрдә уңайлы мохит формалаштыруны жиренә җиткереп эшләп бетерү буенча 2011 – 2012 елларда сынау проектын тормышка ашыруны күздә тота.

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 ел, 24 ноябрь, ФЗ-181 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2011 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасы турында» 2011 ел, 17 март, 175 нче карары, шулай ук 2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында инвалид булуны профилактикалау һәм инвалидларны тернәкләндерү системасын үстерү концепциясе нигезендә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 31 декабрь, 1184 нче карары белән расланды) Татарстан Республикасы территориясендә инвалидларга карата дәүләт сәясәтен тормышка ашыруда Татарстан Республикасы катнашуын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 22 сентябрь, 786 нчы

карары белән расланган 2011 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» Татарстан Республикасы озак вакытлы максатчан программасы (алга таба – Программа) кабул ителде.

Программаны тормышка ашырган чорда һәр объектны кирәклек итү һәм барлык категорияле инвалидлар (таяну-хәрәкәтләнү аппараты, ишетү һәм күрү сәләте бозылган) өчен хезмәт күрсәтү чаралары күздә тотылды. Программага инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәре тереклек эшчәнлегенең барлык өстенлекле өлкәләре дә тартылды. Программаны төзү һәм өстенлекле объектлар исемлеген билгеләү, аларның кирәклегенә һәм аларга кешеләр йөрү-йөрмәүгә, инвалидлар мәнфәгатьләрен яклаучы иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итүгә карап гамәлгә ашырылды.

«Уңайлы мохит» программасын тормышка ашыру кысаларында 2011 елда республиканың 17 муниципаль берәмлегендә 83 объектны адаптацияләү чаралары үткәрелде.

Программада инвалидларның барлык категорияләренә дә игътибар бирелде һәм һәр объектта таяну-хәрәкәтләнү аппараты, ишетү һәм күрү сәләте бозылган инвалидлар өчен уңай мохит булдыру чаралары күздә тотылды.

Сәламәтлек саклау өлкәсендә объектларның иң күп саны – 24 объект адаптацияләнде. Алар арасында республиканың барлык халкын кабул итә торган әһәмиятле объектлар: республика клиник хастаханәләре, Республика клиник онкология диспансеры, ветераннар өчен госпитальләр, шулай ук республика шәһәрләрендә һәм районнарында берничә бинаны: поликлиниканы, хастаханәне, балалар бүлеген һ.б. үз эченә ала торган үзәк район хастаханәләре бар.

Социаль яклау өлкәсендә 25 объект адаптацияләнде. Алар арасында – зур шәһәрләрдәге социаль яклау бүлекләре, картлар һәм инвалидлар өчен интернатлар, тернәкләндерү үзәкләре, эш белән тәэмин итү үзәкләре, инвалид балалар укый торган һөнәри-техник училищелар.

Инвалидлар йөрү өчен (тамашачы буларак та, физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүче буларак та) 14 спорт корылмасы адаптацияләнде. Болар универсаль спорт комплекслары, йөзү бассейннары һәм балалар спорт мәктәпләре.

Мәдәният өлкәсендә 16 объект адаптацияләнде. Бу республика өчен шундый әһәмиятле объектлар: зур театрлар, концерт заллары, цирк, мәдәният сарайлары һәм кинотеатрлар.

Яңа технологик мөнәсәбәтләр кулланып, Казан метрополитенының барлык эшләп торучы станцияләрен адаптацияләү эшләре үткәрелде.

2011 һәм 2012 елларда республиканың зур шәһәрләрендә җәяүлеләрнең юл аркылы чыгу урыннары (җир өстендәге, җир астындагы һәм җир өстендәге) яңадан җиһазландырылды.

2011 елда биналарны барлык категорияле инвалидларның тоткарлыксыз керүе өчен адаптацияләү эшләренең барлык комплексын үткәрү нәтиҗәсендә иң оптималь чишелешләр үрнәге булган берничә объект билгеләнде. Мондый объектлар базасында эшче төркемнәрне, инвалидларның иҗтимагый оешмалары экспертларын, учреждениеләр, төзелеш оешмалары җитәкчеләрен уңайлылык элементларын булдыру һәм эксплуатацияләү буенча өйрәтү чаралары һәм киңәшмәләр үткәрелде.

Программаны тормышка ашыру кысаларында инвалидларның иҗтимагый оешмалары актив катнашында тәгаенләнгән һәм расланган объектларның уңайлылык паспорты эшләнде; муниципаль программалар эшләү буенча бердәм методик тәкъдимнамәләр әзерләнде; Программага кертү өчен өстенлекле объектлар исемлеге расланды; тротуарларны, шулай ук эре панельле торак йортларга һ.б. кирә торган урыннар төркемнәрен инвалидлар өчен уңайлылык элементлары белән җиһазландыруның бертип проект карарлары расланды һәм инвалидларның иҗтимагый оешмалары белән килештерелде.

2012 елда объектларны адаптацияләү республиканың барлык 45 муниципаль берәмлегендә үтте.

Барлык объектлар инвалидларның иҗтимагый оешмалары тәкъдимнәре буенча, инвалидларның йөрү күрсәткеченнән һәм аларның әһәмиятеннән чыгып, тереклек эшчәнлегенең төп өстенлекле өлкәләрендә сайлап алынды.

Сәламәтлек саклау өлкәсендә объектларның күп саны – 53 объект адаптацияләнде. Алар арасында – бөтен республика халкын кабул итә торган әһәмиятле объектлар: Республика ишетү сәләтен тернәкләндерү үзәге, Республика офтальмология хастаханәсе, Тергезү дәвалавы республика клиник хастаханәсе, Республика клиник психиатрия хастаханәсе, Республика наркология диспансеры, шулай ук республика шәһәрләрендәге һәм районнарындагы үзәк һәм район хастаханәләре.

Социаль яклау һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә 51 объект адаптацияләнгән. Шулар арасында – республика районнарындагы 17 социаль яклау бүлеге, 27 халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе (картлар һәм инвалидлар өчен интернатлар, тернәкләндерү үзәкләре, социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре), 7 халыкны эш белән тәэмин итү үзәге.

Шулай ук инвалид балалар белем ала торган 12 һөнәр белеме бирү оешмаларын адаптацияләү эшләре үткәрелде.

2012 елда республикада инклюзив белем бирүне кертүгә игътибар бирелде. 35 гомуми белем бирү оешмасын адаптацияләү эшләре үткәрелде.

Коляскада йөрүче инвалидлар яши торган торак фондны адаптацияләү буенча лифтлар белән җиһазландырылган күпфатирлы йортларның 1 нче катында һәм 1 нче катыннан югарырак зур күләмле эшләр башкарылды. Шулай ук күрү сәләте бозылган инвалидлар өчен йортлар адаптацияләнде.

Программаны тормышка ашыру кысаларында уңайлылык картасы программа продукты эшләнде һәм кертелде, аның мәгълүматлар банкына, аларның уңайлылык дәрәҗәсен бәяләп, көн саен объектлар кертелә. Карта, инвалидлар мәнфәгатьләрен яклый торган иҗтимагый оешмалар фикерен исәпкә алып, җиренә җиткереп эшләп бетерелә. 2013 елның 18 ноябренә уңайлылык паспортлары булдырылды һәм уңайлылык паспортына 1 199 объект буенча мәгълүмат кертелде. 2011 – 2012 елларда адаптацияләнгән объектларга уңайлылык паспортлары нигезендә инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә социаль инфраструктура һәм хезмәт күрсәтүләр реестры төзелде.

2011 – 2012 елларда Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Республика «Татмедиа» матбугат һәм

массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә, «Уңайлы мохит» программасы кысаларында «мөнәсәбәт» киртәләрен юкка чыгаруга юнәлдерелгән коммуникация кампаниясен оештырды.

Җәмгыятьтә мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә карата толерантлы мөнәсәбәт формалаштыру, инвалидның уңай образын булдыру максатларыннан чыгып, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән берлектә, ике телдә социаль реклама роликлары, фильмнар эшләде, тематик теле- һәм радиотапшырулар, иҗтимагый-агарту кампанияләре, социологик тикшеренүләр оештырды.

2011 – 2012 елларда Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңайлы мохит булдыруны регламентлый торган мәгълүмати-аналитик материаллар, методик тәкъдимнамәләр эшләде һәм бастырып чыгарды.

Ярдәмче программа тормышка ашырылган чорда түбәндәге проблемалар ачыкланды:

инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге өстенлекле объектларга керүгә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалануга карата таләпләрне үтәү өлешендә норматив-хокукый кырның балансланмаган булуы,

барлык этапларда – объектны проектлаудан эксплуатациягә керткәнгә кадәр инвалидлар өчен өстенлекле объектларны кереп булырлык итүгә карата таләпләр үтәлешен тикшерүдә тоту буенча көчле система булмау,

яңа биналарны проектлау һәм төзү өлешендә проектлаучыларның һәм төзүчеләрнең компетенция дәрәҗәсе җитәрлек дәрәҗәдә булмау, эксплуатациядәге эшләп торучы биналарны инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре ихтыяҗлары өчен адаптацияләү,

материаллар һәм җиһазлар базары камил булмау, уңай мохит булдыру өчен кирәк булган сыйфатлы материаллар һәм җиһазлар җитештерү дәрәҗәсе түбән булу,

учреждениеләр бюджетында уңайлылыкның кертелгән элементларын көн дә карап тотуга һәм эксплуатацияләүгә финанс чыгымнары каралмау һәм учреждениеләрнең штаттагы хезмәткәрләренең өстәмә бәрәмлекләре белән тәэмин ителмәү.

Барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан ел саен арта бара торган шактый зур финанслау күләмнәре белән тәэмин ителә торган чаралар күрелүгә дә карамастан, әһәмиятле социаль бурыч – физик, икътисадый һәм мәдәни әйләнә-тирәгә, сәламәтлек саклау һәм белем алу, мәгълүмат һәм элемтә өлкәләренә керә алуны тәэмин итү юлы белән инвалидлар өчен иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә тигез мөмкинлекләр тудыру әлегә хәл ителеп бетмәгән. Социологик сораштырулар мәгълүматлары буенча, инвалидлар проблемаларына игътибар арта баруга да карамастан, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән сораштырылган затларның 52 проценты уңай мохит формалаштыру буенча муниципаль хакимият куя торган тырышлыкларның нәтиҗәсен канәгатьләнмәслек дип бәяли.

Тернәкләндерү сәясәтенең күп кенә уңай моментлары булуга да карамастан, төбәктә инвалидлар керә ала торган тереклек эшчәнлеге өлкәләрендәге өстенлекле объектлар саны, шулай ук аларның мөмкинлекләре чикләнгән затлар тарафыннан файдаланылуы түбән булып кала.

Биналар һәм корылмалар, җәяүлеләр йөри торган юллар һәм тукталыш платформалары, җәмәгать транспорты Татарстан Республикасы гражданнарының бу категориясе тарафыннан файдалануга җайлаштырылмау аркасында аларның медицина, социаль, белем бирү, көнкүреш, рекреация хезмәтләре кебек күп кенә хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алуы, җәмгыять тормышында тулы хокуклы катнашуы кыенлаша яки алар бу хезмәт күрсәтүләрдән бөтенләй дә файдалана алмый.

Ярдәмче программа Татарстан Республикасында үткәрелә торган инвалидларны тернәкләндерү һәм җәмгыятькә интеграцияләү өчен шартлар тудыру буенча комплексы чараларның дәвамы булырга һәм инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектларыннан һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген, аларның тормыш сыйфатын һәм дәрәҗәсен күтәрүне тәэмин итәргә тиеш. Ярдәмче программа кысаларында тормышка ашырыла торган чаралар социаль һәм транспорт инфраструктурасының һәркем керә ала торган объектларын булдыруны тәэмин итәргә тиеш.

Ярдәмче программаны эшләү нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 ел, 24 ноябрь, ФЗ-181 нче Федераль закон;

2020 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең озак вакытлы социаль-икътисадый үсеш концепциясе (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 ел, 17 ноябрь, б-1662 нче боерыгы белән расланды);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2011 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасы чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2012 ел, 26 ноябрь, 1225 нче карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2011 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2012 ел, 26 ноябрь, б-2181 нче боерыгы;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Россия Федерациясе субъектының инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге өстенлекле объектлардан һәм өстенлекле хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алуны тәэмин итү буенча якынча программасын раслау турында» 2012 ел, 6 декабрь, 575 нче приказы;

«2011 - 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасын раслау турында» 2011 ел, 22 апрель, ТРЗ-13 нче Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы инвалидлар эшләре советын төзү турында» 2010 ел, 31 декабрь, ПУ-908 нче Указы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 21 декабрь, 1199 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында инвалид булуны профилактикалау һәм инвалидларны тернәкләндерү системасын үстерү концепциясен раслау турында» 2010 ел, 31 декабрь, 1184 нче карары.

Бу Ярдәмче программаны тормышка ашыру кысаларында әһәмиятле момент булып аны үтәү вакытында барлыкка килергә мөмкин булган һәм шуның белән аның нәтиҗәләренә тискәре йогынты ясый ала торган куркынычларны мөмкин кадәр киметү, ягъни:

бюджет кытлыгы барлыкка килү һәм аның аркасында бюджет финанславы дәрәҗәсе җитәрлек булмау белән бәйле финанс куркынычы;

финанс ресурсларыннан нәтиҗәсез файдалану куркынычы;

Ярдәмче программа белән нәтиҗәсез идарә итү куркынычы:

Ярдәмче программаны үтәү барышында нәтиҗәсез идарәчел карарлар кабул итү куркынычы;

Ярдәмче программаны тормышка ашырганда кирәкле яраштыру булмау куркынычы;

Ярдәмче программа көтелә торган соңгы нәтиҗәләрне бирмәү куркынычы.

Килеп чыгарга мөмкин булган куркынычлар сала ала торган тискәре зыяннарны бетерү/мөмкин кадәр киметү юллары:

Ярдәмче программаны, Татарстан Республикасы бюджеты акчасын, муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчасын һәм бюджеттан тыш чыганакларны җәлеп итеп, федераль бюджет акчасы исәбеннән финанслау варианты;

Ярдәмче программаны тормышка ашыру кысаларында төбәкләргә карата куела торган техник бирем таләпләре нигезендә объектларны адаптацияләү проектларын килештерүне тикшерүдә тоту. Төбәкләргә карата куела торган таләпләрнең үтәлешен тикшерүдә тоту буенча эшче төркемнәр төзү;

инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәре тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә төбәкләрнең өстенлекле объектларын билгеләүгә һәм аларның санын билгеләүгә карата бердәм мөнәсәбәт булдыру.

## II. Ярдәмче программаның максаты, бурычлары, көтелә торган соңгы нәтиҗәләре тасвирнамәсе, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Ярдәмче программаның максаты - Татарстан Республикасында инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәренең (мөстәкыйль күчеп йөргәндә хезмәт күрсәтүләрдән файдалануда, кирәкле мәгълүмат алуда авырлыклар кичерүче кешеләр) тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге өстенлекле объектларга тоткарлыксыз керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү.

Ярдәмче программаның бурычлары:

Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге өстенлекле объектларга керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу дәрәҗәсен күтәрү;

Татарстан Республикасында инвалидларны тернәкләндерү һәм социаль интеграцияләү системасын мәгълүмати-методик яктан һәм кадрлар белән тәэмин итү.

Татарстан Республикасында инвалидлар проблемаларына һәм инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен тереклек эшчәнлегенең уңай мохитен тәэмин итү проблемасына карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру һәм җәмгыятьтә социаль таркаулыкны бетерү.

Ярдәмче программаны тормышка ашыруны тасвирлаучы төп күрсәткечләр булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасында инвалидларның гомуми санында тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге өстенлекле объектларга керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу дәрәҗәсен уңай бәяли торган инвалидлар өлеше;

Татарстан Республикасында өстенлекле объектларның гомуми санында социаль, транспорт, инженерлык инфраструктурасының инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре керә ала торган өстенлекле объектлары өлеше;

Татарстан Республикасында хәрәкәт итүче состав паркында халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәрен йөртү өчен җиһазландырылган автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортының хәрәкәт итүче составы паркы өлеше;

һөнәр белеме бирү оешмаларының гомуми санында инвалидларның һәм үсешләрендә тайпылышлар булмаган затларның бергә укуын тәэмин итәргә булыша торган универсаль киртәсез мохит булдырылган һөнәр белеме бирү оешмалары өлеше;

системалы рәвештә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүче сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге инвалидларның бу категориягә керә торган халыкның гомуми санындагы өлеше;

сораштырылган инвалидларның гомуми санында халыкның инвалидлар проблемасына карата мөнәсәбәтен уңай бәяли торган инвалидлар өлеше;

инвалидларны тернәкләндерү, социаль интеграцияләү мәсьәләләре буенча белем алган һәм квалификациясен күтәргән белгечләрнең бу өлкәдә эшләүче белгечләрнең гомуми санындагы өлеше.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләренә керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән түбәндәге чаралар күздә тотылды:

җәмгыятьтә социаль таркаулыкны җиңеп чыгу һәм инвалидлар проблемаларына һәм республикада инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен тереклек эшчәнлегенең уңайлы мохитен тәэмин итү проблемасына карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру;

Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңайлы мохитне тотрыклы алга таба үстерү өчен шартлар тудыру;

Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге өстенлекле объектларга керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу өчен шартлар тудырганда дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшләрен яраштыруны һәм ведомствоара хезмәттәшлек итүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге социаль инфраструктура объектларына керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу турындагы мәгълүматны аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру максатыннан чыгып җыю һәм системалаштыру;

пассажирлар, шул исәптән җир өсте электр, транспортының төп төрләренә керә торган хәрәкәт итүче составтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү, инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен елга транспортына, метрога керә алу өчен шартлар тудыру.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты: 2014 – 2015 еллар.

Ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләрне җентекләп тасвирлау бу Ярдәмче программага теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.

Ярдәмче программа чаралары исемлеге бу Ярдәмче программага теркәлгән 2 нче кушымтада китерелә.

Ярдәмче программаның 2014 елда Россия Федерациясе бюджетыннан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган объектлары һәм чаралары исемлеге бу Ярдәмче программага теркәлгән 3 нче кушымтада китерелә.

Ярдәмче программаның максатчан күрсәткечләре (индикаторлары) системасы бу Ярдәмче программага теркәлгән 4 нче кушымтада китерелә.

## III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1 052 631,783 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 621 052,766 мең сум; федераль бюджет акчасы исәбеннән – 431 579,017 мең сум.

(мең сум)

| Ел | Акчаның гомуми күләме | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | федераль бюджет акчасы |
|---|---|---|---|
| 2014 | 526 315,883 | 310 526,383 | 215 789,500 |
| 2015 | 526 315,900 | 310 526,383 | 215 789,517 |
| Барлыгы | 1 052 631,783 | 621 052,766 | 431 579,017 |

Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителеше күләме бу Ярдәмче программага теркәлгән 5 нче кушымтада китерелә.

Ярдәмче программаның тереклек эшчәнлеге өлкәләре буенча ресурслар белән тәэмин ителеше күләме бу Ярдәмче программага теркәлгән 6 нчы кушымтада китерелә.

## IV. Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы

Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы планлаштыруны һәм фаразлауны, Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыруны, Ярдәмче программаны үтәү барышын мониторинглауны һәм тикшерүне, Ярдәмче программа чараларын ачыклауны һәм коррекцияләүне, финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын, максатчан индикаторларны үз эченә ала.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру, гамәлдәге законнарга таянып, дәүләт ихтыяҗлары өчен продукция сатып алу һәм кайтарту турында Ярдәмче программа чараларын үтәүчеләр белән төзелә торган дәүләт шартнамәләре (килешүләре) нигезендә башкарыла.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру өчен кирәкле идарәчел карарларны, норматив хокук актларын, Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысыннан кирә торган мәгълүматны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кабул итә.

Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысы булып Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тора.

Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы;

Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы;

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы;

Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы;

Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы;

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы;

Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы;

Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт ведомстводан тыш экспертиза идарәсе;

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы.

Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысы аны тормышка ашыру барышында:

Ярдәмче программага җитәкчелек итүне һәм аны тормышка ашыру белән агымдагы идарә итүне гамәлгә ашыра;

Ярдәмче программаны тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, инвалидларның иҗтимагый оешмалары эшчәнлеген яраштыра;

үз компетенциясе чикләрендә Ярдәмче программаны тормышка ашыру өчен кирәкле норматив хокук актлары проектларын эшли;

Ярдәмче программаның нәтиҗәлелеге буенча максатчан күрсәткечләрнең мәгънәләренә ирешүне тәэмин итә;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 еннән дә соңга калмыйча, Ярдәмче программа чараларын үтәү хакында, сан-сыйфат күрсәткечләрен һәм чараларның үтәлүен яки үтәлмәвен тасвирлауны үз эченә алган чараларны үтәү турындагы белешмәләрне күрсәтеп, Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына мәгълүмат кертүне гамәлгә ашыра;

үзенең финанс йөкләмәләрен үтәве турында, шул исәптән Ярдәмче программаны һәм (яки) Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруны күздә тота торган муниципаль программаларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яки) җирле бюджетлар чыгымнары хакында, Ярдәмче программаның максатчан күрсәткечләренең ирешелгән мәгънәләре турында хисаплар кертә;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыруны һәм тиешле контрактлар төзүне тикшерүдә тотуны тәэмин итә;

Ярдәмче программаны тормышка ашыру барышы турында квартал саен хисап алып баруны гамәлгә ашыра;

ел саен Ярдәмче программаны тормышка ашыру барышы турында һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү хакында доклад әзерли;

Ярдәмче программаны тормышка ашыру барышы һәм нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны электрон рәвештә урнаштыруны оештыра;

Ярдәмче программаны тормышка ашыру барышын яктырту мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек итә.

Кирәк булганда Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысы Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытын озайту турында Татарстан Республикасының норматив хокукый акты проектын эшләүне тәэмин итә.

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хисап палатасы субсидиянең максатчан, адреслы һәм нәтиҗәле файдаланылуын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

Ярдәмче программа чараларын үтәү өчен җаваплы үтәүчеләр:

Ярдәмче программа чаралары үтәлешен һәм үзләре карамагындагы тармак объектларына карата аларны тормышка ашыруны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

эшләрне башкаручыларны һәм хезмәт күрсәтүчеләрне, шулай ук Ярдәмче программаның һәр чарасы буенча продукция кайтартучыларны конкурс нигезендә сайлап алуны гамәлгә ашыра;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 10 сыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына Ярдәмче программаны тормышка ашыру чыгымнарын тоту турында билгеләнгән тәртиптә хисап җибәрә;

квартал саен Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен гомумиләштерә һәм анализлый һәм хисап кварталыннан соң килүче айның 10 сына кадәр аны тормышка ашыруның барышы турындагы мәгълүматны Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы-яраштыручысына җибәрә.

Ярдәмче программаны тормышка ашыруны тикшерүдә тотуны һәм бәяләүне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында Ярдәмче программаны тормышка ашыруның барышын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру

буенча Ярдәмче программаны тормышка ашыруда катнашучы дәүләт хакимияте органнары һәм инвалидларның иҗтимагый оешмалары вәкилләреннән төзелә торган эшче төркем (алга таба – Эшче төркем) оештырыла.

Эшче төркем Ярдәмче программаны тормышка ашыруда булышлык күрсәтә торган тикшерүдә тотучы орган булып тора һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, Ярдәмче программаны тормышка ашыруда катнашучы башка органнар һәм оешмалар хезмәттәшлегенә ярдәм итә.

Эшче төркемнең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, Ярдәмче программаны тормышка ашыруда катнашучы башка органнар һәм оешмалар тәкъдимнәре буенча карарлар кабул итү;

эшләр торышын анализлау һәм Ярдәмче программаны үтәү механизмнарын куллану эшен гомумиләштерү нигезендә Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлешендә төбәк законнарын камилләштерү буенча карарлар кабул итү;

Ярдәмче программа чараларын, шул исәптән норматив хокукый, методик характердагы чараларны тормышка ашыруны тикшерүдә тоту;

инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен өстенлекле объектлардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә законнарны үтәү һәм мониторинглау системасын тикшерүдә тоту.

Эшче төркем үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы-эраштыручысыннан, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарыннан, башка органнардан һәм оешмалардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материаллар соратып алырга;

Ярдәмче программа чараларын алга таба тормышка ашыру өчен нәтиҗәләр ясарга һәм тәкъдимнәр эшләргә.

Эшче төркем Эшче төркем җитәкчесе, аның урынбасары, сәркатибе һәм Эшче төркемнең аның эшендә катнаша торган әгъзалары составында төзелә.

Эшче төркем рәисе булып Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары тора.

Эшче төркем утырышларын әзерләүне һәм оештыруны һәм Эшче төркем эшчәнлегенең агымдагы мәсьәләләрен хәл итүне Эшче төркем сәркатибе гамәлгә ашыра.

Эшче төркем утырышлары айга бер тапкыр үткәрелә. Кирәк булганда Эшче төркемнең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

Эшче төркем карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Эшче төркем составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

## V. Ярдәмче программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр:

Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңай мохит шартларын тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру;

Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге өстенлекле объектларга керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу өчен шартлар тудырганда дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшләрен яраштыруны һәм ведомствоара хезмәттәшлек итүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге социаль инфраструктура объектларына керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу турындагы мәгълүматны, аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру максатыннан чыгып, җыю һәм системалаштыру;

инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге өстенлекле объектларга керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу өчен шартлар тудыру;

пассажирлар транспортының, шул исәптән җир өсте электр транспортының төп төрләренә керә торган хәрәкәт итүче составтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү, инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен елга транспортына, метрога керә алу өчен шартлар тудыру.

Татарстан Республикасында инвалидлар өчен тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын һәм аннан һәркем файдалана алу дәрәҗәсен күтәрү;

җәмгыятьтә социаль таркаулыкны бетерү һәм «мөнәсәбәтләр» киртәләрен җиңеп чыгу.

Ярдәмче программаның норматив хокукый, методик характердагы чараларын тормышка ашыру, инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен яңа төзелә торган социаль инфраструктура объектларына керү мөмкинлеге өлешендә Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен киртәсез мохит булдыруның ныклы адымнар белән баруын тәэмин итәргә булышлык күрсәтәчәк законнарның үтәлешен тикшерүдә тоту һәм мониторинглау системасын булдыру.

Ярдәмче программаның гамәли чараларын тормышка ашыру түбәндәгеләргә ярдәм итәчәк:

инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәренең тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрүгә;

инвалидларның изоляциясен бетерүгә һәм социаль бәйләлекне киметүгә;

инвалидларның социаль һәм хезмәт активлыгын стимуллаштыруга;

инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәренең тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге объектларга керә һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алуына;

паралимпия һәм сурдлимпия хәрәкәтен, экскурсия туризмын үстерүгә.

2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасына 1 нче кушымта

## 2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм чараларны финанслау

| Төп чаралар исеме | Үтәүчеләр | Төп чараларны үтәү вакытлары | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Еллар буенча индикаторларның мәгънәләре | | | Финанслау чыганагы | Еллар буенча финанслау, мең сум | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2014 ел | 2015 ел | | 2014 ел | 2015 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Максатның исеме: Татарстан Республикасында инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәренең (мөстәкыйль күчеп йөргәндә хезмәт күрсәтүләрдән файдалануда, кирәкле мәгълүмат алуда авырлыклар кичерүче кешеләр) тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалану һәм өстенлекле объектларга тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итү | | | | | | | | | |
| | ТР ХХЭбТИһСЯМ | 2014 – 2015 еллар | Татарстан Республикасында инвалидларның гомуми санында тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу һәм өстенлекле объектларга керә алу дәрәҗәсен уңай бәяли торган инвалидлар өлеше | 34,7 | 44,6 | 55 | | | |
| 1 нче бурычның исеме: Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрдә хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу һәм өстенлекле объектларга керә алу дәрәҗәсен күтәрү | | | | | | | | | |
| Транспорт инфраструктурасы объектларын адаптацияләү һәм транспорт хезмәтләре күрсәтү | ТР ТАһТКХМ, ТР ТһЮХМ. ТР ЯЭһСМ, ЖҮО | 2014 – 2015 еллар | Өстенлекле объектларның гомуми санында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре керә ала торган социаль, транспорт, инженер инфраструктурасының өстенлекле объектлары өлеше, % | 16,8 | 30,9 | 45 | федераль бюджет | 44 000,0 | 44 000,0 |
| | | | | | | | ТР бюджеты | 63 380,0 | 63 380,0 |
| Спорт объектларын адаптацияләү һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү | ТР ТАһТКХМ, ТР ЯЭһСМ | 2014 – 2015 еллар | | | | | федераль бюджет | 25 671,200 | 25 671,207 |
| | | | | | | | ТР бюджеты | 36 941,493 | 36 941,493 |
| Социаль яклау һәм халыкны эш белән тәэмин итү объектларын адаптацияләү һәм социаль яклау һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү | ТР ТАһТКХМ, ТР ХХЭбТИһСЯМ | 2014 – 2015 еллар | | | | | федераль бюджет | 44 800,7 | 44 800,7 |
| | | | | | | | ТР бюджеты | 64 469,3 | 64 469,3 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Медицина ярдәме (медицина хезмәтләре) күрсәтүче медицина оешмалары объектларын адаптацияләү, шулай ук сәламәтлек саклау өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү | ТР ТАһТКХМ, ТР ССМ | 2014 – 2015 еллар | | | | | федераль бюджет | 51 455,0 | 51 455,0 |
| | | | | | | | ТР бюджеты | 74 045,0 | 74 045,0 |
| Мәдәният объектларын адаптацияләү һәм мәдәният өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү | ТР ТАһТКХМ, ТР ММ | 2014 – 2015 еллар | | | | | федераль бюджет | 21 311,25 | 21 311,25 |
| | | | | | | | ТР бюджеты | 31 176,35 | 31 176,35 |
| Белем бирү оешмалары биналарын (урыннарын) адаптацияләү һәм белем бирү хезмәтләре күрсәтү | ТР ТАһТКХМ, ТР МһФМ | 2014 – 2015 еллар | | | | | федераль бюджет | 21 835,55 | 21 835,56 |
| | | | | | | | ТР бюджеты | 32 050,04 | 32 050,04 |
| Хәрәкәт итүче состав паркында халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәрен йөртү өчен җиһазландырылган автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортының хәрәкәт итүче составы паркын булдыру | ТР ТһЮХМ | 2014 – 2015 еллар | Халыкның аз хәрәкәт итүче төркемнәрен йөртү өчен җиһазландырылган автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортының хәрәкәт итүче составы паркының бу хәрәкәт итүче состав паркындагы өлеше, % | 8,3 | 10,0 | 11,7 | | - | - |
| Һөнәр белеме бирү оешмаларының гомуми санында инвалидларның һәм үсешләрендә тайпылышлар булмаган затларның бергә укуын тәэмин итү өчен һөнәр белеме бирү оешмаларында уңай мохит булдыру | ТР МһФМ | 2014 – 2015 еллар | Һөнәр белеме бирү оешмаларының гомуми санында инвалидларның һәм үсешләрендә тайпылышлар булмаган затларның бергә укуын тәэмин итәргә булыша торган универсаль киртәсез мохит булдырылган һөнәр белеме бирү оешмалары өлеше | 4,9 | 11,8 | 15,4 | | - | - |
| Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларга һәм 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге инвалидларга физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру | ТР ЯЭһСМ | 2014 – 2015 еллар | Халыкның түбәндә күрсәтелгән категориясенең гомуми санында системалы рәвештә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүче сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге инвалидлар өлеше | 13,9 | 14,5 | 15,0 | | - | - |
| 2 нче бурычның исеме: Татарстан Республикасында инвалидларны тернәкләндерү һәм социаль интеграцияләү системасын мәгълүмати-методик яктан һәм кадрлар белән тәэмин итү | | | | | | | | | |
| Инвалидларны тернәкләндерү һәм социаль интеграцияләү мәсьәләләре буенча белгечләрне өйрәтү | ТР ХХӘбТИһСЯМ, ТР МһФМ, ТР ССМ | 2014 – 2015 еллар | Инвалидларны тернәкләндерү, социаль интеграцияләү мәсьәләләре буенча белем алган һәм квалификациясен күтәргән белгеч- | 11,0 | 19,0 | 26,0 | | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ләрнең бу өлкәдә эшләүче белгечләрнең гомуми санындагы өлеше, % | | | | | | |
| 3 нче бурычның исеме: Татарстан Республикасында инвалидлар проблемаларына һәм инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен тереклек эшчәнлегенең уңай мохитен тәэмин итү проблемасына карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру һәм җәмгыятьтә социаль таркаулыкны бетерү | | | | | | | | | |
| Инвалидларга карата толерантлы мөнәсәбәт формалаштыруга юнәлдерелгән иҗтимагый-агарту кампанияләре үткәрү | Р «Татмедиа» МһМКА, ТР ХХЭбТИһСЯМ, ТР ММ, ТР ЯЭһСМ ТР инвалидлар ФСҖ (килешү буенча), ТР ТАһТКХМ, ТР МһФМ, ТР ССМ | 2014 – 2015 еллар | Сораштырылган инвалидларның гомуми санында халыкның инвалидлар проблемасына карата мөнәсәбәтен уңай бәяли торган инвалидлар өлеше, % | 40,8 | 45,2 | 49,6 | федераль бюджет | 6 715,8 | 6 715,8 |
| | | | | | | | ТР бюджеты | 8 464,2 | 8 464,2 |
| **Ярдәмче программа буенча барлыгы, шул исәптән:** | | | | | | | | 526 315,883 | 526 315,9 |
| **Федераль бюджет** | | | | | | | | 215 789,500 | 215 789,517 |
| **Татарстан Республикасы бюджеты** | | | | | | | | 310 526,383 | 310 526,383 |

**Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:**

ТР ЯЭһСМ – Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы;
ТР ССМ – Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы;
ТР ММ – Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы;
ТР МһФМ – Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы;
ТР ТАһТКХМ – Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы;
ТР ХХЭбТИһСЯМ – Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;
ТР ТһЮХМ – Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы;
ҖҮО – Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары;
Р «Татмедиа» МһМКА – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы;
ТР Инвалидлар ФСҖ – Татарстан Республикасының Инвалидлар физкультура-спорт җәмгыяте.

2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасына 2 нче кушымта

2014 – 2015 елларга «Унайлы мохит» ярдәмче программасы чаралары исемлеге

| Т/с | Чаралар исеме | Чараларны үтәү вакытлары | Җаваплы үтәүчеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. Инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңайлы социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасын формалаштыруны норматив-хокукый тәэмин итү, инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен социаль һәм транспорт инфраструктурасының һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүне мониторинглау һәм тикшерүдә тоту системасын формалаштыру | | | |
| 1.1. | Инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңайлы социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасын формалаштыру өчен шартлар тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү, бу бурычларны тормышка ашыруны тикшерүдә тоту функциясен билгеләү | 2014 – 2015 еллар | ТР ЮМ, Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары |
| 1.2. | Эшләп торучы объектлар социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары паспортларын булдыру эшен үткәрү өчен муниципаль берәмлекләрнең эшче төркемнәрен өйрәтүне оештыру | 2014 – 2015 еллар | ТР ТАһТКХМ, ТР ХХЭбТИһСЯМ |
| 1.3. | Инвалидларның иҗтимагый оешмалары вәкилләрен җәлеп итеп, инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тереклек эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендәге объектлар һәм хезмәт күрсәтүләр паспортларын булдыру | 2014 – 2015 еллар | ҖҮО (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 1.4. | Социаль һәм транспорт инфраструктурасы объектларының уңайлылык картасын һәм мәгълүматлар банкын булдыру һәм алып бару буенча программа продуктын үстерү | 2014 – 2015 еллар | ТР ХХЭбТИһСЯМ, ТР ТАһТКХМ, ТР МһЭМ, ТР МТҮ, ТР ТһЮХМ, ТР ССМ, ТР МһФМ, ТР ММ, ТР ЯЭһСМ, ҖҮО (килешү буенча) |
| 1.5. | Инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңайлы мохит булдыруны регламентлый торган методик тәкъдимнамәләр эшләү һәм бастырып чыгару | 2014 – 2015 еллар | ТР ХХЭбТИһСЯМ, ТР ТАһТКХМ |
| 1.6. | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының рәсми сайтында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңай мохит булдыру буенча норматив хокукый базаны, объектлар төзегәндә һәм адаптацияләгәндә кызыксынучы оешмалар һәм учреждениеләр тарафыннан файдалану максатларында, инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен тереклек эшчәнлегенең уңай мохитен булдыруны исәпкә алып, кабат куллану проектлары вариантларын урнаштыру | 2014 – 2015 еллар | ТР ТАһТКХМ, ТР ТһЮХМ |
| 1.7. | Муниципаль берәмлекләр яктылыгында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңай мохит тәэмин итү буенча республика дәүләт статистика күзәтүе формаларын эшләү һәм раслау, мониторинглауны һәм мәгълүмати-аналитик мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертүне гамәлгә ашыру | 2014 – 2015 еллар | ТР Социаль-икътисадый мониторинг комитеты, ҖҮО (килешү буенча) |
| 1.8. | Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары һәм шәһәр округларының һәм муниципаль | 2014 – 2015 еллар | Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксы- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | районнарның җирле үзидарә органнары арасындагы килешүләргә инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен социаль (биналар һәм корылмалар), транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының һәм хезмәт күрсәтүләрнең һәркем файдалана алырлык булу торышын чагылдыра торган күрсәткечләрне кертү | | нучы органнары, ҖҮО (килешү буенча) |
| 1.9. | Дәүләт һәм муниципаль торак фондының эшләп торучы һәм яна кертелә торган социаль инфраструктура объектларында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңайлылык таләпләре үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру.<br>Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә ел саен хисап кертү | 2014 – 2015 еллар | ТР ТһАб ДВТЭИ, ТР ДТКИ |
| 2. Социаль, транспорт, инженерлык инфраструктурасының өстенлекле объектларын инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тоткарлыксыз керә алырлык итеп, аларның аерым ихтыяҗларын исәпкә алып, тереклек эшчәнлекләрендәге төп чикләнүләрдән чыгып адаптацияләү | | | |
| 2.1. | Торак фонды объектларын һәм торак мохитне адаптацияләү | | |
| 2.1.1. | Торак фондының эшләп торучы объектлары паспортларын булдыруны инвалидларның иҗтимагый оешмалары вәкилләрен җәлеп итеп үткәрү | 2014 – 2015 еллар | ҖҮО (килешү буенча) |
| 2.1.2. | Торак фонды объектларын һәм ишек алды территорияләрен инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре ихтыяҗлары өчен адаптацияләү, шул исәптән:<br>бинага керә торган зонаны, баскыч төбен, тамбурны, подъ-ездның вестибюлен һәм хәрәкәт юлларын (лифтны, баскычны) җиһазландыру (җайлаштыру);<br>хәрәкәт юлларын махсус җайланмалар (пандуслар, таяну | 2014 – 2015 еллар | ҖҮО (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | тоткалары, аппарельләр, күтәргечләр, коляскаларны ныгыту урыннары, биналар эчендәге утлы-тавышлы хәбәр итү җайланмалары, баскыч алдындагы тактиль полосалар, соңгы бачкыч такталарын контраст төсләргә буяу, тавышлы маягы булган ишек яңаклары белән) җиһазландыру | | |
| 2.1.3. | Күрү буенча инвалидлар күпләп яши торган торак йортларны күрү буенча инвалидлар ихтыяҗларына адаптацияләү (Бөтенроссия сукырлар җәмгыятенең Татарстан Республика оешмасы белән килештереп) | 2014 – 2015 еллар | ҖҮО (килешү буенча) |
| 2.1.4. | Коляскаларда йөрүче инвалидлар һәм ишетү һәм күрү сәләте бозылган инвалидлар өчен ял паркаларында һәм рекреация зоналарында хәрәкәт маршрутларын (юл-сукмак челтәре белән) ясау | 2014 – 2015 еллар | ҖҮО (килешү буенча) |
| 2.1.5. | Утыргыч-коляскаларда йөрүче инвалидлар һәм ишетү һәм күрү сәләте бозылган инвалидлар тарафыннан файдалану өчен тротуарлар һәм җәяүлеләрнең юл аркылы чыгу урыннарын ясау (җир өстендәге юл аша чыгу урыннарын, җир астындагы юл аша чыгу урыннарын реконструкцияләү, җир өстендәге юл аша чыгу урыннарында бордюр ташын түбәнәйтү) | 2014 – 2015 еллар | ҖҮО (килешү буенча), ТР ТһЮХМ |
| 2.1.6. | Торак зоналарда инвалидлар өчен махсус бирелгән парковка урыннары булдыру | 2014 – 2015 еллар | ҖҮО (килешү буенча) |
| 2.2. | Транспорт инфраструктурасы объектларын адаптацияләү һәм транспорт хезмәтләре күрсәтү | | |
| 2.2.1. | Шәһәр эчендәге җир өсте пассажир транспортын адаптацияләү | | |
| 2.2.1.1. | Инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен пассажирлар транспортының хәрәкәттәге составы уңайлылыгын, аларның аерым ихтыяҗларын исәпкә алып, тереклек эшчәнлекләрендәге чикләнүләрдән чыгып тәэмин итү, шул исәптән җир өсте шәһәр | 2014 – 2015 еллар | ТР ТһЮХМ, транспорт хезмәтләре күрсәтүче предприятиеләр белән берлектә ҖҮО (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
| --- | --- | --- | --- |
| | пассажирлар транспортының хәрәкәттәге составын, гомуми файдаланудагы транспорт чараларын махсус җиһазлар белән модернизацияләү | | |
| 2.2.1.2. | Хәрәкәттәге пассажирлар составын начар ишетүче инвалидлар өчен ут-диодлы табло һәм начар ишетүче инвалидлар өчен махсус тавышлы сигнал белән җиһазландыру | 2014 – 2015 еллар | транспорт хезмәтләре күрсәтүче предприятиеләр белән берлектә ҖҮО (килешү буенча) |
| 2.2.1.3. | Транспорт чараларын аларны инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңайлы булуын тәэмин итә торган махсус җиһазлар һәм конструктив үзенчәлекләре белән сатып алу | 2014 – 2015 еллар | ТР ТһЮХМ, ҖҮО (килешү буенча), транспорт хезмәтләре күрсәтүче предприятиеләр милекчеләре (килешү буенча) |
| 2.2.1.4. | Транспорт туктап тору мәйданчыкларында маршрут автобуслары килеп җитәргә тиеш булган вакыт турында сорауга тавыш белән җавап бирә торган мәгълүмат таблосы (чакыру төймәсе) кую | 2014 – 2015 еллар | ҖҮО (килешү буенча), ТР ТһЮХМ |
| 2.2.1.5. | Тавышлы светофорлар кую | 2014 – 2015 еллар | БСҖ ТРБ территориаль бүлекләре катнашында ҖҮО (килешү буенча) |
| 2.2.1.6. | Юл инфраструктурасы объектларына инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре килә торган юлларны бозлавыкка каршы япмалар белән ябу | 2014 – 2015 еллар | ТР ТһЮХМ, ҖҮО (килешү буенча) |
| 2.2.2. | Җәяүлеләр юл аша чыга торган урыннарны адаптацияләү | | |
| 2.2.2.1. | Җир астындагы, җир өстендәге җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарын инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тоткарлыксыз керә алу өчен адаптацияләү һәм пандуслар, лифтлар, тактиль һәм контрастлы өслекләр, интенсивлыгы югары булган, утны кире кайтара торган һәм күләме зурайтылган «Игътибар, балалар!», «Сукыр җәяүлеләр» дигән күрсәткечләр һ.б. белән җиһазландыру | 2014 – 2015 еллар | ТР ТАһТКХМ, ТР ТһЮХМ, ҖҮО (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 2.2.3. | Шәһәрара пассажирлар транспортын адаптацияләү | | |
| 2.2.3.1. | Тимер юл вокзалларының һәм алар янындагы территорияләрнең инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңайлы булуын тәэмин итү, шул исәптән:<br>таяну-хәрәкәтләнү аппараты бозылган затлар өчен махсуслаштырылган таксофоннар, ишетү һәм күрү сәләте бозылган затлар өчен утлы һәм тавышлы мәгълүмат белән күрсәткечләр кую;<br>махсуслаштырылган кассалар, җәмәгать бәдрәфләрендә кабиналар һәм көтү залларында урыннар җиһазландыру;<br>инвалидлар йөрү өчен адаптацияләнгән транспорт хәрәкәте расписаниеләрен урнаштыру;<br>биналарны пандуслар һәм башка махсус җиһазлар һәм җайланмалар белән җиһазландыру,<br>биналарны мәгълүмати табличкалар, «ярдәмче» чакыру төймәсе белән җиһазландыру,<br>махсус бирелгән парковка урыннары булдыру,<br>ишетү сәләте бозылган инвалидларның ишетү сәләтен арттыру өчен җиһазлар кую,<br>махсус бирелгән парковка урыннары булдыру | 2014 – 2015 еллар | ТР ТһЮХМ, ОАО «РЖД-Казань» (килешү буенча) |
| 2.2.3.2. | Аэропортларның һәм алар янындагы территорияләрнең инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңайлы булуын тәэмин итү, шул исәптән:<br>таяну-хәрәкәтләнү аппараты бозылган затлар өчен махсуслаштырылган таксофоннар, ишетү һәм күрү сәләтләре бозылган затлар өчен утлы һәм тавышлы мәгълүмат белән күрсәткечләр кую;<br>махсуслаштырылган кассалар, җәмәгать бәдрәфләрендә | 2014 – 2015 еллар | ТР ТһЮХМ, «КХА» ачык акционерлар җәмгыяте (килешү буенча), «Бигеш» аэропорты» ачык акционерлар җәмгыяте (килешү буенча), «Аэропорт «Ак Барс – Аэро» ачык акционерлар җәмгыяте (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | кабиналар һәм көтү залларында урыннар җиһазландыру; инвалидлар йөрү өчен адаптацияләнгән транспорт хәрәкәте расписаниеләрен урнаштыру; биналарны пандуслар һәм башка махсус җиһазлар һәм җайланмалар белән җиһазландыру, биналарны мәгълүмати табличкалар, «ярдәмче» чакыру төймәсе белән җиһазландыру, махсус бирелгән парковка урыннары булдыру, ишетү сәләте бозылган инвалидларның ишетү сәләтен арттыру өчен җиһазлар кую, махсус бирелгән парковка урыннары булдыру | | |
| 2.2.3.3. | Мөмкинлекеләре чикләнгән затларга хезмәт күрсәтү өчен махсус транспорт чаралары сатып алу | 2014 – 2015 еллар | ТР ТһЮХМ, «КХА» ачык акционерлар җәмгыяте (килешү буенча), «Бигеш» аэропорты» ачык акционерлар җәмгыяте (килешү буенча), «Аэропорт «Ак Барс – Аэро» ачык акционерлар җәмгыяте (килешү буенча) |
| 2.2.3.4. | Автовокзалларның инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңайлы булуын тәэмин итү, шул исәптән: таяну-хәрәкәтләнү аппараты бозылган затлар өчен махсуслаштырылган таксофоннар, ишетү һәм күрү сәләтләре бозылган затлар өчен утлы һәм тавышлы мәгълүмат белән күрсәткечләр кую; махсуслаштырылган кассалар, җәмәгать бәдрәфләрендә кабиналар һәм көтү залларында урыннар җиһазландыру; инвалидлар йөрү өчен адаптацияләнгән транспорт хәрәкәте | 2014 – 2015 еллар | ТР ТһЮХМ, ҖҮО (килешү буенча), транспорт хезмәтләре күрсәтүче предприятиеләр (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | расписаниеләрен урнаштыру;<br>биналарны пандуслар һәм башка махсус җиһазлар һәм жайланмалар белән җиһазландыру,<br>биналарны мәгълүмати табличкалар, «ярдәмче» чакыру төймәсе белән җиһазландыру,<br>махсус бирелгән парковка урыннары булдыру,<br>ишетү сәләте бозылган инвалидларның ишетү сәләтен арттыру өчен җиһазлар кую,<br>махсус бирелгән парковка урыннары булдыру | | |
| 2.2.3.5. | Елга вокзалларының инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре өчен уңайлы булуын тәэмин итү, шул исәптән:<br>таяну-хәрәкәтләнү аппараты бозылган затлар өчен махсуслаштырылган таксофоннар, ишетү һәм күрү сәләтләре бозылган затлар өчен утлы һәм тавышлы мәгълүмат белән күрсәткечләр кую;<br>махсуслаштырылган кассалар, җәмәгать бәдрәфләрендә кабиналар һәм көтү залларында урыннар җиһазландыру;<br>инвалидлар йөрү өчен адаптацияләнгән транспорт хәрәкәте расписаниеләрен урнаштыру;<br>биналарны пандуслар һәм башка махсус җиһазлар һәм жайланмалар белән җиһазландыру,<br>биналарны мәгълүмати табличкалар, «ярдәмче» чакыру төймәсе белән җиһазландыру,<br>махсус бирелгән парковка урыннары булдыру,<br>ишетү сәләте бозылган инвалидларның ишетү сәләтен арттыру өчен җиһазлар кую,<br>махсус бирелгән парковка урыннары булдыру | 2014 – 2015 еллар | ТР ТһЮХМ, «Татфлот» СК» ачык акционерлар җәмгыяте (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 2.2.3.6. | Пассажирлар белән турыдан-туры хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыручы транспорт өлкәсе хезмәткәрләрен инвалид пассажирлар белән эшләү үзенчәлегенә өйрәтү | 2014 – 2015 еллар | ТР ТhЮХМ, ҖҮО (килешү буенча), транспорт хезмәтләре күрсәтүче предприятиеләр (килешү буенча) |
| 2.3. | Спорт объектларын адаптацияләү һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү | | |
| 2.3.1. | Өстенлекле спорт объектларының һәм алар янындагы территорияләрнең, шулай ук адаптив физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен таләп ителгән объектларның таяну-хәрәкәтләнү аппараты, күрү һәм ишетү сәләтләре бозылган инвалидлар өчен унайлы булуын тәэмин итү | 2014 – 2015 еллар | ТР ТАһТКХМ, ТР ЯЭһСМ |
| 2.3.2. | Инвалид спортчыларны әзерләүне һәм аларның спорт ярышларында катнашуын тәэмин итү | 2014 – 2015 еллар | ТР Инвалидлар ФСҖ катнашында ТР ЯЭһСМ |
| 2.3.3. | «Адаптив физик культура һәм спорт» белем бирү программасы буенча белгечләр әзерләү | 2014 – 2015 еллар | ЮҺББ «Идел буе физик культура, спорт һәм туризм дәүләт академиясе» ФДБУ (килешү буенча) |
| 2.3.4. | Инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре белән эшләүче инструкторларның һәм тренерларның квалификациясен күтәрү һәм аларны яңадан һөнәри әзерләү | 2014 – 2015 еллар | ТР ЯЭһСМ |
| 2.3.5. | Инвалид спортчылар өчен бөтенроссия һәм республика ярышларын, чемпионатларын, спартакиадаларын оештыру һәм үткәрү | 2014 – 2015 еллар | ТР Инвалидлар ФСҖ катнашында ТР ЯЭһСМ (килешү буенча) |
| 2.3.6. | Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр, шул исәптән инвалид балалар арасында республика спорт-савыктыру чараларын, спорт бәйрәмнәрен үткәрү | 2014 – 2015 еллар | ТР Инвалидлар ФСҖ катнашында ТР ЯЭһСМ (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 2.3.7. | Күчеп йөрү мөмкинлекләре чикләнгән, ишетү һәм күрү сәләтләре бозылган инвалидлар өчен экскурсия маршрутларын эшләү, экскурсияләр оештыру һәм үткәрү | 2014 – 2015 еллар | ТР ЯЭһСМ, ТР ММ |
| 2.3.8. | Күрү сәләте бозылган һәм утыргыч-колярскаларда йөрүче инвалидлар тоткарлыксыз керә алу өчен кунакханәләр ясау, шул исәптән номерларны һәм алар янындагы территорияләрне җайлаштыру | 2014 – 2015 еллар | кунакханәләр милекчеләре (килешү буенча) |
| 2.4. | Социаль яклау һәм халыкны эш белән тәэмин итү объектларын адаптацияләү һәм социаль яклау һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү | | |
| 2.4.1. | Халыкны социаль яклау өлкәсендәге өстенлекле объектларның керә алырлык булуын тәэмин итү | | |
| 2.4.1.1. | Халыкны социаль яклау территориаль органнары биналарын һәм алар янындагы территорияләрне, инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тоткарлыксыз керә алырлык итеп, аларның аерым ихтыяҗларын һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалануын исәпкә алып адаптацияләү, шул исәптән:<br>махсус бирелгән парковка урыннары булдыру;<br>биналарны пандуслар һәм башка махсус җиһазлар һәм җайланмалар белән җиһазландыру;<br>биналарны мәгълүмати табличкалар, «ярдәмче» чакыру төймәсе белән җиһазландыру;<br>ишетү сәләте бозылган инвалидларның ишетү сәләтен арттыру өчен җиһаз кую;<br>көтү урыннарында һәм гражданнарны кабул итү урыннарында юл күрсәтүче эт яки күчеп йөрү җайланмасы өчен алда һәм янда өстәмә урын белән уңайлылыгы арттырылган урыннар җиһазландыру;<br>инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре керә ала торган урыннарда инвалидлар өчен, | 2014 – 2015 еллар | ТР ТАһТКХМ, ТР ХХЭбТИһСЯМ |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | аларның аерым ихтыяҗларын исәпкә алып, күрсәтелә торган хезмәтләр хакында адаптацияләнгән формада белешмә мәгълүмат урнаштыру;<br>инвалидларга һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәренә, аларның тереклек эшчәнлекләрендәге чикләнүләрдән чыгып, аларның аерым ихтыяҗларын исәпкә алып, хезмәтләр күрсәтү;<br>тиешле квалификацияле сурдотәрҗемәчеләр булуны тәэмин итү | | |
| 2.4.1.2. | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре биналарын һәм алар янындагы территорияләрне инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре тоткарлыксыз керә алырлык итеп, аларның аерым ихтыяҗларын һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалануын исәпкә алып адаптацияләү, шул исәптән:<br>махсус бирелгән парковка урыннары булдыру,<br>биналарны пандуслар һәм башка махсус җиһазлар һәм җайланмалар белән җиһазландыру;<br>биналарны мәгълүмати табличкалар, «ярдәмче» чакыру төймәсе белән җиһазландыру;<br>ишетү сәләте бозылган инвалидларның ишетү сәләтен арттыру өчен җиһаз кую;<br>көтү урыннарында һәм гражданнарны кабул итү урыннарында юл күрсәтүче эт яки күчеп йөрү җайланмасы өчен алда һәм янда өстәмә урын белән уңайлылыгы арттырылган урыннар җиһазландыру;<br>инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәре керә ала торган урыннарда инвалидлар өчен, аларның аерым ихтыяҗларын исәпкә алып, күрсәтелә | 2014 – 2015 еллар | ТР ТАһТКХМ, ТР ХХЭбТИһСЯМ |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | торган хезмәтләр хакында адаптацияләнгән формада белешмә мәгълүмат урнаштыру;<br>инвалидларга һәм халыкның аз хәрәкәт итүче башка төркемнәренә, аларның тереклек эшчәнлекләрендәге чикләнүләрдән чыгып, аларның аерым ихтыяҗларын исәпкә алып, хезмәтләр күрсәтү;<br>тиешле квалификацияле сурдотәрҗемәчеләр булуны тәэмин итү | | |
| 2.4.2. | Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстелекле объектларны адаптацияләү | | |
